PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№7 (307) – ИЮЛЬ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Язмышы –
кешеләрне коткару

Сукбайлар
кемгә кирәк?

Беренче
башкала

ТИМЕРЧЕ ИМАМ

4 612750 670011

PRESSA.RU

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Гадел Хәеров, Фаяз Хуҗин
Фотограф: Ната Смирнова, Александр Ефремов
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Диана Сираҗиева
Тышлыктагы фото: Ната Смирнова

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа»
рубрикалары материаллары реклама-коммерция
нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-1587

Басарга кул куелды: 19.07.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76

Коммерция директоры урынбасары:
Александр Березовский

Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова

Махсус проектлар бүлеге белгече:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

БӘХЕТ ҖӘЙДӘМЕНИ?!

Бу җәйдә без шуны аңладык: бәхет җәйдә түгел икән. Гәрчә ул бездә әле һаман да җылылык, яктылык белән тәңгәлләшсә һәм кечкенә генә өмет чаткысын исән килеш сакласа да… Тукта, ә бәлки, иртәгә чынлап та башланыр – балкып торган эссе җәй, ә бит ул асылда шундый булырга тиеш тә!

Әмма быелгы җәйдә моңсулык модада: күкләр елый, зонтлар чылана, дөрес, флора сөенеп туя алмый, фауна да әллә ни хәсрәтләнми шикелле. Ничек кенә булмасын, яңгыр юган һәм җетелегеннән күз камашкан яшеллеккә һава торышына зонт астыннан бары тәнкыйть белән генә карарга иялә шкән күз белән багып та, соклануны яшерә алмыйбыз. Шуңа да һава бозылганга моңаеп утыруны туктатабыз да, типтереп яшәргә керешәбез – монда туганбыз икән, барыбер монда яшисе инде! Сүз уңаеннан, быелгы җәйдә 2010 елгысыныкына караганда яшәү барыбер дә уңайлырак. Теге чакта без яңгыр сорап тилмергән идек, әмма ул ялварууларыбызга колак салмый тинтерәтте. Конфедерацияләр кубогы кунакларына да бик җәй туры килде: эссе бөркеп утырган илләреннән чыгып китеп, ниһаять, салкынча-җиләс Казан чынбарлыгына күмелә алдылар. Һәм инандылар: җылылык кояш нурларыннан бигрәк кунакчыл кешеләрдән бөркелә, яңгыр астында чәнечкеле кактуслар түгел, көдрә каеннар җилферди.

Озын сүзнең кыскасы, Татарстан, гадәттәгечә, йөзгә кызыллык китермәдә – 2017 елда Конфедерацияләр кубогы белән берләттән, бар дөньядан килгән кунакларга иркенләп яшәү мөмкинлеге тудырды. Ә яхшы эштән соң күңел дә рәхәтләнеп кала. «Кешеләргә бәхет өләшә-өләшә, үз бәхетебезне арттырабыз» лабаса.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен



Рассам: Иван Шишкин. 1891 ел. «Дождь в дубовом лесу»

ИЮЛЬ. АЛАБУГА

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Бурыч – үтәлерлек.
Татарстанның баш раввины – мөселманнарны һәм яһүдләрне берләштергән кыйммәтләр турында

14. Биеклектә коткару.
Авиация медицинага ярдәм итә аламы

16. Олы уеннар.
Футбол фанатлары Казанда ниләр күргәннәр

20. Хирурглар нәселеннән.
Берничә буын татарстанлыларның сәламәтлеген кем кайгырткан

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

26. Язмышмы, ялгышмы?
Бер сукбай республика казнасына күпмегә төшә

30. Игелекле кешеләр дөньясы.
Ничек кешеләр өчен яшәргә өйрәнергә

34. Үзең алпавыт та, крепостной да.
Чит илләргә чыгу туйдырса, кая барырга

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

40. Таулар манзарасы.
Кайсы калага гашыйк булмау мөмкин түгел

62. Тарих битләре.
Болгар иле башкаласы турында бәхәсләр

66. Татарлар дөньясы.
Лангепаста милләттәшләребез ничек яши

70. Редакция кухнясы.
Актаныш чәкчәге нинди була

78. Рафаэль Хәкимов белән әңгәмә.
Академик булу өчен нинди китаплар укырга кирәк

80. Китап киштәсе.
Журналистлар күргән һәм ачкан дөнья

92. Татар авыллары.
Кошлар тавы кайда урнашкан

Банк Казани
«Мега Депозит»
для юридических лиц
Открыть депозит можно на срок
181
день
Процентная ставка
от 9,5 – 11,0%,
в зависимости от размера неснижаемого остатка и суммы депозита
Минимальная сумма депозита
10 000 000
рублей
Выплата процентов производится в день окончания срока депозита, либо ежемесячно. По условиям депозита предоставляется возможность пополнения и изъятия денежных средств.
Бесплатный звонок по России
8 (800) 77-518-77
www.bankofkazan.ru
Лицензия №708 от 27.05.2016 г., ООО КБЭР «Банк Казани». Реклама. Проценты выплачиваются в день окончания срока депозита, либо ежемесячно. В день окончания срока депозита Банк перечисляет сумму депозита и причитающиеся Клиенту проценты на расчетный счет Клиента. Возможна, на условиях, опубликованных на официальном интернет–сайте Банка по состоянию на последний рабочий день, предшествующий дате окончания срока депозита. Подробная информация на сайте: bankofkazan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

22.06

Йоахим Лёв, футбол буенча Германия җыелма командасының баш тренеры, – Татарстан башкаласында Конфедерацияләр кубогы матчыннан соң:

– «Казан Арена»мы? Бу стадион искиткеч матур! Сочи белән Казанда бик матур һәм заманча стадион төзелгән, монда бик яхшы газоннар, аларда сыйфатлы футбол күрсәтергә мөмкин.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

28.06

Хуан Антонио Пицци, Чили җыелма командасының баш тренеры, – Португалия җыелма командасын җиңгәннән соң үткәрелгән матбугат конференциясендә:

– Казанда безне бик җылы, кунакчыл каршы алдылар. Мин монда элегрәк, әле кыш көне үк булган идем. Бу шәһәр бик салкын, карлы була ала, әмма елның теләсә кайсы фасылында миңа монда бик ошый. Мин аңлыйм: истәлекле урыннар белән танышыр өчен вакытыбыз күбрәк булса, яхшырак булыр иде. Гомумән, һәркемгә дә Казанга килергә киңәш итәм. Ул искиткеч гүзәл, матур шәһәр.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

28.06

Джанни Инфантино, ФИФА Халыкара футбол федерациясе президенты:

– Казан – спорт шәһәре, һәм бу безгә билгеле иде. Шуны өстәп әйтим: ул – футбол шәһәре дә. Дөньяның әле үзе өчен Казанны һәм Татарстанны аның бай мәдәнияте һәм тарихы ягыннан ачасы бар. Конфедерацияләр кубогында Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләре кушыла һәм үзара тату яши торган бу «эретү казанын» күрү минем өчен ачыш булды.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

КЕМ мохтаҗларга игелек кыларга әзер

Татарстанның баш раввины хыялын **НИЧЕК** тормышка ашырган

Футбол фанатларын **НИЧЕК** каршы алырга

КЕМ берничә буын татарстанлыларның сәламәтлеген кайгырткан

PRESSA.RU

«Татмедиа» АҖнең #ПодариПодписку проекты күп татарстанлылар арасында теләктәшлек тапты. Депутатлар, министрлар, спортчылар, артистлар, шулай ук республиканың битараф булмаган кешеләре матбугат басмаларына, шул исәптән «Татарстан» журналына, мохтаҗларны яздырдылар, шул рәвешле игелекле гамәлләр кылдылар.

ТАТАРСТАН
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫЙ



Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, күбрәк читтәрле мәгълүмат пространствосында активлыгына карамастан, хәйрия акциясен читләтеп узмады һәм Татарстандагы 26 картлар йортын «Татарстан»ның русча һәм татарча версияләренә яздырды.

СӨЕНЕП ҺӘМ ЧЫН КҮҢЕЛДӘН БҮЛӘК ИТӘМ

Ләйлә Фазлыева, ТР Президенты ярдәмчесе Кайбыч, Балык Бистәсе һәм Тәтеш районнарының интернат-йортларын журналга яздырды:
– «Татарстан» журналын үзем яратып укыйм һәм ул хәзерге замандагы бихисап интернет-басмалар арасында үзенең лаеклы урынын били, укырга кызыклы, кулга тотып карарга да җайлы. Бүләгем – чын күңелдән.

ЯРДӘМ ИТҮ, МОХТАҖЛАР ТУРЫНДА КАЙГЫРТУ – ИСЛАМ ДИНЕ БЕЗНЕ ШУҢА ӨЙРӘТӘ

«Казан Нуры» мәчетенең Хәйрия фонды республиканың 30 картлар йортын «Татарстан» журналына яздырды:
– Ислам дине безне мохтаҗларга ярдәм итегез, алар турында кайгыртыгыз дип өйрәтә, – ди «Казан Нуры» мәчетенең имамы Марат хәзрәт. – Бу нибары картлык көннәрендә балаларының кайгыртуыннан мәхрүм калган өлкән кешеләргә игътибар һәм ихтирам билгесе генә... «Татарстан» журналы бу җәһәттән яхшы бүләк: ул позитив, кызыклы, аны укуы күңелле... Без кешеләргә мәңгелек кыйммәтләр турында искәртеп торырга, аларны чынбарлыкка кайтарырга тырышабыз, гамәлләрен аңлы рәвештә кыларга, укырга өндибез. «Татарстан» журналы моңа ярдәм итә, һәм без бик шатбыз.

Реклама 16+

«Татарстан» журналына теләсә кайсы айдан башлап
барлык элемтә бүлекчәләрендә язылырга мөмкин!

РЕСПУБЛИКАНЫҢ ПРОФСОЮЗЛАР ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА БӨТЕН ТАТАРСТАН БЕЛЕП ТОРЫРГА ТИЕШ

Татарстанның Профсоюзлар федерациясе үзенең бүлекчәләрен «Татарстан» журналына яздырды.

– Профсоюз әгъзалары федерациянең эшчәнлеге, аның бай тарихы, кызыклы бүгенгесе һәм якты киләчәге турында күбрәк белеп торырлар, – ди **Татьяна Водопьянова, ТР Профсоюзлар Федерациясе рәисе.** – Без барыбыз да эшлибез, барыбыз да тегे яки бу оешманың хезмәткәрләре, ә профсоюз – эшли торган татарстанлыларның мәнфәгатьләре сагында тора.

ӘГӘР ЯРДӘМ ИТҮ МӨМКИНЛЕГЕ БАР ИКӘН – НИГӘ ИТМӘСКӘ?

Антон Пушкарёв, Швейцариянең Syngenta AG* үсемлекләрне саклау чаралары һәм орлык җитештерү буенча компаниясенең Россиядәге филиалының коммуникацияләр буенча менеджеры Татарстан Республикасының Ветераннар берлеген һәм Азнакайның картлар һәм инвалидлар йортын ярты елга яздырды:

– Укырга ярата торган кешеләр, ә өлкәннәр нәкъ шушы категориягә карый, бу журналда, һичшиксез, үзләренә туры килә һәм кызыклы булган материалларны табачак.



Айрат Дәүләтшин, Татарстанның синхрон йөзү федерациясе президенты республиканың Федоровское, Алексеевск, Әлки, Яңа Чишмә, Спас, Чирмешән һәм Чистайдагы картлар йортын журналга яздырды:

– Нәкъ менә алар укый торган аудитория дә инде. «Татарстан» журналында өлкән буын үзләре өчен кызыклы булган материалларны табачак. Ә яздырырга мөмкинлекләре юк. Миндә бар ул мөмкинлек, шулай булгач, нигә ярдәм итмәскә?

БАЛАЛАРГА КҮРСӘТКӘН ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТЛЕБЕЗ



«Татарстан» журналына РБКХ табибләры үзләрен, әти-әниләрен һәм Балалар республика клиник хастаханәсенең китапханәсен яздырдылар.

– Безгә көн саен бик күп балалар килә, кечкенәләре әниләре белән, әлбәттә, – **ди РБКХнең баш табибы Рафаэль Шәвәлиев.** – Һәрбер әни үзенең сабые өчен борчыла, һәркайсын тынычландырырга кирәк. Бала савыга башлагач, аңа балалар өчен китаплар укыйлар, әниләренең дә укыйсы килә башлый. Шуңа да без һәрвакытта да төрле басмаларга язылабыз, һәркайсы үз укучысын таба. Китапханәбез өчен дә яздырабыз. Табибларга үзләренең яраткан басмаларына язылу уңайлы булсын өчен без шушында ук абунәче көннәре уздырабыз. Хастаханәләрдә халык укырга ярата.



– Күз өчен экраннардан, телефоннардан, гаджетлардан уку зыянлы, дип саныйм, – **дип киңәш итә абунәчеләргә Республика балалар клиник хастаханәсенең офтальмология бүлеге мөдире, табиб-офтальмолог Алексей Расчёсков.** – Бары тик кәгазьдән генә укырга кирәк. Үзем күзләремне сакларга тырышам – китапларны һәм журналларны кәгазьдән укыйм. Шуңа да «Татарстан» журналына язылдым: кызыклы да, күз өчен дә зыянлы түгел.

– Миңа «Татарстан» журналы коллективының эшләү рәвеше ошый, – **дип аңлата «ТР ССМ РБКХ» ДАССУнең җәмәгатьчелек белән элемтәләр белгече Светлана Шканова.** – Ниндидер чаралар турында кызыклы итеп язу өчен уйлап чыгарган идеяләрегез дә, редакциягә Роналд Макдоналд Йортыннан балалар чакырып, аларны «редакция кухня»сында катнаштыруыгыз да ошый. Күренеп тора: чын күңелдән эшлисез, барысы да алдан уйланган, кызыклы. Без сезнең балаларга биргән игътибарыгыз өчен рәхмәтле, шулай ук һөнәри осталык һәм компетенция өчен дә. Менә дигән полиграфия, югары һөнәри дәрәҗәдәге фотографияләр – болар барысы да басманы кызыклы итә. Шуңа да без рәхәтләнеп «Татарстан» журналына язылабыз.

* Сингента АГ

Реклама 16+

Язылу индекслары:

П 2381 татар телендә 900 сум 00 тиен

П 2378 рус телендә 900 сум 00 тиен

PRESSA.RU

БУРЫЧ – ҮТӘЛЕРЛЕК

Ицхак Горелик Казанга егерме ел элек бик зур миссия белән килә: аңа яһүд җәмгыятен җитәкләү һәм онытылган милли гореф-гадәтләрне торгызу бурычы йөкләнә. Татарстанның баш раввины ниятләрен чынга ашыра алдымы икән?

«ЭШЛӘГЕЗ ҺӘМ БУЛДЫРЫГЫЗ!»

– Сез Израильдә туып, АКШта укыгансыз, тик тормыш алып барыр һәм хезмәт итәр урын буларак, нәкъ менә Россияне сайлагансыз. Моны ничек аңлата аласыз?

– Әти-әниләрем – совет эмигрантлары. Алар бик динле кешеләр, ләкин СССРда дин кушканнарны үтәп яшәү җиңелләрдән түгел иде. Бабамны әле Сталин заманында ук моның өчен сөргенгә сөргәннәр. Димәк, әти-әниләрем ватаннарын рәхәт тормыш эзләп кенә ташлап китмәгән. Алар бары бер нәрсә – балаларын үз милли гореф-гадәтләре нигезендә тәрбияләргә теләгән. Без алардан Россияне начар ил дип хурлаганнарын һич ишетмәдек. Киресенчә, алар монда тату тормыш хөкем сөргәнен бик җылы итеп искә алалар иде. Хәзер әти белән әни безнең янга, Казанга кунакка еш килә, һәм бу – алар өчен чын могҗиза! Россиягә янә кире кайту, әле монда синагогага йөрү турында хыяллана ала идемени алар?

– Ә Казанга ничек килеп чыктыгыз?

– 90 нчы елларда Россия һәм дөнья арасындагы дивар җимерелде, монда дингә мөнәсәбәт тә тамырдан үзгәрде. Халыклар милли гореф-гадәтләрен торгызу теләге белән яна иде, ләкин ничек? Израильдә укуымны тәмамлап килгән чагым, булачак хатыным Ханна белән таныштым. Аның гаилә тарихы минекенә аваздаш булып чыкты. Өстәвенә, икебез дә Хабад – дөньякүләм яһүд хәрәкәте кыйммәтләрендә тәрбияләндек, шуңа күрә кешенең бу дөньяга тормыштан ләззәт алу өчен түгел, ә файда китерү өчен килгәнлеге турындагы фикер безгә якын иде. Язмышларыбызның охшашлыгында без күкләр тарафыннан билгеләнгән миссиябезне күрдек. Бергәләп Россиягә китәргә! Тик кайсы төбәккә? Әлеге карар Россиянең баш раввины Берл Лазардан инде. Ханна белән икәүләп аңа илнең теләсә кайсы почмагына чыгып китәргә әзер икәнлегебезне хәбәр иткәндә, миңа нибары 22 яшь иде. «О! Казанда җәмгыять бар, һәм аларга раввин кирәк!» – диде безгә Берл Лазар. Менә шулай итеп, монда төпләнүебезгә инде егерме ел узды.

> **Күптән түгел татар телен дә өйрәнә башладым. Бәлки, берәр елдан бу юнәлештәге уңышларымны да күрсәтә алырмын. Тел – безне берләштерүче ул. Кешеләр белән аларның туган телендә сөйләшү – бер-береңне аңлаудан югарырак, мөһимрәк нәрсә.**

– 90 нчы еллар – катлаулы чор. Ул вакытларда үзегезне ничек хис иттегез?

– Безнең өчен уңайлы чор булды ул. Мәхәллә безне бик җылы каршы алды, һәр минут үзебезнең кирәклегебезне тоеп яшәдек. Республика җитәкчелеге ягыннан да мөнәсәбәт уңай иде: «Монда булганыгыз өчен рәхмәт! Эшләгез һәм булдырыгыз!» – дип кабул итте алар. Шушы ике дистә елда мин бер уңайсыз мизгелне дә искә төшерә алмыйм.

– Әңгәмәбез бик матур синагогада уза. Яһүд мәхәлләсенең аны үзенә алу өчен көрәше бик озак барды, тик шулай да сез килергә бер ел кала, эш башкарылган иде. Ә сезгә монда нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килде?

– Казанда төп бәйрәмебез Песахны беренче тапкыр билгеләп үтүебезне бүген дә хәтерлим. 1997 елда синагогада бу бәйрәмгә алты йөз кеше җыелды. Аларның барысын да ашатырга кирәк, тик моны ничек тормышка ашырырга? Кошер ризык – яһүдиләрнең тормыш таләбе, Израильдә андый азык-төлекне теләсә кайсы супермаркетта сатып алырга була. Ләкин ул елларда Казанда бу зур проблема иде. Алдан ук Мәскәүгә барып, поездда берничә капчык туңдырылган тавык алып кайтырга туры килде. Бүген исә Казанда кошер ризыкны инде сайлап алу мөмкинлеге бар, ләкин барыбер эшлисе, яхшыртасы нәрсәләр җитәрлек әле. Бездә дә бары тик кошер азык-төлектән генә әзерләнгән ризыклар, хәтта конфетлар да сатып алырлык кибет булсын иде, дип хыялланам.

БЕРЛӘШТЕРӘ ТОРГАН ИМАН

– Россиядә яһүд диненә карата тискәре караш бармы?

– Бүген, әлбәттә, андый нәрсә күзәтелми. Без көнкүрештә дә, дәүләт системасы югарылыгында да моны сизгәнебез юк. Күптән түгел кибеттә бер кызык хәл булды. Касса янында балалар белән иврит телендә сөйләшеп, чиратта торабыз, шулчак бер гаиләнең безгә соклануы колакка керде. «Булдырасыз! Туган телегезне онытмыйсыз!» – диде алар.

– Ә рус телен җиңел өйрәндегезме?

– Кешене йөзәргә өйрәтү өчен иң шәп ысул – аны суга төртеп төшерү. Русчаны да мин әнә шулай өйрәндем. Шактый җиңел бирелде, дөрес, әнә шундый «тормышчан» ысул аркасында грамматика ягы җитенкерәми. Тик үз хаталарымны үзем күрәм, табам икән, бу инде билгеле бер югарылыкка ирешүдер, дип уйлыйм. Күптән түгел татар телен дә өйрәнә башладым. Бәлки, берәр елдан бу юнәлештәге уңышларымны да күрсәтә алырмын. Тел – безне берләштерүче ул. Кешеләр белән аларның туган телендә сөйләшү – бер-береңне аңлаудан югарырак, мөһимрәк нәрсә. Бу бер-береңбелән хис-тойгылар дәрәҗәсендә аралашу, бер-береңә мөмкин кадәр якын килү, дигән сүз.

– Әле хәзер дә халык арасында аерылып торасыз, ә 90 нчы елларда сезне күргән кешеләрнең кичерешләре нindiрәк иде?

– Чыннан да, мин шундук игътибарны җәлеп иттем. Аңлашыла да: мондый кыяфәттәге бердәнбер кеше идем калада! Бу хакта һичкайчан хафаландым, чөнки кешеләр кимсетеп, мыскыллап түгел, ә кызыксынып карый бит. Егерме ел эчендә миңа ияләшә төштеләр, өстәвенә тарафдарларым да пәйда булды. Шулай да урамга башкалардан бик аерылып торган килеш-кыяфәттә чыгу өчен никадәр кыюлык таләп ителгәнлеген күз алдыма китерәм. Шуңа күрә дини киемдәге мөселман кызларының эшкә яки университетка ашыгуын күргәндә, аларга карата хөрмәт хисе туа.

– Башка дин вәкилләре яисә атеистлар белән дуслыгыгыз бармы?

– Атеистлар беләнме? Һич проблема түгел, бик җиңел! Әледән-

Ольга Туманская
әзерләде

PRESSA.RU

әле сугышлар кабынып торган бу дөньяда, башка дин вәкилләре белән чагыштырганда, атеистлар белән аралашу кайчак җайлырак та. Әмма бездә, Татарстанда, тиңдәшсез вазгыять урнашты. Израильдәге барлык туганнарымны, таныш-белешләрне шаккатырган фотографиям бар. Рамазан ае тәмамлануга багышланган Гает бәйрәмендә төшерелгән иде ул. Безне анда мөфти чакырды, мөселманнарның изге йоласына ихлас хөрмәт тоеп, аларны бәйрәм белән котларга килдек. Дуслыгыбызны раслап, бер табында утырдык. Казаннан кала, тагын кайда раввинны меңләгән мөселман уртасында очрата алыр идегез? Гаиләбез белән синагогага барган вакытта, башка дин вәкилләренең үз гыйбадәтханәләренә юл тотуларын бик еш күрәбез. Бу бик матур манзара! Әйе, тормышка караш-мөнәсәбәтебез аерыла, ләкин безне бер нәрсә – Аллага ышану берләштерә. Иман безне яхшырта, камилләштерә. Бер-береңә хөрмәт саклар өчен бу бер сәбәп түгелмени?

ӨЕҢНЕҢ МЕНӘ ШУШЫНДА ИКӘНЕН ТОЮ МӨҺИМ

– Сез килгән генә чорда дин мәсьәләсендә илебез кара көйгән чүлне хәтерләтә иде. Беренче шытымнар баш төрткәнче, «җир»не озак эшкәртергә туры килдеме?

– Израильдә синагогага килгәч, әйләнә-тирәңдә меңләгән кеше күрәсең. Ә мин менә җомга киченда гыйбадәткә җыелырга кирәклеге хакында халык һич хәбәрдар булмаган Казанга килеп төштем. Ләкин минем бурыч – аларның йогынтысына бирелмичә, билгеле бер рухи дәрәҗәдә калу, вазгыятькә үзем тәэсир итү. Беренче вакытта үзем генә гыйбадәт кылдым, монда әллә ни куркыныч нәрсә юк иде, ник дигәндә, бүген син берүзең, ә иртәгә сиңа кемдер иярә, берсекөнгә – тагын берсе... Бу – мавыктыргыч процесс. Менә инде егерме ел да узып китә, янәшәңдә халык күбәйгән, һәм син үзеңә йөкләнгән бурычның акрынлап үтәлүен аңлыйсың. Бүген мәхәлләбез үсә, зурая, тик мин бу җиңүләрне, яуланган үрләрне үз хисабыма яздырып-теркәп куярга җыенмыйм, чөнки болар – зур бер төркемнең, һәм, әлбәттә, безнең попечительләр советының эш нәтиҗәсе.

– Яһүдләр арасындагы туганлык – уйдырмамы, чынбарлыкмы? Бездә, Казанда, бармы ул?

– Израильдә без күршеләребез белән хәтта бәйрәм көнне дә күрешә алмаска мөмкин. Ләкин безне берләштерердәй нәрсә юк дип уйлый күрмәгез, моның сәбәбе – һәркайсыбызның үз өендә булуы. Ә башка бөтен җирдә безгә уртаклыгыбызны, якынлыгыбызны тоярга кирәк, шунлыктан без, чыннан да, монда бер-беребезгә ныграк тартылабыз. Беләсезме, теләсә кайсы яһүд үзен борчыган мәсьәлә белән теге яки бу рәсми органга мөрәҗәгать итә ала, ләкин ешрак ул нәкъ менә безнең янга килә. Һәм бу аңлашыла да: җәмгыятьтә яшәвебезгә карамастан, һәрберебезнең якын даирәсе бар, ә үз кешеләр ярдәмсез калдырмый ул.

– Бу ярдәм нидә чагыла соң?

– Мәсәлән, калабызда өлкән яшьтәге яһүдләрне исәпкә алган база булдырдык. Шул исемлектәге теләсә кайсы әби мәхәлләгә шалтырата ала, һәм аңа шунда ук ярдәмгә кеше җибәрелә. Ләкин без үзебез дә, кешенең бәлагә тарыганын, авыр хәлдә калганын белми калмыйк дип, өлкәннәргә шалтыратып торабыз. Синагогада тулы бер офис шундый эш белән мәшгуль. Бу юнәлештә без йөз процент уңышка ирештек. Бу яктан караганда, бездә һәр көн 9 май кебек. Башка юнәлешләребез дә бар, анысы яшьләрне тәрбияләү белән бәйле. Мәхәлләбезнең яшь әгъзаларында җаваплылык хисе булдырырга телибез. Еш кына өлкән кешегә акча түгел, ә аралашу кирәк бит. Егет-кызларыбыз үзара адресларны бүлешеп ала да кучтәнәчләр белән кунакка бара. Ни өчен? Чөнки алар яһүдләр!

> Тиздән яңа уку елы башлана. Бер гаиләдә ялгыз әни кеше баласын мәктәпкә нинди акчага әзерләрмен икән, дип борчыла. Ә башка гаиләнең ярдәм итү мөмкинлеге бар. Безнең бурычыбыз – үзара ярдәмне җайга салу.

Яки башка бер үрнәк. Тиздән яңа уку елы башлана. Бер гаиләдә ялгыз әни кеше баласын мәктәпкә нинди акчага әзерләрмен икән, дип борчыла. Ә башка гаиләнең ярдәм итү мөмкинлеге бар. Безнең бурычыбыз – үзара ярдәмне җайга салу. Барлык яһүдләр дә үз йортларының менә шушында икәнен тоеп-аңлап яшәвен телибез.

БӘХЕТ ҺӘМ МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА

– Җәмәгатегез Ханна белән тормыш йөген инде 20 ел бергә тартасыз. Бәхетле гаилә сере бармы ул?

– Гореф-гадәтләребезгә салынган ул. Ләкин кайбер нәрсәләрне аерып күрсәтер идем. Шулхәтле балага ничек көч җиткерәсез дип, миннән еш сорыйлар, янәсе, монда берсен ничек үстерергә икәнен белмиләр, ә сездә – тугызау! Бу тормышка караш белән бәйле. Гадәттә, кыенлыкларның барысы да менә болай башлана: мин яшь кеше, хатыным да яшь, тыныч кына яшисебез, бергә ял итәсебез, сәяхәт кыласыбыз килә… Ә менә шулчакта бала бөтен планнарны бозып куя! Бездәге хәл-әхвәлне күз алдына китерә аласызмы? Берсе йоклап кына китә, икенчесе уяна, өченчесе… Һәм моның башы-ахыры юк. Көч каян киләме? Без бу елларны бала ләззәтен тою вакыты буларак кабул итәбез, ә ул чорда киләчәк буын өчен эшләргә, тырышырга кирәк. Моның өчен яшьлегебез, кәефебез бар. Менә алар үсеп җиткәч, без дә сәяхәт кыла алырбыз, бергә ял итәрбез, туйганчы йокларбыз… Үз-үзеңне шул рәвешле ышандыру тормышның һәр көне өчен шатлана белергә булыша. Гаилә бәхетенең икенче ягы ир белән хатын мөнәсәбәтләренә бәйле. Бүгенге яшьләр бер-берсенә никадәр туры килгәнлекләрен аңлау өмете белән бергә яшәп карарга тырышалар. Ә аннары: «Барысы да әйбәт кенә кебек, хәзер инде туй уздырсак та була», – дип уйлыйлар. Һәм кинәт күзләрдәге җанлылык сүрелеп китә… Баксаң, алар бит чынлап торып бергә яшәмәгән дә, бер-берсе каршындагы бурычларны тоймаган да, аңламаган да… Алар бер-берсен кайгыртырга әзер түгел. Ә мәхәббәт? Әйе, ул хакта барысы да сөйләгән була, тик бу хиснең асылда нәрсә икәнен бик азлар гына аңлый шул. Чын мәхәббәт вакытлар тарафыннан сыналган ныклы мөнәсәбәтләр ул, бу вакытта кешеләр – бер-берсенә чын партнёр, алар икәүләп нәрсәдер булдырганга күрә, тормыш юлында бергә бара. Һәм туй ул мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәсе түгел, ә уртак сәфәрнең башы гына.

– Мәхәлләнең яшь әгъзалары фикерегезгә никадәр игътибарлы? Сезнең сүзгә колак салаламы?

– Бүген кешеләр милли гореф-гадәтләребезгә көннән-көн ешрак мөрәҗәгать итә, һәм бу күренеш – хезмәтебезнең иң төп нәтиҗәсе. Әйтик, безгә дин кушканча туй уздыру гына түгел, гаилә тормышын да дин кануннары кысаларында корырга теләгән парлар килә. Мин – кияү кеше белән, хатыным кәләш белән әңгәмә кора. Ханна – минем партнёрым, без мәхәллә белән икәүләп җитәкчелек итәбез, шунлыктан хатын-кызлар белән бәйле юнәлешне ул алып бара. Без туйга әзерлек эшләрен бергәләп башкарабыз, ә Тәүрат, тормышыбыздагы барлык өлкәләрнең дә иң тирән төпкеленә ирешеп, иң катлаулы сорауларыбызга җавап бирә. Әйтик, ир белән хатын арасында мөнәсәбәтләрне ничек саклап торырга? Моның белән бәйле үз серләребез, үз нечкәлекләребез бар.

«БЕР СӘГАТЬКӘ ТЕЛЕФОНЫГЫЗНЫ СҮНДЕРЕП КАРАГЫЗ!»

– Дин бүгенге кешелек җәмгыятенең акылдан шаштырылык тизлегенә ничек тә булса яраклашамы?

– Әлбәттә, юк, ул үзгәрешсез кала. Динне кешеләр уйлап чыгармаган бит – аларга Хак Тәгалә сүзләрен пәйгамбәрләр ирештергән. Фәкать диннәрнең заманга туры килү-кил-



PRESSA.RU

> “ **Булачак уку йортында без лекцияләр һәм семинарлар уздырырга, гадәти уку-укыту ысуллары белән бергә иң заманча технологияләрне кулланырга ниятлибез.**

мәве, аның заманчалыгы мәсьәләсе, чыннан да, бик кызык. Бездәге гыйбадәт бүлмәсенә урнаштырылган плазма мониторга күз салыгыз. Без дөньяның башка шәһәрләрендәге яһүдләр белән скайп аша аралаша-сөйләшә алабыз яки, заманча технологияләр кулланып, төрле фильмнар күрсәтү мөмкинлегебез бар. Әмма шул ук вакытта дини гореф-гадәтләребездән бер адым да читләшмибез. Һәм бу эштә безгә заман алгарышы булыша. Чөнки лампаны шимбәгә кадәр яндырып куеп була, һәм ул янып торачак. Яки шундый прибор сатып алырга мөмкин, һәм ул кирәк чакта бу лампаны автомат рәвештә сүндерә дә, куша да ала.

Дин кешеләрне анык планлаштырырга өйрәтә, һәм ул тормыш рәвешенә әйләнә. Буыннан-буынга кешеләр, шимбә көнен бүләк иткән өчен, Аллага рәхмәт укый, һәм бүген бу рәхмәтләр аерым бер мәгънәгә ия. Көндәлек ыгы-зыгыда күпләребезнең хәтта хатынына күз салу өчен дә яки балалары белән сөйләшеп алу өчен дә вакыты юк. Ә сез бүген бер сәгатькә булса да телефоныгызны, компьютер, телевизорны сүндереп куеп, якыннарыгыз һәм дусларыгыз белән сөйләшеп алыгыз. Әйе, бу җиңел түгел, тик никадәр рәхәт! Ә хәзер әнә шундый аралашу, якынаю өчен тулы бер көнегез булуын күз алдына китереп карагыз. Шул рәвешле дин бүгенге тормышны һич тә кире какмый, ул аны бизи, тулыландыра гына.

– Яһүд мәхәлләсе өчен иң якын арада ни булдырырга теләр идегез?

– Безгә бүген ни җитми дигәндә, теләсә нинди югарылыктагы белем алырга мөмкинлек бирә торган үз Тәүрат үзәгебез юк. Безгә халык күп килә, гореф-гадәтләребез белән танышырга, динебез турында күбрәк белергә-өйрәнергә телиләр. Булачак уку йортында без лекцияләр һәм семинарлар уздырырга, гадәти уку-укыту ысуллары белән бергә иң заманча технологияләрне кулланырга ниятлибез. Бу проект җәй ахырында тормышка ашып, эшли дә башлар, дип уйлыйм. Тормышта әледән-әле туып торган сорауларына җавап эзләүче кешеләр бихисап бит, шуңа күрә безнең Тәүрат үзәге дә һәрвакыт тулы булсын иде, дип хыялланам.

Казань ✈ Франкфурт-на-Майне

Прямой рейс 2 раза в неделю*

Направление	Номер рейса	Время вылета	Время прилета
Казань – Франкфурт-на-Майне	SU 704	9:50	13:05
Франкфурт-на-Майне – Казань	SU 705	14:20	19:15

THE WORLD'S 4-STAR AIRLINE
Авиакомпания «4 звезды» Скайтракс

6+

По России бесплатно:
8 (800) 444-5555
*555 МТС, Билайн, Мегафон

www.aeroflot.ru

**Летнее расписание полетов действует с 26.03.17 по 28.10.17. Возможны изменения в расписании полетов. Узнать подробности и купить билеты Вы можете на сайте авиакомпании www.aeroflot.ru, в офисах собственных продаж и у агентов. Реклама. Сертификат эксплуатанта №1 от 17.11.2011. ПАО «Аэрофлот», 119002, Москва, ул. Арбат, д. 10, ОГРН 1027700092661. Реклама.*

Установите приложение:
App Store
Google Play
Скачать

PRESSA.RU

МАКС-2017: ТИЗРӘК, ЮГАРЫРАК, КӨЧЛЕРӘК

Хәрби самолётлар һәм граждан лайнерлары, вертолётлар һәм спутниклар, ракеталар һәм орбиталь станцияләр... Мәскәү янындагы Жуковскида 18 июльдә ачылачак МАКС-2017 Халыкара авиакосмик салонында авиация һәм космос тармагының бик күп өр-яңа казанышларын күрергә мөмкин булачак.

МАКС бик күптәннән һәм хаклы рәвештә дөньяның иң эре авиафорумнарыннан берсе дип санала. «Боинг» һәм «Ильюшин»нан башлап, «тар өлкәдә махсуслашкан» кечерәк предприятиеләргә кадәр – йөзләрчә фирма үз эшләнмәләрен биредә тәкъдим итүне зур дәрәҗәгә саный. Быел авиасалонда катнашучылар саны дүрт йөздән артып киткән, аларның уникесе – Татарстан предприятиеләре. Павильоннарда, стендларда һәм аэродромда – күптөрле оча торган техника үрнәкләре генә түгел, радарлар да, коммуникация һәм элемтә системалары да, авиатренажёрлар да, бүген авиатөзелештә кулланыла торган заманча материаллар һәм технологияләр дә бар.

Бирдә, Жуковскида, теләгән һәркем Казанда эшләнгән Ту-160 стратегик ракета йөртүчене һәм Ту-22М3 бомбардировщигын, Ми-8, Ми-38 һәм медицина модуле белән җиһазланган «АНСАТ» вертолётларын күрә ала. Россия экспозициясенә шулай ук МиГ-29СМТ, Су-30СМ, Су-35С истребительләре, Су-34, Ту-95МС бомбардировщиклары, А-50У ерактан радиолокацион тоюлы самолёт һәм башка хәрби һәм граждан техникасы куела.

Безнең һәм чит илләрнең яңа буын машиналарының ни дәрәҗәдә яхшы икәнлегенә күргәзмә көннәрендә инанырга мөмкин булачак. МАКС программасында – авиашоу һәм Россия һәм чит илләрнең атаклы пилот төркемнәренең күргәзмә чыгышлары каралган. Мәсәлән, Су-30СМ истребительләренең бишенче буыны мөмкинлекләрен һавада «Рус витязьләре» күрсәтәчәк. «Россия лачыннары» пилот төркеме уникаль очыш программасы әзерли.

Гади тамашачылар өчен МАКС – истә кала торган гаҗәеп күренеш. Әмма шулай да авиасалонны оештыручыларның төп бурычы күпкә җитдирәк. МАКС ул – чит илләрдәге партнёрларның алдынгы казанышларын файдаланып, уртак проектлар булдыру максатында Россиянең югары технологияләрен һәм эчке базарның ачыклыгын күрсәтү. Жуковскида белгечләргә һәм эшкуарларга күпбаскычлы контактлар булдыру, җитештерү корпорациясен алга таба үстерү һәм яңа партнёрлар эзләү өчен уникаль мөмкинлек тудырыла.

МАКС Россия Федерациясе Президенты химаясендә үткәрелә. Бу – оештыруның һәм вәкиллекнең югары дәрәҗәсенә гарантия булып тора, дип белдерә оештыручылар. Тагын әле Жуковскидагы авиасалон – үзенә күрә киләчәккә тәрәзә. Очу аппаратлары һәм хәрби комплексларның тәҗрибә үрнәкләрен, кайбер сәбәпләр аркасында чит илләрдә күрсәтеп булмый торган эксперименталь җайланмаларны бирдә генә күрергә мөмкин.

Фотолар МАКС Халыкара авиакосмик салоны рәсми сайтыннан.

ЫШАНЫЧЛЫ ПАРТНЁР

Соңгы берничә ел эчендә илебезнең оборона сәнәгате авиация тармагы предприятиеләрен тирән модернизацияләүгә ышанычлы юнәлеш алды. Әлеге процессларга илнең зур тәҗрибәгә һәм тиешле ресурсларга, шул исәптән прогрессив инженер кадрларына ия булган иң өлкән проект институтларын җәлеп итмичә, мондый киң күләмле проектларны тормышка ашыру мөмкин түгел. Аларның берсе – «Казан Гипронииавиапромы» АҖ – авиация сәнәгате үсешенә керткән зур өлеше һәм ирешкән хезмәт уңышлары өчен, быел РФ Президентының Рәхмәтенә лаек булды.

Әмма оештырылганыннан башлап һәм бүгенге көнгәчә авиация һәм сәнәгатьнең башка оборона тармагы предприятиеләрен модернизацияләү проектлары элеккечә үк «Казан Гипронииавиапромы» АҖ компанияләре төркеме эшчәнлегендә өстенлектә кала: «Берләштерелгән авиатөзелеш компаниясе» ГАҖ, «Берләштерелгән двигательләр төзү корпорациясе» АҖ, «Оборона сәнәгате» берләштерелгән сәнәгать корпорациясе» АҖ, «Россия вертолётлары» АҖ, «Радиоэлектрон технологияләр» Концерны» АҖ, «Тактик ракеталар белән коралланү» Корпорациясе» АҖ, «Алмаз-Антей» һава-космик оборона концерны» АҖ – «Казан Гипронииавиапромы» АҖнең төп заказчылары исемлеге әле болар белән генә чикләнми.

Тормышка ашырылган проектлар арасында – Казанда һәм Ульяновскида илебезнең перспективалы МС-21 һәм RRJ (РРДжей) самолётлары өчен наномодификацияле күмер композитларыннан «кара канат» җитештерү буенча ике завод проекты.

Сынау җиһазларын эре узеллы җыю буенча уртак Россия – Кытай предприятиесе булдырылган. Җиһазларны тулысынча Россиядә җитештерелгән детальләрдән җыю күздә тотыла.

«Казан Гипронииавиапромы» АҖ, генераль подрядчы сыйфатында, «АНПП «Темп-Авиа» АҖ (Арзамас), «Смоленск авиация заводы» АҖ, «УПКБ «Деталь» АҖ (Каменск-Уральск), Горбунов ис. КАҖБ (Казан) өчен корпусларны, «Климов» АҖ (Санкт-Петербург) өчен стендларны үзгәртеп кору эшләрен тәмамлады. Институт тарафыннан мондый киң масштаблы эшләрне башкару әлеге предприятиеләргә, бер үк вакытта импортны алыштыру принципларын да тормышка ашырып, дәүләт оборона заказларын үтәүне тәэмин итү мөмкинлеген бирә.

«Казан» аэропортын модернизацияләү – институтның тагын бер уникаль проекты, ул халыкара аэропортны Skytrax* һәм «Авиапорт» версияләре буенча Россия һәм БДБ илләренең иң яхшы төбәк аэропорты буларак таныткан заманча аэровокзал комплексына әверелдерде, аэропорт шулай ук Skytrax рейтингында дүрт йолдызга һәм «Россиянең һава капкалары» милли премиясенә ия булды.

Бүгенге көндә институт эшчәнлегенең реаль нәтиҗәләре аның шушы елларда күрсәткән хезмәтләренең һәрвакыт ихтыяҗга ия һәм әһәмиятле булганлыгын раслый. Институтның һәм башка структураларның проектлаучылар коллективы иң катлаулы инженерлык мәсьәләләрен дә хәл итәргә сәләтле югары квалификацияле белгечләрдән тора. Ул теләсә нинди катлаулылыктагы эшләргә тотынырга һәм аларны намус белән башкарып чыгарга әзер булуын инде күп тапкырлар эштә раслады, һәм шуның нәтиҗәсендә тотрыклы һәм ышанычлы партнёр абруен яулады.

Реклама

* Скайтракс

PRESSA.RU

БИЕКЛЕКТӘ КОТКАРУ

Авиация техникасын җитештерүчеләр белән чиктәш юнәлешләрдә эшләүче компанияләрнең казанышлары еш кына дәүләт һәм ММЧның игътибар үзәгендә булган эре җитештерүчеләр күләгәсендә кала. Юк, тармак өчен түгел, киң җәмәгатьчелек өчен. Казан агрегат заводының баш конструкторы Леонтий Карась «Татарстан»га компаниянең Россия авиациясенә яңа җиңүләр яуларга ничек ярдәм итүе турында сөйләде.

– Предприятиегез продукциясен эшләп чыгаруның үзенчәлеген, уникальлеген искә алып, җитештерүне хаклы рәвештә инновацион дип атарга мөмкин. Әлеге югары дәрәҗәгә ирешү өчен нәрсә таләп ителә?

– Тәҗрибә. «Инновацияләр» дигән термин Татарстанга биш ел элек килеп керде, һәм мин үзем дә әлеге төшенчәнең асылын бик үк аңлап бетерми идем әле. Продукциянең яңа төрләрен уйлап чыгаруны, сынауны һәм әзерләүне аңлата икән. Ягъни без инде 20 ел буена шөгыльләнгән эшне. Башта – Казан электромеханика заводы базасында, аннары Казан вертолёт заводында без Ми-8, Ми-38, «Ансат» тибындагы вертолётлар өчен кайбер техника төрләренең беренче тәҗрибә үрнәкләрен әзерләдек.

– Бүгенге көндә завод Россиядә дә, дөньяда да авиация өчен медицина модульләре тәэминатчысы буларак танылды. Сез ничек бу юлга чыктыгыз?

– 2000 нче елларның икенче яртысында без оча торган госпиталь буларак җитештерелә торган вертолётларны җиһазлау өлкәсендә «ХелиКО Групп» вертолёт компаниясе белән хезмәттәшлек иттек. Әмма мондый вертолётларны турыдан-туры куллану ихтыяҗы булмаганга күрә, аларның күбрәк эшсез торулары ачыкланды. Без бу хәлне алып куела торган медицина җиһазлары үзгәртә алыр, дигән фикергә килдек. Эшне Ми-8, Ми-8МТ тибындагы вертолётларга югары нәтиҗәле аппаратура, шул исәптән үпкәләрне ясалма вентиляцияләү аппаратын урнаштырудан башладык. Безнең «сигезле» катлаулы шартларда зыян күргән кешеләргә ярдәм күрсәтү өчен оча торган реанимобиль буларак кулланыла иде. Көтмәгәндә бу эшкәртмәбез трендка әверелде. Шунда ук Россия Оборона министрлыгыннан шундый модульләр белән Ил-76 самолётларын җиһазларга дигән заказ килде. Бүгенге көндә без аларга дүртәр урынлы 5 модуль урнаштырабыз. Ми-8МТга – икешәр урынлы ике модуль. Һәм төрле санда берәр урынлыны – «Ансат», Ми-8, Ка-226 вертолётларына, Ан-148, Sukhoi Superjet* 100 һ.б. самолётларга. Хәзерге вакытта без шундый ук медицина модульләрен техниканың башка төрләренә урнаштыру буенча эш алып барабыз. Төрле министрлыклар, ведомстволар, аеруча ГТХМ белән тыгыз хезмәттәшлек итәбез.

– Бу модульләрне куллану ярдәмендә коткарылган кешеләрнең саны буенча статистика бармы?

– Бу җиһазлар куелган самолётлар һәм вертолётлар бөтен ил буенча һәм аннан читтә дә оча. Теләсә кайсы гадәттән тыш хәлләр вакытында, әйтик, «Хромая лошадь»тагы янгын, Израильдә автобус каплану һ.б. шундый хәлләрдә, ягъни фаҗига урынына бик тиз килеп җитәргә яки ерактагы медицина үзәгенә эвакуация ясарга кирәк булганда, алар бик тә нәтиҗәле. Төрле исәпләүләр буенча, безнең модульләрдә өч меңнән артык кешене алып чыкканнар. Шунысы игътибарга лаек: җиһазларны ун ел куллану дәвамында транспортировка вакытында кешеләрне югалту булмаган.

– Белүемчә, «Ансат» вертолёты белән бер «җыелма»да Казан агрегат заводында җитештерелүче җирдә хезмәт күрсәтү чаралары да гамәлгә кертелә. Бу аерым юнәлешме?

– Казан агрегат заводы 20 елдан артык вакыт дәвамында Ми-8

Реклама

* Сухой Суперджет

(Ми-17), Ми-38, «Ансат» тибындагы вертолётлар өчен җирдә хезмәт күрсәтү чараларын (СНО) эшкәртә, әзерләп чыгара һәм сыный, шулай ук алар белән Казан вертолёт заводын, ХһК һәм граждан авиациясенә хезмәт күрсәтү бүлекчәләрен тәэмин итә. «Ансат» вертолёты өчен безнең тарафтан СНОның 50дән артык төре эшләнде, әзерләп чыгарылды һәм сыналды. «Ансат» вертолётына хезмәт күрсәтү өчен компактлылыкның, энергиядән бәйсезлекнең һәм мобильлекнең яңа принциплары салынган. Бу принциплар вертолётка һәм аның системаларына техник хезмәт күрсәтү вакытын кыскартырга, кече габаритлы җиһазлардан файдалану исәбенә хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшыртырга, һәм шулай ук техник хезмәт күрсәтүне башкарырга, сыек һәм газ ягулыгы салуны һәм ягулыкны өстәүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. Бу вакытта гомуми кулланыштагы СНОдан файдалану зарурлыгы кими. Әйтик, без ягулык һәм май системаларына ягулык салу өчен заманча җиһазларны гамәлгә кертәбез. Аларның өстенлеге – конструкциясендә, ул ябык килеш ягулык салуны һәм ягулык өстәүне, сыеклыкларны агызуны, шулай ук сыеклыкларның һәм бу системалар эшенең чисталыгын тәэмин итә. Хәзерге вакытта без СНОларны «Камов» АҖ вертолётларына, һәм шулай ук Арктика зонасы шартларында эшләүче вертолётларга яраклаштыру буенча эшләр алып барабыз.

– Сезнең коллективның юл башында автокраннар һәм күтәрү механизмнары белән бәйле эшләр бар иде. Бу тарихның дәвамы бармы?

– Без бу тематика белән яхшы таныш. Авиация техникасына хезмәт күрсәтүдә куллану максатында без эшләгән беренче күтәрү механизмнарының берсе булып СПК-3 краны тора. Җыелган хәлдә ул Ми-8 тибындагы вертолётларда күчереп йөртелә ала һәм вертолётның барлык агрегатларын монтажлау һәм сүтү өчен автоном кыр шартларында кулланыла ала.

– Ә «спиртта» эшли торган нинди легендар җайланма ул?

– УПЭД-3 – двигательне юдыру һәм эмульсияләү җайланмасы. Ләкин ул спиртта түгел, шулай да челтәрдән эшли – өстәвенә, борттагы челтәрдән. Аның тарихы гаять кызыклы: якынча 40 еллап элек, ТВ3-117 двигательле Ми-14 вертолётын диңгез шартларында кулланганда, двигательнең эчке юнәлешле аппараты калакларында коррозия ачыкланган. Безнең тарафтан двигательне юдыру һәм эмульсияләү җайланмасы проектлаштырылды. Юдыргыч сыйфатында эмульгатор кушылган су кулланыла – һава температурасы – 5 градуска кадәр булган шартларда. Ә менә түбәнрәк температурада нәкъ менә 40–60%лы спирт эремәсе кулланыла. ТВ3-117 һәм ВК-2500нең яңа модификацияләрендә дә двигательгә юдыргыч салу урыны шундый ук булганга, әлеге җайланманы куллану белешмәлеге кертелде, һәм шулай җайланма белән дә тәэмин ителә.

– Җирдә хезмәт күрсәтү чаралары юнәлешендә эшләр ничегрәк тора?

– Хәзер, мәсәлән, без ААО-1 аэродром хезмәте агрегатын эшләдек һәм әзерләп чыгарабыз. Бу агрегат Ми-8 тибындагы вертолётларны, «Ка» сериясе вертолётларын һәм башкаларны ток астында эшләтүне, гидросистемаларның эшен тәэмин итә, вертолёт салонын кондиционирлаштыруны башкара һәм ЗИЛ шассиена урнаштырылган мораль яктан искергән җиһазларны (хәрәкәт итүче аэродром агрегатын, гидросистеманы тикшерү җайланмасын, унификацияләнгән җылыткычны) алыштыра. Әлеге агрегат компактлылык, энергиядән бәйсез булу һәм мобильлек принципларына туры килә. Хәзерге вакытта бу җайланманы самолётларга яраклаштыру буенча эшләр алып барыла.

– Предприятие бу кадәр киң ассортиментны ничек үзләштерә алды? Даими камилләшү шактый инвестицияләр таләп итсә дә, сез нинди дә холдинг яисә корпорациянең бер өлешенә әверелмичә, бәйсезлегегезне ничек саклап кала алдыгыз?

– Хәзерге вакытта 300дән артык кеше эшләгән Казан агрегат заводы – шактый мөстәкыйль компания. Бу күбесенчә безнең үз вакытында коллективны югары классны белгечләрдән туплый алуыбызга бәйле. Моннан тыш, без серияле булмаган һәм күп хезмәт таләп иткән юнәлешләр белән шөгыльләнәбез, ә ул эре предприятиеләрдә кызыксындыру уятмый. Шулай ук без алдынгы дөнья тәҗрибәсен өйрәнәбез, шуңа юнәлеш тотабыз.

– Күп нәрсәләрне куллана аласызмы?

– Без һәрвакытта да чит ил җитештерүчеләре юлыннан бармыйбыз. Күп очракларда безнең алар белән юлларыбыз төрле. Шул ук медицина модульләре: күп илләр, ни дисәң дә, махсус кулланылыштагы самолётлар һәм вертолётлар җитештерә. Ә бездә бер үк очу аппараты күп төрле бурычларны хәл итү өчен кулланыла. Әгәр дә нинди дә очу аппаратын медицина максатында куллану турында команда бирелә икән, андый очракта аңа безнең модульләрне кыска вакыт эчендә урнаштырып була.

– Сезнең коллектив алдына киләчәккә нинди бурычлар куела?

– Беренчедән, бу – очу аппаратларының башка типларына техник хезмәт күрсәтү системаларына хезмәтнең сыйфатын яхшырта торган компактлылык, энергиядән бәйсезлек һәм мобильлек принципларын кертү. Икенчедән, башка типтагы һава транспорты, һәм шулай ук җир һәм су транспортлары өчен авиамедицина технологияләрен эшләп чыгару һәм кертү. Өченчедән, санитар авиациядә, мегаполисларда һәм транспорт челтәрләрендә авиамедицина технологияләрен куллану планнарын эшләү.

КАЗАНСКИЙ АГРЕГАТНЫЙ ЗАВОД
420127, Казан ш.,
Дементьев ур, 2В йорты.
Тел.: (843) 237-95-56,
факс: (843) 237-95-56 (доб. 180)
E-mail: info@vysota.aero

БАРЫСЫ ДА ҖАН АТА!

Конфедерацияләр кубогы көннәрендә Казан экзотикага кинәнде һәм берничә уен өчен дистә меңнәрчә чакрым юл үтеп килгән футбол җанатарларын кабул итте. Без дә вакыйгаларның үзәгендә кайнадык һәм кемнәр соң алар – хыялый кешеләр һәм каһарманнар, дип кызыксындык...



Автор:
Ксения Сёмина

ИКЕНЧЕ ДӘРТ

Җанатарлар психологиясе өлкәсендәге теоретик бушлыкны тутырмакчы булып интернетка керәм. «Җанатар» дигән сорауга Википедия мондый җавап чыгара: «фанатлар», аннан соң – «футбол хулиганнары» һәм, ниһаять, «ультрас». «Ультрас – спорт командаларына, бигрәк тә футбол клубларына теләктәшлек белдерү өчен җанатарлардан оештырылган төркемнәр», – дип хәбәр итә энциклопедия. – «Көньяк Америкада ультраслар «БарраБравас» дип атала». Иң килештерә алмастай «БарраБравас»лар булып Колумбия, Чили, Бразилия, Мексика җанатарлары тора...

Бәхеткә, Fan-ID идентификацияләү карталары системасы иң үҗәт «ультрас»ларны иләк аша уздырды – «кычкырып торган» үткәне булган фанатлар «Җанатар паспорты» ала алмады. Шулай яхшырак та булды әле: димәк, чын фанатларга олы футбол уеннарыннан ләззәт алырга бирәү дә комачауламаячак. Ә миңа – бөтен кыйтгаларда да миллионнарча кешеләргә «йоккан» әлеге «авыру»ның үзенчәлекләре турында күбрәк белергә.

Казан Кремле. Чит телдә бу кадәр күп сөйләшкәннәрен Кремль диварлары Казан ханлыгы чорыннан бирле ишетмәгәндер. Шау-шулы Мексика, Чили кешеләре һәм тыныч европалылар агымында бөтенләй югала язган хәлдә Fan-ID картасына чит ил кешесе икәнлеге язылган беренче очраган затны туктатам. Гвадалахарадан (Мексика), Эрнесто исемле.

– Ә сез нигә Мексика эшләпәсе белән пончодан түгел? – дип сорыйм Эрнестодан, аның дустанә мөнәсәбәтенә тәмам инангач.

– Бу мариачи гадәте, Мексика мәдәниятенең визит карточкасы. Әмма мин Америка белән

Британия музыкасын тыңлап үстем, миңа бик якын түгел ул, – дип аңлата Эрнесто.

Волонтер-тәрҗемәче кыз аңа инглиз телендә Кремль тарихын сөйли. Эрнесто кызыксынып тыңлый. Кол Шәрифкә керәбез. Эрнесто мәчетнең пыяла куб эчендә әйләнеп торучы кыйммәтле металлардан эшләнгән нөсхәсен күзәтә.

– Биредә бик матур. Соклангыч, – дип елмая Эрнесто. – Мин моны сатып ала аламмы? – ди ул ялык-йолык килеп торган бәләкәй Кол Шәрифкә күрсәтеп.

Ул үзенең яраткан командасы белән финалга кадәр барырга хыяллана.

– Сез футболга гашыйкмы? – дип сорыйм аннан.

– О, әйе! Хатын-кызлардан соң икенче урында ул минем өчен, – дип елмая Эрнесто һәм ике ел үзенең дә Мексикада икенче лиганың футбол командасында менеджер булып эшләве турында сөйли. Ләкин бу эшнең кадере юк ди ул, шуңа да хәзер текила җитештерү белән шөгыльләнә.

Үзе белән нинди тәэссоратлар алып кайтып китә икән?

– Хәзер инде мин Татарстан турында күп нәрсәләр беләм. Аңлавымча, республиканың үз икътисады бар, һәм ул әйбәт. Мин монда төрле диндәге кешеләрнең тыныч яшәвен күрдем. Элек мин Россия турында анда яшәве авыр, ул дошмани, агрессияле ил дип уйлый идем. Хәзер исә мин бөтенләй башка фикердә.

МОНДА РОНАЛДО ГЫНА ТҮГЕЛ

Яшь мексикалылар төркеме очрый – милли командаларына җан атар өчен килгәннәр.

– Минем монда берничә ел элек булганым бар иде, Казан үзгәргән шуннан соң. Кунакчыллыгы арткан. Һәм менә бу ике мәдәниятнең үзара килешеп яшәве – безнең өчен берникадәр шок, – дип сөйли миңа яшьләрнең берсе инглиз телендә.

– Казан нинди дә булса икенче бер шәһәргә охшаганмы, – дип сорыйм. Бәләкәй генә бәхәс булып ала. Берсе Көнчыгыш Европа белән чагыштыра. Икенчесе: юк, юллар Латин Америкасындагы кебек, ди. Һәм газоннар…

– Татар кухнясын авыз итеп карадыгызмы әле? – дип сораштырам.

– Шашлык! – дип шатланып баш селки берсе.

– Алар бүген генә килделәр әле, барысы да алда, – дип елмая тәрҗемәче.

Казансу яр буенда Россиядән килгән җанатарларны очратам. Безнең җыелма командага теләктәшлек белдерү өчен Самарадан бөтен гаиләләре – әниләре, әтиләре, кызлары белән килгәннәр.

– Төпчек кызыбыз былтыр футбол уйный башлады, без дә әкрен-әкрен футбол фанатларына әйләнеп барабыз, – ди әниләре Светлана. – Роналдоның уйнаганын күрдек, әмма күңелдәгедәй булмады. Аның каравы турнирдан алган тәэссоратлар барысы да уңай! Португалия җыелма командасының тренеры безгә автограф бирде! Мин кызыма аны Роналдоның автографына караганда да әйбәтрәк, дип аңлаттым. Кызым бик борчылган иде. Киләсе елдагы дөнья чемпионатын түземсезлек белән көтәбез. Мөмкинлек булса, янә Казанга киләчәкбез. Безгә монда бик ошый.

– Күрәсең, Конфедерацияләр кубогы казанлылар өчен – мөһим вакыйга. Дөресен генә әйткәндә, мин бу дәрәҗәдә оештырырлар дип көтмәгән идем, – ди мәскәүле Джам Мирзоджонов. – Дөнья чемпионатына туганнарым белән – команда булып киләчәкбез.

Конфедерацияләр кубогы вакытында Казаннан китәргә кирәкми, дип белдергән иде Татарстанның спорт министры Владимир Леонов алдагы көнне, һәм ул хаклы булган. Матч саен шәһәрдә нindидер карнавал тойгысы, яхшы мәгънәсендә шашыну көчәя барды. Мексикалыларның хисләр ташкыны тынарга өлгермәде, Казанны

– Дөнья чемпионатына туганнарым белән – команда булып киләчәкбез, – ди Джам Мирзоджонов.

PRESSA.RU

– Ә фанатлар өчен иң мөһиме: хисләр һәм голлар. «Сөрән» – алар өчен бик көчле энергия. Уенчылар аларны ишетәме икән? Әйтүе кыен, – ди Пабло Маркес.

Чили дәрте басып алды. Германия белән Чили җыелма командаларының матчы көнне Бауман урамында бәйрәм булды.

ОЧРАШУ УРЫНЫ – КАЗАН

Чили җанатараларының беренче төркеме минем инглиз телемне аңламады. Куллар белән генә аларның «сөрән»нәрен язып алырга теләвемне аңалатам. Алар ризалаша.

– Чи-чи-ле-ле-ле, вива, вива, Чиле! – дип җырлап бирә алар, һәм урамның икенче башында шундый ук җөмлә белән җавап кайтаралар.

– Мин Сантьяго радиосында эшлим, Россиягә сәяхәт кыларга уйлавымның сәбәбе шул: кубок тамашалары бик кызыклы булырга охшаган иде. Футбол – хис-кичерешләргә бай спорт. Стратегия һәм уен схемалары футболны белгән кешеләр өчен кызык, – дип сөйли Чилидан килгән Пабло Маркес. – Ә фанатлар өчен иң мөһиме: хисләр һәм голлар. «Сөрән» – алар өчен бик көчле энергия. Уенчылар аларны ишетәме икән? Әйтүе кыен. Сезнең стадионнар шундый зур... Ләкин бездә Чили гимны бар, һәм бу җырны җанатарлар да, уенчылар да башыннан ахырына кадәр җырлый, чын йөрәктән.

Төрле телләрдә сөйләшә торган җанатарлар арасыннан немецларныкын аерып алу җиңелләрдән булмады. Ниһаять, Ремарк каһарманнарына охшаганнарын табып алам.

– Мин – Франкфурттан. Монда ничек килеп эләктемме? – Ян дустына күрсәтә. – Кристиан ике билет сатып алган да: «Без Казанда очрашырга теләмибезме?» – дип шалтыратты. Башта: «Син акылдан язгансың!» – дидем. Соңрак аңладым, шәп идея бит! Ул Чилида яши, мин – Германиядә, һәм менә без – монда. Мин Казан турында берни дә белми идем,

Немец җанатарлары Ян һәм Кристиан Казанда очрашканнар.

“ – Мин – Франкфурттан. Монда ничек килеп эләктемме? – Ян дустына күрсәтә. – Кристиан ике билет сатып алган да: «Без Казанда очрашыйкмы?» – дип шалтыратты. Башта: «Син акылдан язгансың!» – дидем. Соңрак аңладым, шәп идея бит!

– Мисыр өчен җан атам, – дип елмая әңгәмәдәшем. – Монда мин футболны яратканга килдем. Бик гади!

бик кызыклы шәһәр булып чыкты. Мәскәүгә караганда рәхәтрәк монда. Волонтерларыгыз молодец! Кызганыч, безгә карталарның һәм юлкүрсәткечләрнең инглиз телендәгесе калмаган. Татарча һәм русча сөйләшергә өйрәнмәдек әле...

КЫЙТГАЛАР АША

Үземне футбол карнавалында чын-чынлап катнашучы итеп тою өчен Чили һәм Португалия җыелма командалары финалга чыгабыз дип уйнаган матч көнне «Казан-Арена» стадионы тирәсенә киттем. Стадионга кадәр йөри торган автобустан төшеп калгач, башкалар белән бергә «соңгы миль» – транспорт хәрәкәтеннән азат булган ярты чакрымлык араны җәяләп узабыз.

Гаҗәп бит: шатлыклы, дәртле ыгы-зыгы безнең тигез булмаган колоннабызда адым саен көчәя бара. Үз образларына тулысынча кереп беткән волонтерлар Чили җанатарларын күрүгә «чи-чи-ле-ле» диләр һәм ни өчендер Пуэрт-Рико җырчысы Луис Фонсиның «Despacito» хитын җырлап җибәрәләр. Чили фанатларына бу әллә ни тәэсир итми – сәламләүләрнең барысына да алар бер төрле итеп җавап бирә.

Төркем арасында «74. Never forget» дигән язу тоткан егетне күреп алам. Ул мисырлы булып чыга.

– Ни өчен 74?

– Биш ел элек Мисырның «Әл-Масри» һәм «Әл-Әхли» командалары арасындагы матчта фанатлар бәрелеше булды, нәтиҗәдә безнең клубның 74 җанатары һәлак булды. Мин бу язуны һәрвакыт үзем белән йөртәм, без аларны беркайчан да онытмаячакбыз – белеп торсыннар, – ди егет.

– Кем өчен җан атачаксыз бүген? Чилиме, Португалиядме?

– Мисыр өчен, – дип елмая әңгәмәдәшем. – Монда мин футболны яратканга килдем. Бик гади!

Fan-ID бирелә торган тирмә янында Чили җанатарлары милли киемнәреннән басып тора. Алар белән фотога төшәргә теләүчеләрдән чират тезелә – Көньяк Америка җанатарлары баш тартмый. Араларындагы иң яшенә сүз катам. Аны һәм юлдашларын шундый ерак аралар үтәргә нәрсә мәҗбүр итте, дип сорыйм.

– Җыелма командабыз безнең өчен бик мөһим. Ул беренче тапкыр Конфедерацияләр кубогында катнаша. Һәм моны, әлбәттә, күрми калырга ярамый! – ди Родриго. Ул да, иптәшләре дә Чилиның төньягында урнашкан Антофагаста шәһәреннән. Аннан алар Сантьягога килгән, Сантьягодан Барселонага очкан, Барселонадан – Мәскәүгә. Һәм менә өч атна инде Родриго һәм аның иптәшләре Россия буйлап сәяхәт итә, үзләренеке өчен җан ата.

– Сезнең команда җиңелсә, нишләячәксез? Елыйсызмы? Эчәсезме?

– Бәлки, еларбыз, – дип елмая Родриго. – Ләкин алар җиңелмәячәк!

Мин стадион каршында җырлый, шатлана, могҗиза көткәндәй уенны көтә торган халык агымы арасында тагын бераз басып торам. Мондый энергияне бер дәрт, бер идея белән берләшеп хәрәкәт итә торган кешеләр генә булдыра ала. Ниһаять, җанатар булуның ни икәнен аңлыйм. Син бер телдә сөйләшә торган бербөтеннең өлешенә әйләнәсең, энергия алмашында катнашасың икән. Шушы энергия аркасында Казан, ФИФА президенты Джанни Инфантино Татарстанның башкаласын «әретү казаны» дип атаганча, берничә көн хисләр ташкынынан кайнап торды.

Алар китте, ләкин кайтырга дип китте. Бер елдан соң.

Көньяк Америка җанатарлары белән фотога төшәргә теләүчеләр чиратка тезеләләр.

PRESSA.RU

Михаил Рокицкий – медицина фәннәре докторы, профессор, Россия табигать фәннәре академиясенең мөхбир-әгъзасы. Балалар хирургиясенең Казан мәктәбенә нигез салучы. РФ халык депутаты, РФ өченче һәм дүртенче чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты.

ЯЗМЫШЫ — КЕШЕЛӘРНЕ КОТКАРУ

Кайчак хирург, калганнар инде чигенгәч кенә, чиргә каршы көрәшкә күтәрелә торган соңгы сугышчы булып чыга. Татарстанлыларның берничә буынының сәламәтлеген саклап калган Михаил Рокицкий үзенә 85 яшь тулган елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнде.

Автор:
Ксения Сёмина

ХИРУРГЛАР НӘСЕЛЕННӘН

Һөнәри язмышым алдан ук билгеләп куелган булгандыр: 1931 елда табиб-профессорлар гаиләсендә дөньяга килгәнмен. Үги әтием дә (әлеге искиткеч яхшы кешегә карата җылы мөнәсәбәтемне чагылдырып бирә алган сүз юктыр телебездә) — хирург-профессор, сугыш башлануга Әстерхан медицина институты кафедрасына чакырыла. Без Ленинградтан блокада башланганчы китәргә өлгердек, бу гомеребезне саклап калды.

Әстерханда тәүге тапкыр үлем белән күзгә-күз очраштым. Немец самолетлары ташлый торган «уткабызгычлар»ны сүндерү өчен, малайлар белән өй түбәсенә мендек. Шунда бер малайның башына зенит снаряды кыйпылчыгы эләкте. Ул малай шунда ук үлде.

«БАШТА ҺУШЫМНЫ ЮГАЛТТЫМ»

Медуниверситетның икенче курсында үземнең хирург булырга теләвемне аңладым. Тәүге тәҗрибәм шактый кызык килеп чыкты: үги әтием мине операциягә карап-күзәтеп торырга чакырды. Барысы да үз көенә бара иде, тик ул кечкенә чүкеч белән пациентның башын тишә башлагач, һуштан яздым. Миннән бөтен гаиләбез көлде. Һәм шуннан соң мин шәһәр хастаханәсенә дежурлыкка йөри башладым. Башта хирурглар миңа кушеткада йокларга тәкъдим итте. Аннары — идән юарга. Ниһаять, миңа операциядә катнашырга рөхсәт бирделәр, тиешсезрәк урынга тыгылганда, бармакларыма пинцет белән сугалар иде.

Институтны кызыл дипломга тәмамладым. Шигърият, нигездә, сатирик шигырьләр ул вакытта җаным-тәнем белән бирелгән тагын бер шөгылем булды һәм хәзер дә шулай булып кала. Институтта без булачак хирург Геша Грачёв белән конферанс оештыра идек, юмористик миниатюралар куйдык. Мәсәлән, Яңа ел кичәләренең берсендә тулай торакта су булмау турында менә нәрсә сөйләдек:

«Но мы надеемся, что в этот новый год
На каждом этаже весомо, грубо, зримо
В быт общежития войдёт водопровод,
Сработанный ещё рабами Рима».

ЯШӘҮ ӨЧЕН КӨРӘШ

Һәр кешенең тормышында үз остазы булуына ышанам. Шәрыктәге мөритләрнең шәехе булган кебек. Профессор Сергей Леонидович Либов минем өчен нәкъ шундый кеше булды. Ул һөнәри тормыш юлымны билгеләүчеләрнең берсе иде, хирургның нинди булырга, әдәбиятны ничек укырга-өйрәнергә тиешлеген, операцияне ничек ясарга, үзеңнең һәм башкаларның хаталарын ничек тикшерергә кирәклеген үз үрнәгендә төшендерде. 50 нче еллар ахырында Либов белән бергә Минскига юл тоттым, шунда ул оештырган балалар торакаль хирургиясе кафедрасында 7 ел эшләдем.

Бу елларда дөньяны куркыныч йогышлы авыру — үпкәләрнең стафилококклы үлекле шеше дер селкетте. Бу чир бик еш сабыйларга йога, бик тиз аяктан ега иде. Эренле үлек үпкә тукымасын «ашап кирә», кан

китә. Аннары — үлем. Яңа туган нарасыйлар арасында үлем-китем 90 %ка җитә. Моның сәбәбе — илебездә җитештерелгән антибиотикларның көчсезлегендә: бу дарулар инфекцияне җиңү түгел, организмдагы сәламәт микрофлораны юк итеп, стафилококка тагын да җәелеп китәргә юл ача иде. Бу тема белән шөгыльләнеп, мин балаларда үпкәне өлешчә кисеп алу турында докторлык диссертациямә материал тупладым.

Белоруссиядән соң Мәскәүгә – министрлыкка юл тоттым. Балалар хирургиясе кафедралары ачыла башлаган гына чак. Миңа Төмәндә, Ярославльдә, Казанда яки Свердловскида шундый кафедраны җитәкләргә тәкъдим иттеләр. Мин Казанны сайладым һәм, шөкер, бер мәртәбә дә үкенергә туры килмәде.

КӨЧӘЙГӘН ВАКЫТТА ЯРДӘМ

Ләкин 1967 елда әле барысы да башлана гына иде. Казанда махсус балалар хирургиясе бөтенләй юк, җирле хирурглар яңалыкны шатланып каршы алды: ниһаять, эчке органнарына операция таләп ителгән шушы балаларның барысын да үз өстенә алачак юләр табылды бит. Иң әүвәл, мин ашыгыч балалар хирургиясен булдыру мәсьәләсен күтәреп чыктым, һәм үпкәләрен үлекле шеш тишкән балаларны безгә бер-бер артлы ташый башладылар.

Дөньяда беренчеләрдән булып, без стафилококк деструкциясенә ялкынсынуның иң көчәйгән вакытында, процессның тотрыклылануын көтеп тормыйча, операция ясый башладык. Шул рәвешле үлем очракларын 25 %ка киметтек. Мәскәүлеләр белән бергәләп, ялкынсынудан соң калган куышлыкны ябыштыруның берничә ысулын эшләдек. Мин стафилококк деструкциясе турында ике китап яздым, унике халыкара конгресста чыгыш ясадым.

Кешедә эшләргә теләк булганда, эш, яңалыкны өйрәнү теләге белән янган башка кешеләрнең дә аңа тартылуына үз тәҗрибәмдә инандым. Бездәге субординатурада ике грузин егете бар иде. Институт тәмамлагач, алар Лениногорскига китеп бардылар, анда балалар хирургиясе бүлеге ачтылар һәм ярты ел коры рәхмәткә эшләделәр, чөнки штатта ставка юк иде. Ләкин энтузиазм дигән нәрсә дә бар бит. Боларны искә төшерү бик рәхәт.

Ул чорда биш республика өчен Казанда республикаара балалар хирургиясе үзәге оештырылган иде. Без анда барып та эшләдек, Татарстан буйлап та йөрдек. Хезмәтебез хакында бөтен Союз дәрәҗәсендә дә, чил илләрдә дә белделәр. Бездә табибларны «тәрбияләү», балалар хирургия хезмәтен оештыру эшенә бик зур игътибар бирелә иде. Ул вакытларның кайтавазы хәзер дә ишетелә – күптән түгел шәкертем Владимир Подкаменевка инде икенче тапкыр «Призвание» премиясен тапшырдылар. Аның улы — Россиянең баш балалар хирургы. Димәк, нидер кереп-сеңеп калган. Ләкин күп нәрсә югалган. Россиядә сәламәтлек саклауның хәле тәмугка тиң, һәм мин хәзер эшләмәвем белән бик бәхетле.

ТОННЕЛЬНЕҢ ОЧЫ-КЫРЫЕ БАРМЫ?

Язмыш мине берсеннән-берсе кызыклырак шәхесләр белән очраштырды. 80нче елларда язучы Юрий Нагибин белән дуслашып киттек. Ул бик нечкә тоемлы, гаять акыллы, искиткеч юмор хисенә ия иде. Без аның белән, әлбәттә инде, киләчәк турында гәпләшә идек. Үзгәртеп корудан күңеле кайткангамы, ул бервакыт болай диде: «Гадәттә тоннельне узгач, яктылык көтә, ләкин без андый хәлдә түгел. Тоннель соңында караңгылык булачак, һәм ул бик озак вакыт сакланачак. Россияне зур канкоеш һәм бәла-казалар көтә, әмма ул дөньяның бөек державалары исемлегенә керәчәк». Ни гаҗәп, ике дистә ел вакыт узса да, аның бу сүзләре һаман да актуаль булып кала бирә.

90 нчы еллар ахырында мин юллар чатында калдым. Стафилококк деструкциясе җиңелде. Безнең тырышлыгыбыз белән, дип әйтер идем, бу хаклыкка хилафлык кылу булыр — аны медицина эволюциясе җиңде. Яңа тема башлау теләгем юк иде. Мин күп вакытымны менә-менә төзелеп бетәргә тиешле Республика балалар клиник хастаханәсендә үткәрдем. Шунда эшләргә ниятли идем, шуңа күрә дә төзүчеләрнең миен черетеп бетердем. Әледән-әле төзелешкә Минтимер Шәймиев тә килгәли иде. Үзенең министрларына карганда мине ешрак күрүе турында шаяртып әйтеп куйгалаганы булды. Мин исә, мөмкинлектән файдаланып, хирургия бүлеге өчен акча сорыйм. Тырышлыгымны, үҗәтлегемне күреп, Минтимер Шәрипович миңа Россия Думасына сайлауларда катнашырга тәкъдим итте.

Дума эшенең мавыктыргыч яклары күп булды, ләкин моннан бик тиз күңелем кайтты, әллә ни зур нәрсәләр майтара алмаячагыма төшендем. Дөрес, вакыт-вакыт Татарстан өчен акча юллап алуны булдырдык.

Хәер, анда да горурланып сөйләрлек эш кыла алдым. 2005 елда сәламәтлек саклау министры итеп Михаил Зурабов билгеләнде, бу өлкәдән бик ерак кеше булса да, төрледән-төрле оптимизация тарафдары иде ул. Шул вакытка инде ул, экономия максатларында, социаль үсеш һәм сәламәтлек саклау министрлыкларын берләштереп тә куйды. Һәм эшен дәвам итәргә карар кылды. Янәсе, балаларда һәм өлкәннәрдә авырулар бер үк төрле, димәк, педиатрияне аерым юнәлеш итеп карау дөрес түгел, ә инде балалар хирургиясен бигрәк тә. Ул педиатрларны гомуми профиль табибларына әйләндермәкче иде. Шулвакыт без Леня Рошаль һәм академик Александр Баранов белән, тәгәрмәчкә таяк тыгып, Думаның пленар утырышында чыгыш ясадык. Кайтаваз булды. Безне ишеттеләр. Зурабов балалар сәламәтлеген саклау тармагын юкка чыгара алмады.

ХӘТЕРДӘ САКЛАНГАННАР

Шулай да, сәясәт белән чагыштырганда, хирургиядә мин күбрәк хезмәт куйдым. Хирурглар үлемгә күнегә дигән сүз ялган ул. Күнекмиләр, бигрәк тә, бала үлеме турында сүз барганда. Шундый бер очрак булды. Перитонит стадиясендәге сукыр эчәк ялкынсынуы белән бер чегән малаен алып килделәр. Без кулдан килгәннең барысын да эшләдек, тик ярдәм соңарган иде, баланы коткарып кала алмадык. Аңа операция ясаган хирург белән моргтан чыгып бара идек: «Суйдыгыз! Үтердегез!» – дип кычкыра-кычкыра, яныбызга бу малайның туганнары йөгереп килде. Мин ник аларның бишенче көнгә генә хастаханәгә мөрәҗәгать итүен дә сорый ала идем, дәшмәдем. Аларда — бала хәсрәте...

Гомер буе хәтерләрлек куанычлы вакыйгалар да булды. Бервакыт безгә стафилококк инфекциясе йоктырган 12 яшьлек Лена Счастьеваны алып килделәр. Озак дәваладык без аны, тик һичнәрсәнең файдасы тимәде. Инде әнисе дә, нәрсә булса да булыр дия-дия, язмыш белән ризалашкан иде. Ниһаять, мин Мәскәүгә шалтыратып килештергәч, безгә АКШ антибиотигы кайтардылар. Ленаны коткарып калдык. Ә күп еллар узып, мин инде депутат булгач, фотографияле хат килеп төште. Бу фотографиядә — Лена үзе һәм аның биш сабые! Мондый истәлекләр берсеннән-берсе киеренке бихисап эш сәгатьләрен, йокысыз дежур торган чакларны аклый, бүген шулкадәр авыр, рәхмәтсез, ләкин һаман да күркәм, мактаулы табиб һөнәрен сайлау өчен бер сәбәп булып тора.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

ИГОРЬ ПРИВАЛОВ: «РЕСПУБЛИКАНЫҢ НИ БЕЛӘН ЯШӘГӘНЕН БЕЛМӘГӘН КЕШЕ ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕНДӘ ФАЙДА КИТЕРӘ АЛМЫЙ»

Казан (Идел буе) федераль университетындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең белем бирү «челтәре» Татарстан һәм якын-тирә төбәкләрне генә түгел, ә чит илләрне дә колачлый – былтыр ноябрь аенда бу «челтәргә» Кытай кушылды. Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Игорь Привалов «Татарстан» журналына уку йортының яңа офыкларны ничек яулавы турында сөйләде.

– Игорь Анатольевич, 2016 елда гына да Татарстанның биш мең ярымнан артык дәүләт һәм муниципаль хезмәткәр сездә уңышлы белем алган. Мәйданының, коллективының әллә ни зурлыгы белән мактана алмаган мәктәп шулкадәр күп кешене укытырга ничек өлгерә?

Автор:
Ксения Сёмина

– Соңгы өч елда күп кенә программаларыбызны яңадан карап, аларны булдыра алганча тулыландырып, кыскартып чыктык. Хәзер курсларның дәвамлылыгы 16 академик сәгатьтән 250 сәгатькә кадәрне тәшкил итә. Дәүләт хезмәткәрен әзерләүнең алдынгы системаларын, шул исәптән чит илләрнекен өйрәнеп, интерактив методикаларның нәтиҗәлерәк булуын ачыкладык. Шуңа күрә лекция сәгатьләрен курсларның гомуми вакытының 10–15%ына кадәр кыскарттык. Тиешле материал кейслар чишү һәм тренинглар аша өйрәнелә. Бу кейслар курсларга йөрүчеләргә билгеле бер ситуацияләрне кичереп карарга, анык, төгәл үрнәк мисалында чишелешен табарга мөмкинлек бирә. Соңгы вакытта без «дистант» ысул – материалны онлайн өйрәнү ысулын актив кулланабыз. Тыңлаучы узган тема буенча имтиханны да онлайн режимда тапшыра ала.

– Шул рәвешле сез белем бирү эшенең даимилегенә омтыласыз булып чыга?

– Әйе. Теләсә кайсы буш вакытта белем бирү – Корея, Сингапур, Кытайның бик тиз үсеш кичергән дәүләт хезмәткәрләрен укыту институтлары нәкъ менә шуңа йөз тота. Мәскәү хөкүмәте каршындагы Мәскәү шәһәр идарә университетында лекция укыганда, Корея университетыннан квалификацияне күтәрү өлкәсендәге бер профессор бу илнең дәүләт хезмәткәрләренә профессионализм дәрәҗәсен арттырырга булыша торган уен рәвешендәге мобиль кушымта турында сөйләде. Билгеле бер биремнәрне үтәп, алар уенда югарырак баскычка күтәрелә, эшкә барганда яки көндезге аш вакытында уйнап, чын баллар алу мөмкинлегенә ия. Уенда алынган очколар эш хакы күләменә, карьера баскычыннан югары күтәрелүгә һ.б.га йогынты ясый. Сүз уңаеннан, анда өстәмә кызыксындыру мәсьәләсе бөтенләй юк.

– Быел мәктәп үзенең биш еллыгын билгеләп үтә. Бу кечкенә юбилей яңа максатлар да алып киләчәкме?

– Соңгы биш ел турында гына сүз йөртү дөрес булмастыр. Мәктәп тарихының чишмә башы 90 нчы еллар ахырыннан ук килә, аның идеологик нигезе Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә академиясендә үк формалашкан иде. Бу академияне Андрей Николаевич Ершов җитәкләде. Ул вакытта да, хәзер дә мәктәпнең максаты дәүләт хезмәте тармагында нәтиҗәле менеджер тәрбияләү булып кала бирә. Интенсив үсешкә карамастан, без реформаларны бик уйлап, иң яхшы тәҗрибәне искә алып, гореф-гадәтләрне саклап тормышка ашырабыз.

– Бар дөньяда һәм шулай ук Россиядә дә дәүләт хезмәткәрләре белән халык арасындагы гадәти багланыш ысулларын үзгәрткән мәгълүматлаштыру һәм цифрлаштыру процесслары төрле яклап чолгап алган заманда, дәүләт идарәчеләрен һәм хезмәткәрләрен база дәрәҗәсендә уку-укыту һәм әзерләү никадәр актуаль булып кала?

– Программаларыбызны әзерләгәндә, нәкъ әнә шул тенденцияләрне исәпкә алабыз да инде. Гади генә бер мисал китерим. Хәзер «Белешмә-аналитик материалларны әзерләү» программасын гамәлгә ашырабыз. Чөнки һәр көнне диярлек дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр төрле аналитик язмалар, җитәкче докладларын, хатларын һәм башкаларны әзерләү белән мәшгуль булалар. Һәм бу вакытта документның эчтәлеге дә, формасы да бик мөһим. Әлеге курс үзенең актуальлеген күрсәтте, һәм ул традицион рәвештә тыңлаучылар арасында бик популяр. Һәм, әлбәттә, эшнең инновацион инструментларын алга таба үзләштерү өчен база булып тора.

– Республикада барган процесслар мәктәп программаларының эчтәлегенә бераз ничек тәэсир итәме?

– Татарстан – безнең төп «заказчы», дип әйтергә була. Соңгы берничә елда монда чын-чынлап зур масштаблы ничә проект тормышка ашырылганына күз салыгыз әле. Җәйге Универсиада, Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты... Хәзер – Конфедерацияләр кубогы. Президент республика программалары болар өчен бик көчле база булды. Сәнәгать, IT-тармак динамик үсештә. Һәм барлык шушы проектлар өчен заманча, югары әзерлекле кадрлар, идарәчеләр кирәк. Чынга ашырылган проектлар исә бездә мондый кешеләрнең

Реклама

булуын раслый, фәкать республика үз алдына яңа максатлар куя, димәк, белемле, әзерлекле белгечләр тагын да күбрәк таләп ителә.

– Мәктәпнең эшчәнлеге шул исәптән кеше капиталын булдыру һәм туплауга да юнәлдерелгән булып чыга?

– Әлбәттә. Сүз уңаеннан, бер юнәлеше кеше капиталын үстерү булган «Татарстан 2030» стратегиясенең нигезләре күп кенә курсларыбызның программасына кертелгән. Бу стратегиянең бер тармагы кеше капиталын үстерүне күз уңында тота да. Дәүләт хезмәткәре республиканың үсеш векторларын, сәясәтен аңламый, бүген аның ни белән яшәвен белми икән, халыкка һәм дәүләткә файда китерә алмаячаклыгын без яхшы аңлыйбыз.

– Инде «урыннарда эшләүчеләр» өчен бу никадәр актуаль соң?

– Районнардагы дәүләт хезмәтенең, һичшиксез, үзенчәлекләре бар. Район хакимияте башлыгы булып эшләгән 10 еллык тәҗрибәмә таянып, берникадәр вакыт элгәрәк мин авыл башлыклары өчен махсус программа булдыру эшен башлап йөрдем. Алар нәтиҗәле идарә итү курсларын башкалар белән бергә, гомумиләштерелгән формада уза иде. Бу юнәлештә безгә Татарстан Президенты теләктәшлек күрсәтте, һәм, өченче елдан башлап, авыл җирлекләре башлыклары итеп яңа билгеләнгән 500ләп җитәкчене без шушы махсус программа буенча укыттык.

– Сез аларның эшендәге үзенчәлекләрне телгә алдыгыз. Болар нәрсәдән гыйбарәт?

– Хәзер авыл җирлеге башлыгы статусы бик зур җаваплылык бирә. Моңа туу-үлү турында белешмә тутырудан башлап, төрледән-төрле тикшерүче инстанцияләр белән үзара элемтәләр булдыру һәм башка бик күп эшләр керә. Шул ук вакытта башлыкларның күбесе үз хокукларын яклау, мөмкинлекләреннән файдалану өчен нинди коралларны, кануннарны кулланып булганын белеп бетерми.

– Бу программа да «кейслы» ысулны күз алдында тотамы?

– Әлбәттә, әле бу кейсларда авыл башлыкларына һәрдаим мөрәҗәгать итәргә туры килгән, эш барышында иң күп сораулар туа торган министрлык һәм ведомство вәкилләре катнаша. Шул рәвешле без уку-укыту мәсьәләләрен генә хәл итеп калмыйча, республика югарылыгындагы проблемалы сорауларны чишүгә дә өлеш кертәбез. Республиканың Муниципаль берәмлекләр Советы рәисе Минсәгыйть Шакиров – даими экспертыбыз. Ул, җирле үзидарә өлкәсендә бай тәҗрибәгә ия кеше буларак, үзара салым, референдумнар уздыру һәм җирле үзидарә органнары өчен актуаль башка бик күп мәсьәләләр һәм сорауларга ачыклык кертүдә ярдәм итте. Бер сүз белән әйткәндә, бу – бик кирәкле һәм файдалы программа.

– Былтыр ноябрь аенда КФУ белән үзара теләктәшлек турында меморандум имзалаган Пекин административ институты вәкилләрендә кайсы программа кызыксыну уятты?

– Кытайларның практик эш-гамәлләрен өйрәнү максаты белән әүвәл без аларга мөрәҗәгать иттек. Сәфәребезне Кытайның хакимият органнары белән бик озак килештерергә туры килде, чөнки алар чит ил кунакларына эчке ишекләрне бик саклык белән генә ача. Ниһаять, бу сәфәр чынга ашты һәм бик файдалы булды. Кытайлар әнә шул чакта кызыксынуларын белдерде һәм нигездә илдән чыгу өчен рөхсәт бирү белән шөгыльләнә торган ведомство вәкилләреннән гыйбарәт төркем юллады. Ике яклы бәйләнешләр бик уңай тәэсир калдырды. Хезмәттәшлегебез нәтиҗәле булырга вәгъдә итә, чөнки мегаполислардагы тормыш белән идарә итү, әйтик, тәзекләндерү, матурлау, территориаль планлаштыру белән бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә Кытай тәҗрибәсе безнең өчен бик кызык, шуңа күрә киләчәктә дә дуслыкны дәвам итәргә өметләнәбез.

– Сез гел хәрәкәттә, дәүләт хезмәте институтларын үстерүнең төрле ысул-алымнарын өйрәнеп, якын һәм ерак чит илләргә дә, Россия төбәкләренә дә еш барасыз. Гомуми фонда Татарстан ничек күренә?

– Һичшиксез, бик ышанычлы югарылыкта. Бу тармакта алып барылган эш буенча без Россиядә лидерлар, дип әйтә алабыз. Әйтик, дәүләт һәм муниципалитет хезмәткәрләре арасында белем алганнар санының республикадагы шундый хезмәткәрләрнең гомуми санына нисбәтеннән чыгып исәпләнгән күрсәткеч Россия төбәкләре арасында иң югарысы. Шул ук вакытта без Мәскәү һәм Санкт-Петербург хөкүмәтләре белән дә актив хезмәттәшлек итәбез, безгә Липецк өлкәсе, Саха Республикасы, Кырым, Дагыстан түрәләре дә укырга килә. Чит ил партнерларыбыз хисабында – Казахстан һәм Кытай. Ләкин шунысын да билгеләп үтү мөһим: төп бурычыбыз – белем алучыларның саны түгел, ә сыйфаты.

– Сүз республикадагы тәҗрибәне күчереп алу турында барамы?

– Һәр практик гамәл бу төбәк шартларына яраклашуны таләп итә. Татарстан тәҗрибәсе турыдан-туры күчереп алына алмый. Кайчак чит төбәккә баргач: «Татарстандагы кебек булсын өчен, безгә нишләргә кирәк?» – дип сорыйлар. «Сезгә Миңнеханов кирәк», – дип җавап бирәсе килә. Чөнки бездәге зур проектларның һәм мөһим процессларның төп чыганагы һәм драйверы нәкъ менә ул. Ләкин бу җавап та бик үк дөрес булмас иде, чөнки Президент инициативаларына Рөстәм Нургалиевич җентекләп туплаган команда теләктәшлек күрсәтә һәм алар шул команда тарафыннан тормышка ашырыла. Әлеге команда кеше капиталы мөмкинлекләрен нәтиҗәле файдалануның бик шәп үрнәге булып тора. Без хәзер шундый дөньяда яшибез ки, бер әкияттәге сүзләр белән әйткәндә, «бер урында калу өчен дә йөгерергә кирәк». Мин исә бер урында таптанып тормыйбыз, ә даими рәвештә алга барабыз, дияр идем. ■

* КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе

PRESSA.RU

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
WWW.PROTATRSTAN.RU
Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Бер сукбай республикага **КҮПМЕГӘ** төшә

Игелеклелек вирусын **КЕМ** тарата

Чит илләргә чыгу туйдырса, **КАЯ** барырга

PRESSA.RU

«Шәфкатьлелек» үзәгендә бүген 76 кеше яши, рәсми рәвештә ул 80 сукбайны сыйдырырга тиеш.

ЯЗМЫШМЫ-ЯЛГЫШМЫ, ЯКИ СУКБАЙЛАР КЕМГӘ КИРӘК?

Без, шәһәр кешеләре, алар белән көн саен диярлек очрашабыз. Юк, урам җыештыручы, кибетче, башка һөнәр ияләрен күздә тотуым түгел. Сүзем – сукбайлар турында. Инде аларга исебез дә китми, күп вакыт күрмәмешкә салышып узып китәргә тырышабыз. Ә бит алар да кайчандыр кемнеңдер газизе, кадерлесе булган. Ни өчен шундый көнгә калганнар? Берничә көн сукбайларны күзәтеп, аралашып, бу кешеләрнең көнкүрешләрен өйрәндем.



Автор:
Руфия Фазылова

«СИН МОНДА ПРОПИСКАДА ТҮГЕЛ!»

Фатирыбыз Казанның Мәскәү базарыннан ерак түгел, әллә шуңа аерым яшәү урыннары булмаган бу затлар гел безнең тирәдәге чүплекләрдә казына. Монысына күндек инде. Ә менә июнь аеның яңгырлы бер көнендә Шәүкәт исемле бер ир, безнең йорт артындагы куаклыклар янына килеп урнашты. Чүплектән иске матрас, юрганнар алып килеп әйбәт кенә «яши башлады». Яңгырлар яуганда үзенең «алачыгын» пакет белән томалап куя. Шуңа игътибар иттем: ир-ат «йортын» көннән-көн зурайта барды. Ята торган урынын катыргы, пенопластлар белән әйләндереп алды. «Тиздән монда мунча да салып куяр әле», – дип шаярттык без. Тик берәү дә Шәүкәт абыйны аннан кумады, киресенчә, әле ризыклар да чыгарып бирде. Бик итагатьле исәнләшә, сөйләшә. Беркөнне иртән карасам, Шәүкәт абый янына бер хатын-кыз килгән, йокысыннан уята:

– Сез танышлармы әллә? – дим бу татар апасына.

– Әйе, бергә эшлибез. Корбанбикә исемле мин. Гает көнне туганга, әти шундый исем биргән…

Балалар бакчасына ашыга идем, сөйләшеп торырга вакыт булмады. Чагыштырмача әйбәт кенә киенгән, пенсия яшендәге бу апа бик күп сораулар уятты: сукбайга, эчеп йөргән кешегә дә охшамаган. Кем ул? Кайда эшлиләр? Шуннан соң берничә көн күзгә чалынмады бу кешеләр. Шулай да кичен, балконга чыккач, кеше тавышлары ишетелә иде: «яңа күршеләр» арта торды.

Кичен бик нык кычкырышкан тавышка тәрәзәгә күз салдым. Ә анда… теге алачык өчен чын мәгънәсендә гауга купкан!

– Син монда пропискада түгел! – дип, бер хатын белән ир сугыша. Янәшәдә тагын берничә кеше бар. Озын сүзнең кыскасы, кемдер полиция чакырткан. Ярты сәгатьтән полиция экипажы килеп җитте. Алачыкта яшәүчеләр бер-бер артлы юкка чыкты, бары исерек әби генә җирдә ятып калды. (Бу «безнең» сукбай түгел иде). Соңрак аны «Ашыгыч ярдәм» машинасына утыртып, хастаханәгә алып киттеләр. Шул кичне күршеләр сукбайларның бөтен әйберләрен җыеп ектылар.

Фото: Лилиана Валитова

ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан алынган мәгълүматларына караганда, Казанның «Шәфкатьлелек» үзәгендә яшәүче бер сукбайга республика казнасыннан көненә 957 сум 58 тиен акча сарыф ителә. Димәк, айга 28 мең 740 сум акча диган сүз.



«ПАСПОРТЫМ ЮК!»

Берничә көннән Корбанбикә апаны янә безнең йортка караган чүплек янында очраттым. Гадәттәгечә өс-башы начар түгел.

– Сез хәзер кайда яшисез? – дим.

Мине танып алды булса кирәк, әллә кайчан белгән кешесе кебек, кулындагы капчыгын җиргә куеп, сөйләшә башлады.

– Әнә, Декабристлар урамы ягына күчендек. Теге тиле хатын булмаса, монда яшәр идем әле.

– Ә Шәүкәт абый кайда?

– Ул Тверь урамы ишек алдында... Салып йөри, эчкән кеше кирәк түгел. Үзе генә йөрсен...

Вакытлыча «күрше» булып алган бу апа белән озак сөйләштек. Яшел Үзән районының Ачасыр авылыннан килгән.

– Аптырагач чыгып киттем, монда ичмаса кыйнамыйлар. Питрәч районы Шәле авылында туган мин. Унбиш яшемдә әни белән Үзбәкстанга күчендек. Бертуган апам шунда яши иде. Әни 1990 елда вафат булды. Апам да озак тормады, үлеп китте. Ялгызым чит җирдә нишләп ятыйм дип, 1995 елда туган ягыма кайттым. Биектау районында яшәүче бер егет белән таныштырдылар, шуңа кияүгә чыктым. 1997 елда улыбыз туды. Тик улыбызга тугыз яшь булганда ирем үлеп китте. Аннан иремнең туган тиешле кешесенә кияүгә чыктым. Улым белән Яшел Үзән районы Ачасыр авылына күченеп кайттык. Икенче ирем белән унбер ел яшәдек. Күргәннәрне сөйләсәң... Күгәрмәгән җирем калмады. Шуңа өйдән чыгып качтым.

Фото: Ната Смирнова

Корбанбикә апа яңа яшәү урынын күрсәтте. Көн саен чүплектән кәгазь, шешә, калай савытлар җыеп, шуны сатып көн күрә икән.

Икенче көнне, редакциядәге кирәкмәгән кәгазьләрне җыеп, Мәскәү базары каршындагы зур ишек алдына киттек. Шунда ук бер гаражда кәгазь, пластмасса, калай савытлар җыялар. Шуңа да бомжлар ерак китеп тормаган, «эш урыны»на якын җирдә яшиләр. Корбанбикә апа, безне күргәч, яшь бала сыман сөенде.

– Эх, балакаем, паспортымны да ясарга ярдәм итсәгез... Пенсия яшемдә булсам да, акча алмыйм бит. Әллә кайчан авылдан иске генә бер йорт сатып алган булыр идем.

Үзбәкстаннан кайтканга 22 ел вакыт узса да, Корбанбикә апа Россия гражданины булып саналмый, паспорты юк. Дөрес, ул паспорт ясатырга тырышып караган, барып чыкмаган. «Үзбәкстанга барып документлар алып кайтырга куштылар. Ә минем анда кадәр барырга акчам булмады», – дип сөйләде.

Алып килгән кәгазьләрне килосын 5 сумнан тапшырдык, 32 кило булды. Корбанбикә апаның кулына 160 сум акча бирделәр.

– Көненә ничә сум акча эшлисең? – дим.

– Төрлечә була, 200, 300 сум да чыга. Мин иртүк, биш тулганчы ук чыгып китәм. Алайса калмый, өйле кешеләр дә кәгазь җыя бит.

Чынлап та, бер сәгать эчендә генә дә яхшы киенгән әллә ничә кеше картоннар алып килде. Гомумән, ул көнне без икенче дөнья, бүтән кешеләр күреп кайттык.

«КИЕМ БЕЛӘН ПРОБЛЕМА ЮК!»

Бирердәге сукбайлар арасыннан бер ир-ат күзгә ташланды: башында эшләпә, өстендә плащ, аягында әйбәт кенә ботинка. Әгәр аны бу урында очратмаган булсак, урамда яшәүче дип уйламас та идем! Бердәнбер кимчелеге – кырынмаган. Ә яшенә күрә әйбәт сакланган ул: төз гәүдә, авызында тешләре дә бар. Баксаң, монда аны барысы да белә, дәрәҗәле, хәтта «смотрящий» да. Үзен Фәрит дип таныштырды.

– Бокс буенча өч тапкыр чемпион мин! – диде горур гына.

– Россиянекеме?

– Юк, Үзбәкстаннан. Әти белән әни 1956 елда Үзбәкстанга киткән. Мин шунда туган. Җиде ел элек хатыным үлде, аннан кызым янына Казанга кайттым. Аның монда фатиры бар. Минем кызым менә дигән! Менә кияү генә... Сугыштым да чыгып киттем.

– Кызыгыз яхшы булгач, ни өчен этисен урамда яшәтә соң? – дим.

– Кияү котырта...

– Матур киенгәнсез. Бу плащны кайдан алдыгыз?

– Кием белән проблема юк. Урамда яши башлаганыма ике ел, мине монда беләләр. Кирәкмәгән киемнәрен кешеләр чыгарып бирә. Халык бай хәзер: яхшы әйберләрен дә ыргыта. Рәхмәт, контейнерга ташламыйлар, матурлап төреп, капчык белән читкәрәк куеп китәләр. Урын-җирләрне дә алыштырып кына торабыз. Чистада йоклыйсы килә бит.

– Аракы белән дусмы соң?

– Гомердә тәмәке тартмадым, шуңа да сәламәтлегем яхшы. Баш ташлап эчмәдем дә. Тик хәзер

Үзбәкстаннан кайтканына 22 ел вакыт узса да, Корбанбикә апа Россия гражданины булып саналмый.

PRESSA.RU

«Шәфкатьлелек» үзәгендә керү-чыгу ирекле.

салгалыйм, йотып алгач, рәхәт булып китә. Дөньяның тагын ни кызыгы бар?

– Кешечә яшисегез килмиме?

– Мин кешечә яшим! (Берничә секунд тынлык – авт.) Кемгә кирәк мин?! Хатын-кыз белән чуаласым килми, кызымның үз тормышы. Күңдем инде бу тормышка, үлгәч, җаен табып, күмәрләр әле.

– Кышкы салкыннарда нишлисез?

– Монда җылылык торбалары бар, шунда йоклыйм, бик салкыннарда подъездларга да керәм. Куып чыгармыйлар, таныйлар. Җылы ризык алып ашыйм. Тамак туйдырырлык кына акча эшләргә була.

Фәрит абый фотога төшәргә ризалашмады.

– Хәзер «Магнит» кибетеннән вакыты чыккан товарларны чыгарып ташлыйлар, тизрәк барып алырга кирәк, – дип, саубуллашып китеп барды.

Үзәктә пластилиннан, камырдан төрле картиналар ясыйлар.

«ШӘФКАТЬЛЕЛЕК» ҮЗӘГЕ

Республикада торыр җире, теркәлгән урыны булмаган кешеләр өчен махсус йортлар бар. Рәсми телдә ул «Билгеле бер тору урыны һәм һөнәре булмаган затлар өчен «Шәфкатьлелек» адаптация үзәге» дип атала. Алар Казан, Яр Чаллы, Бөгелмә шәһәрләрендә урнашкан. Башкаладагы үзәк 2005 елда ачылган. «Шәфкатьлелек» үзәге төзеклеге, чисталыгы буенча Казанның кайбер бала тудыру йортлары, сырхауханәләре, балалар бакчаларына караганда бик күпкә яхшырак хәлдә.

Казандагы үзәктә бүген 76 кеше яши, рәсми рәвештә ул 80 бомжны сыйдырырга тиеш. Кышын сукбайларның йөздән артып киткән чаклары да булган.

– Ел саен шулай, көннәр салкынайта башлагач, торыр урыны булмаган гражданнар безгә килә, – дип сөйләде Казанның «Шәфкатьлелек» үзәге бүлеге җитәкчесе Фирдания Гыймаева. – Урыннар тулы булса да, кышкы салкыннарда кешеләрне урамда калдырмаска тырышабыз. Аннан кемне картлар йортына, кайсын инвалидлар йортына урнаштырабыз. Кайберәүләр үзләре чыгып югала. Мисал өчен 2017 елның алты аенда гына өлкән яшьтәге 32 кешене картлар йортына җибәрдек. Аларның 10сы гарип иде, шуның өчен ул кешеләрне махсус интернатларга урнаштырдык. Гадәттә үзәккә паспорты да булмаган кешеләр килә. Без аларның документларын җыябыз, паспорт алырга ярдәм итәбез. Шунсыз аларны интернатларга алмыйлар, сау-сәламәт булганнары эшкә урнаша алмый. Элеккеге СССР, БДБ илләреннән булган кешеләрнең документларын җыю бик авыр, мөмкин түгел дисәм дә була. Ә үзәктә читтән килгән кешеләр бик күп. Алар белән нишләргә дә белгән юк. Чыгарып җибәреп тә булмый. Хәер, чыгып китсәләр дә, берничә айдан яңадан әйләнеп кайталар, тик инде гарипләнгән булалар. Шуңа күрә берничә ел яшәүчеләр дә юк түгел.

«Шәфкатьлелек» үзәгендә берничә кагыйдә бар. Беренчесе – биредә кеше алты ай гына яшәргә хокуклы.

Икенче кагыйдә – үзәккә йогышлы куркыныч авырулары булган кешеләрне кабул итмиләр. Башта яңа килгән бомжны республиканың туберкулез диспансерына җибәрәләр. Алар анда бушка флюорография уза. Корчаңгылы, бетле кешеләрне исә башкаланың дезинфекцияләү бүлегенә озаталар. Тәннәре чистаргач, үзәккә алып кайталар.

Өченче кагыйдә – үзәктә аракы эчү тыела. Исереп кайтучыларны да бирегә кертергә тиеш түгелләр. («Шәфкатьлелек» үзәгендә керү-чыгу ирекле.) Ләкин үзәктә эшләүчеләр бу очракта да искәрмә ясый икән:

– Катып үләрлек салкыннарда кешене урамда калдырып булмый бит, – диде Фирдания ханым. – Исерек булса да, кертәбез. Әгәр инде кеше гел эчеп йөри башласа, андыйларны үзәктән

Фото: Лилиана Вәлитова

Бүлмәләр якты, иркен. Тәрәзә төбендә гөлләр үсеп утыра.



куып чыгарабыз. Хәзер бу яңа бинада махсус изолятор бар – шаулашып йөрмәсеннәр өчен, исерекләрне шунда ябабыз.

Үзәк, чынлап та, бик матур, төзек. Идәндә плитка, тәрәзәләр яңа, пластик. Стеналар төрле төсләргә буялган. Бүлмәләр дә җылы, иркен. Тәрәзә төбендә гөлләр үсеп утыра, стенада да – үрмәле гөлләр. Коридорда берничә җиргә шкаф куйганнар, анда китаплар тезелгән. Тик барыбер зәһәр ис килә. «Монда эшләүчеләр бу искә ничек түзә икән?» – дип гаҗәпләндем. Сәбәбе: беренче катта тарту бүлмәсе бар, тәмәке исе шуннан килә. Аннан... бомжлар юынырга яратмый икән.

– Менә дигән душ бүлмәсе бар, көн саен рәхәтләнеп юынып чык та бит, – ди «Шәфкатьлелек» үзәгенең бүлек җитәкчесе. – Мәҗбүриләп диярлек юынырга кертәбез үзләрен. Адәм баласы бер түбәнлеккә тәгәрәсә, аннан чыгарга ашыкмый икән...

«Шәфкатьлелек» үзәгенең беренче каты инвалидлар өчен эшләнгән. Пандуслар куелган. Фирдания ханым белән палаталар буйлап йөреп чыктык: беренче катта гарипләр булса, икенче катта төрмәдән кайткан, эчеп йөреп, гаиләсен югалткан әзмәвердәй ир, хатыннар, карт бабайлар, әбиләр яши. Араларында элеккеге наркоманнар да бар. Ирләр бер, хатыннар икенче бүлмәдә. Өч тапкыр ашаталар, беренче, икенче ашлар, десертка кадәр бирәләр.

– Сәламәтлеге менә дигән ирләр дә бар, тик көннәр буе бүлмәләрендә яталар, – дип сүзен дәвам итте Фирдания ханым. – «Барыгыз, эш эзләгез. Монда бит гомер буе яши алмыйсыз», – дим. Юк, эшләргә, тормышларын үзгәртергә тырышмыйлар.

...Яшел Үзән районы Ачасыр авыл җирлеге белән элемтәгә кереп, Корбанбикә апаның улын эзләп таптык. Казанга килеп, әнисен Яшел Үзәнгә алып кайтып китте ул. Шулай ук ана белән улга яңа паспорт ясату буенча юл күрсәттек. Корбанбикә апаны упкынга төшүдән саклап калдык, дип, бик тә ышанасы килә. Һәрхәлдә, ул әле башка сукбайлар кебек дөньясына кул селтәмәгән. Әнә, улын күргәч ничек сөенде:

– Идән юарга булса да урнашасы иде, – диде. – Кичә коеп яуган яңгыр астында басып торганда үкереп еладым. Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорадым. Бу көнгә калырмын димәгән идем. Күкләр мине ишетте: әлеге куркыныч җирдән китәм...

Тирә-юньдәге башка сукбайлар Корбанбикә апаның машинага утырып киткәнен тыныч кына карап торды. Ананың ни өчен сөенгәнен дә, елаганын да аңламыйлар иде кебек. Аларны чүплек янындагы тормышлары канәгатьләндерә шикелле. Гамьсез генә җирдәге түшәкләренә бер-бер артлы барып чүмәштеләр. Бу күзләрдә нур юк. Дөньясына, шул исәптән үзләренә дә кул селтәгән алар.

Ирек Җиһаншин, «Зәкәт» фонды директоры:

– «Зәкәт» фонды кысаларында 2016 елның июнь аеннан башлап сукбайлар, ризык әзерләргә мөмкинлеге булмаган кешеләр өчен ашату оештырылды. Һәр атнаның дүшәмбесендә башкаланың Колхоз базары янында йөзгә якын сукбайга кайнар хәләл ризык китерәбез. Гадәттә ул токмач белән ит була. Шулай ук кайнар чәй белән салатлар да бирәбез. Бу хәләл кафелар белән «Зәкәт» фондының уртак изге эше. Максатыбыз – авыр хәлдә калган кешеләр, сукбайларны хәләл ризык белән сыйлау. Шулай ук мораль ярдәм күрсәтү. Безнең фондның егет-кызлары алар белән сөйләшүләр үткәрә. Якыннары булган кешеләрне өйләренә кайтырга өнди, ә сәрхүшләрне туры юлга басарга чакыра.

Казанда шәхси оешмалар, аерым хәйрия фондлары шулай вакыт-вакыт сукбайлар өчен кайнар ашлар тарата. Кыш көннәрендә ашарга килүчеләр аеруча күп була. Киләчәктә дә бу эшне дәвам итәргә уйлыйбыз.

НИ ӨЧЕН КЕШЕ СУКБАЙЛЫККА ЧЫГА? ТӨП СӘБӘПЛӘР:

- кешенең җәмгыятькә яраклаша алмавы, тормышта үз урынын тапмавы;
- мошенниклардан алданып, тораксыз калу;
- алкоголизм, наркомания һ.б. шундый төр бәйлелекләр;
- авырлык килгәндә ярдәм итәрлек якын кешесе булмау;
- каты авыру аркасында эшсез калу;
- янгын һәм башка фаҗигале очраклар аркасында торагын югалту.

PRESSA.RU

Илнур Нәбиуллин, хореография укытучысы, бию мәктәбе оештырып җибәргән, әлеге вакытта аның директоры. Атнага өч тапкыр Казанның 1нче интернат-мәктәбендә сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән балаларны биергә өйрәтә.

ИГЕЛЕКЛЕЛЕК ВИРУСЫ

Чит кешеләрнең проблемаларын үз өстеңә алмауның иң гади юлы – күрмәмешкә-белмәмешкә салышып үтү. Әмма йөрәк җылысын чит-ятлар белән бүлешергә әзер кешеләр һәрвакыт очрап тора. Үз юлын табып, уңышка ирешкән кешеләр ни өчен башкаларга ярдәмгә ашыга? Бу турыда «Татарстан» журналына каһарманнарыбыз үзләре сөйли.

БАРЫСЫ ДА БИИ!

– Интернатта чираттагы репетицияне тәгәлләп, кайтырга җыенам. Янымда орчык кадәрле генә бер малай бөтерелә, мөгаен, беренче сыйныф укучысыдыр. Кинәт кенә ул минем аякларымнан кочаклап ала. Берни аңламыйча басып торам.

– Нәрсә булды, – дип сорыйм, – сине кыерсыталармы әллә?

– Сез минем әтиемә шундый охшагансыз...

Мондый очракларга әзер булмасаң, чын мәгънәсендә сынау үтәргә туры килә: күз яшьләре дә көттереп тормаска мөмкин. Әмма мин кызганырга хакым юклыгын тәгәл аңлыйм. Тәҗрибәм дә бар – Алабуганың мәдәният училищесын тәмамладым, педагогик практика үттем, элеккке чор мөгаллимнәренә эләктем – алар күп нәрсәгә өйрәтте. Ләкин минем дә мондый мизгелләрдә тамагыма төер тыгыла. Шуны аңларга кирәк: биредә, интернатта, үзенчәлекле балалар. Аларга хәтта һава торышының да тәэсире бар, тиз арыйлар, көйсезләнәләр, аларның кәефләре дә кәтмәгәндә үзгәрүчән. Дәвасымы? Ярату һәм сабырлык. Интернат-мәктәптә укытучы педагоглар һәм тәрбиячеләр, минемчә, зур хөрмәткә һәм рәхмәткә лаек.

Мондый балалар минем тормышымда өч ел элек очраклы гына пайда булды: бию мәктәбе клиентлары интернатта 1 сентябрьгә багышлап бию куярга сорадылар.

– Ярдәм итә алмассызмы?

Ә ни өчен итмәскә? Әлбәттә, бер бию куярга да китәргә дә була иде. Ләкин эш башлауга шуңа төшендем: аларның тормышына тик торганнан гына килеп кер дә кит имеш. Мине аларның медицина куйган диагнозлары кызыксындырмый, мин аларны энергетик катламда тоярга тырышам. Алар ясалма елмаюны сүзсез дә аңлый, ул аларга кирәк түгел. Бу балалар кем белән аралашырга икәнен үзләре сайлый.

Аларны күбрәк куандырасы, күңелләрен күтәрәсе килә. Шуңа да без шаярабыз, уйныйбыз, һәм балалар да үзләрен ихлас тоталар. Алар миңа ышандылар һәм рәхәтләнеп биюләр өйрәнәләр. Безнең дәресләр – үзенә күрә бию терапиясе, ул балаларга хис-кичерешләрен чыгарырга ярдәм итә, бер-берсе өчен җаваплылык хисенә өйрәтә, хәтерне яхшырта. Алга китеш бар. Репетицияләр башлаганда, берсе дә гади генә хәрәкәтне дә исендә калдыра алмый, бик тиз арыйлар иде. Ә хәзер инде без роликларда бию куябыз – егылабыз, торабыз, әмма өйрәндек бит. Ел саен «Куллар тотышыйк, дуслар!» дигән хәйрия хәрәкәте оештырган концертларда чыгыш ясыйбыз. Хәтта сәламәт балалар өчен, дип әйтик инде, бәйгеләрдә дә катнашабыз. Күз алдына китерәсезме, без үзебезне уңайлы хис итәбез, балалар яшьтәшләренә тизрәк ияләшә. Шулай итеп, үсәбез, үзгәрәбез, алга атлыйбыз. Процесс, әлбәттә, озак бара, әмма нәтиҗәләр уңай. Һәм безнең интернат укытучылары белән бергәләп ирешкән иң зур уңышыбыз – бию дәресләрендә балалар бер-берсенә ярдәм итәргә, музыка һәм ритмны тоярга, башкаларның уңышларына сөенергә өйрәнде.

Без интернатның хореографы Людмила Медведева белән коллективыбызга биергә теләк белдергән һәр баланы кабул итәбез. Ышанасызмы, малайлар да бик теләп киләләр. Бик күп костюмнар тегәбез, чөнки биюләрне дублерлар белән куябыз. Реквизитлар сатып алабыз, декорацияләр эшлибез. Һәм ярдәм итәргә теләүчеләр даими очрап тора – кем кулыннан килгәнне эшли, кем акча бирә. Менә шундый игелек чылбыры барлыкка килә – ә ул минем биючеләремә бик кирәк. Бәләкәй бала шуны аңлый: өлкәннәрне аның дәресне ничек үзләштерүе, үзен ничек хис итүе генә борчымый, өлкәннәр аны бөтен кызыксынулары, мавыгулары белән бергә кабул итә.

Янәшәмдә кемгәдер җиңелрәк, күңеллерәк икән, мин үземне рәхәт хис итәм. Әлегә балаларның каникуллары. Тынлыкка ияләшеп киләм инде. Без социаль челтәрләр аша аралашып торабыз. Шушы көннәрдә генә быелгы чыгарылыш сыйныф укучысы үзенең шатлыгы белән бүлеште – үз авылындагы шәп егеткә кияүгә чыккан. Бәби көтәләр.

Автор:
Алсу Троицкая

Фото: Ната Смирнова, Александр Ефремов, ачык мәгълүмат чыганакларыннан

PRESSA.RU

СИН ДӘ ШУЛАЙ ЭШЛӘ

Гөлнара Җәләлетдинова. Былтыр май аенда «Игелекле кешеләр шәһәре» дигән хәйрия фонды оештырган.

Аңа кадәр улы Марат белән Анжела Вавилова исемендәге фондта волонтер булган. Буш вакыты булса, тизрәк Республика балалар клиник хастаханәсенең онкология гематологиясе бүлегенә йөгерә.



– Улым белән икебез өчен дә фондта эшләү яшәү мәгънәсенә әйләнде. Без бу «вирус» белән чирлибез. Беренчедән, әлеге бүлектә озак вакытлар үзебез дәваландык – улыма дүртенче стадиядәге остеоген саркомасы диагнозын куйдылар, метастаза инде үпкәләренә киткән иде. Ләкин без бу чирне җиңдек. Сүз уңаеннан, Маратның яраткан кызы кебек үк. Алар минем ике җиңүчем, икесендә бер үк кыйбла: «Башкалар ничек эшли, син дә шулай эшлә».

Икенчедән, безнең бүлешер тәҗрибәбез бар. Дәваланганда ук әле без эшсез утырмадык – Марат балаларның ялын оештыра иде, бүлектә компьютер клубы булдырды, мин исә өлкән әни ролендә. Улым белән горурланам. Ул авыруы котылгысыз вакытта да бер генә тапкыр елады. Анда да мине җәлләп. «Сиңа бик авыр!» – диде миңа сөяк рагы дигән диагнозлы, бөтен тәне система инәләре белән шыплап тулган үсмер улым. Хәзер дә «бәләкәй тылсымчым» миңа күңелсезләнергә юл куймый, һәрвакытта да кирәкле сүзләрен таба, илһамландыра һәм ярдәмгә килә. Һәм иң әһәмиятлесе: Марат кайчандыр үзе кебек авыру балаларга ярдәм итә, аларга бу куркыныч чирне җиңәргә булыша. Ә миңа теләсә кайсы вакытта әниләр шалтырата ала. Аларга бүтән төрле ярдәм кирәк – җылы сүз. Әти-әниләр «балагызда куркыныч авыру», дигән сүзне ишетүгә коелып төшә, шок хәлендә кала. Ләкин бу хәлдә озак йөрергә ярамый, үзеңне кулга алырга, алга таба нишләргә икәнен тиз арада хәл итәргә кирәк. Шушы мизгелләрдә кемнеңдер ярдәмен тою бик кирәк, хәсрәт эчендә үзең генә түгеллеген аңлау мөһим. Кайбер әти-әниләр балалары дәваланганнан соң, үзләре дә волонтер булып китә. Билгеле, башта алар бу темадан читләшергә тырыша, онытырга телиләр – моның өчен вакыт таләп ителә. Әмма чираттагы тикшеренүләргә килер алдыннан шалтыраталар, нәрсә кирәк, дип сорашалар.

Безнең фондның эшчәнлеге бик гади – балалар өчен тәгаен нәрсәләр эшли ала торган кешеләргә мөрәҗәгать итәбез дә берданбер сорауны бирәбез: ярдәм итә аласызмы? Ышанасызмы-юкмы, әмма тылсымчылар һәрвакыт бар. Без шуның белән бәхетле дә: безгә гел яхшы кешеләр очрап тора, һәм беркайчан да тискәре җавап ишеткәнебез юк. Алай гына да түгел, хәзер фондның дуслары бик күп. Көн саен безгә шалтыратып ярдәмнәрен тәкъдим итәләр. Без һәрвакыт элемтәдә, безгә шалтыратып яки язып була. Мондый яшәү рәвеше наркотикларга бәйлелек кебек. Бүлеккә бер көн килми калсаң, нindидер мөһим эшең калган кебек гасабиланасың.

Без офисыбызны махсус булдырмадык. Бөтен ярдәм туп-туры бүлеккә килә. Памперслар, көнкүреш химиясе, шәхси гигиена әйберләре, азык-төлек – өйдә кирәк була торган бөтен нәрсә дә кирәк. Бүлек бит, асылда, балаларга һәм аларның әниләренә дәвалану вакытында икенче өйгә әйләнә. «Кыюлык Тартмасы» дигән хәйрия проекты өчен уенчыклар, китаплар бик кирәк. Онкология бүлегендә ятучы балалар әлеге бүләкләрне авырттыра торган процедуралардан соң ала, һәм аларның күз яшьләре күпкә тизрәк кибә. Һәм, әлбәттә инде, без балалар арасында төрле бәйгеләр оештырабыз, мастер-класслар үткәрәбез, артистлар, рәссамнар, музей һәм иҗат студияләре хезмәткәрләрен чакырабыз, төрле конфессия руханилары килә.

Безнең күп кенә дусларыбыз бүлеккә беренче тапкыр килгәч, аптырашта кала. Күрәсең, чынбарлык алар көткәннән үзгә булып чыга: биредә якты, тыныч, һәрвакыт яхшы мөгамәлә, ә иң мөһиме – балалар үзләре. Һәм берниндәи негатив юк.

PRESSA.RU

ИСКЕ ДАЧА ЭЗЛӘГӘНДӘ

Дача! Казан кешесе өчен моннан ди шигърирәк сүз булуы мөмкинме? Бу бәләкәй өйдә июль уртасындагы яңгырлардан һәм суыклардан ышыкланып була. Кадакларда һәрвакыт иске, ертык курткалар һәм плащлар эленеп тора – Махно ротасын киендерерлек! Әмма барыннан да бигрәк шушы зур планетада синең берничә сутый үз җирең булуы һәм анда нәрсә теләсәң, шуны эшли алуыңны тою җылытып тора. Чөнки син монда бер үк вакытта алпавыт та, крепостной да! Җир казырга, су сибәргә, тирес ташырга үзеңә үзең кушасың, бакчадагы беренче җиләкне дә үзең өзеп кабасың һәм, падишаһ булып, шезлонгта утырасың.

Автор:
Гадел Хәеров

БЕРНИЧӘ СУТЫЙ ҖИР ҖӘННӘТЕ

Рәхәтләнеп ял итеп ятканда, берәр бик акыллы бакчачы Цветаеваның мондый юлларын искә төшерер:

Бу тәмугларым өчен,
Саташуларым өчен,
Картайган көнемә
Бер бакча бирче.

Әлбәттә, бу юлларны язганда Марина Ивановна полиэтилен плёнка астындагы бөҗәкләр белән тулы тирес өемен дә, көрәк сабыннан уч төпләрендә шартлаган сөялләрне дә күздә тотмагандыр. Аның күз алдына үзеннән-үзе үсә һәм иҗат итәргә берни дә комачауламый торган ниндидер абстракт бакча килгәндер. Тагын бер рус шагыйре – Иван Северянин – шулай ук дача өе турында хыялланган:

Минем яшел өй генәм
Елга яры паркта.
Нинди аулак урын ул!
Ялгызлык һәм тынлык та!

Әмма хыялы тормышка ашу белән, ул пластинканы алыштыра һәм моңая башлый:

Тынгылык тапмыйм, терелү күрмим,
Бу җирлектә мин үземә.
Хәлсезмен, берни ошамый, хыялымда-
Башка пейзаж иде лә…
Бакча урамга караган, күпдачалык бирелдә.
Коллар кебек, өйләре дә
Кысылган бер-беренә.
Күршем Боккачионы уйный,-
Йөзенче кат бер үк вальс –
О, бетмәс газап күңелгә!

Илаһым, ничек заманча яңгырый, дип уйлап куйдым мин, чүп баскан участогыма күз йөртеп чыккач. Ялкаулыктан баскан чүп түгел ул, ә махсус, «күпдачалык»тан, бөтен җирдәге күршеләрдән, аларның Бразилия карнавалы төсләрендәге ыштаннары белән чүп өстенә иелгән бишенче нокталарыннан киртәләнү өчен махсус үстерелгән. Әмма аерылу мөмкин түгел, хәтта күпьеллык әрекмәннәр дә моннан коткармый.

Ютубта Боккачионы тыңлап карау насыйп булмады (эзләнү бары тик Джованни Боккачоның «Декамерон»ын гына бирә), юкса, мин бу вальсның бүгенге заман попсасыннан күпкә яхшырак булуына ышанам. Хәтеремдә, моннан ун еллап элек, күршеләрем кунагының «үндүртенче» динамигыннан яңгыраган «Чёрные глаза» мине чак дөньядан ваз кичтермәде. Әмма Северянинны аңлап була, борынгы музыка күңелне ничек кенә сихерләмәсен, ләкин унынчы тапкыр уйналгач, ул, һичшиксез, колакларны чүкеч белән төйгәндәй итә.

Ул Санкт-Петербургта яшәгән. Шәһәр кешеләре җәйләрен дымлы «таш капчыкларын» калдырып, урманда, күл буенда яшәргә, саф һава суларга тырышкан. Хезмәтчеләр хуҗалары белән бергә киткән, ә «авыллар» – җир сөрергә, печән чабарга – өйләренә кайткан. Шәһәр сизелерлек бушап калган.

Бездә исә башкача. Ул еллардагы Казан – тыныч, провинциаль шәһәр. Үзәк Воскресенская урамыннан (хәзерге – Кремль урамы) бер читкә атласа, кеше матур табигатьле, тар тыкрыклары белән аерылып торган, таш җәелмәгән авыл урамнарына килеп чыккан. Монда сәүдәгәрләр һәм мещаннарның җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалы биек булмаган өйләре урнашкан булган. Тирә-якта әтәч кычкырулары, сыер-сарык тавышлары, эт өрүләре ишетелгән, анда-монда юл тотучы арбаларның майланмаган күчәрләре шыгырдаган.

Коллекционер Кирилл Пономарёв тәкъдим иткән «Учёные записки Казанского университета»ның 1899 елның сентябре язмасыннан без менә ниләр укыдык: «Казан полицмейстеры җиткерүенчә, җирле халык, полициянең тыюына да карамастан, бернинди караучысыз килеш, ишегалларыннан үзләренең сыерларын һәм башка терлекләрен чыгаралар, алар йорт тирәләрендә тротуарларны боза, янбакча коймаларын вата, хәтта шәһәрдәге һәм шәхси бакчаларга керә, шулай итеп, шәхси һәм җәмәгать милкенә зыян китерә, кайчакта үтеп йөрүчеләрне борчый, һәм аларга хәтта зарар да китерә».

Әле хәзер дә Универсиада проспекты буенча (Курчак театрыннан башланып РКХнә күтәрелү юлына кадәр) бакчаларны күрергә була. Шәһәрнең нәкъ үзәгендә сакланып калган авыл да бар – Әмәт авылы ул – бирелдә коттеджлар арасында йөзәр еллык кечкенә агач өйләр дә очрый.

Шулай булгач, революциягә кадәр Казан кешеләренең күбесе җәйләрен шәһәрдә калган. Алар тузан йотмаган, эсселектән интекмәгән, яшелчәләр үстергәннәр, Иделгә, Казансуга, Кабан күленә су коенырга йөргәннәр, көймәдә йөзгәннәр, балык тотканнар. Горький исемендәге парк ул чакта – Рус паркы, таулы ландшафты өчен Немец Швейцариясе дип тә атаганнар. Бу – аланлыкларга һәм табигый чишмәләргә ия (аларның берсе «Новаторлар» тимер юл станциясендә әле дә тибә)

чын чытырманлык булган. Монда кайчандыр немец колонистларыннан калган җыйнак-тәртипле бакчалардан кура җиләге, чия, алма җыйганнар. Каен җиләге һәм гөмбәгә Әмәт урманына йөргәннәр.

Алпавытлар яздан ук үз утарларына киткән. Бәрхет сезонына Кавказ суларына (нәкъ Лермонтов кебек!) яки Карловы Варыга, Баден-Баденга (Гоголь, Тургенев, Достоевский кебек!) бару модада булган. Диңгез ярында кызынырга теләүчеләр күренмәгән. Кояшта каралучылар солдатлар һәм гади кешеләр арасында гына булган. Бай әфәнделәр ак тәнле булырга тиеш саналган. Утызар градуслы эсселәрдә аксыл төстәге жилетлы костюмнардан пешеп йөргәннәр, өлкән яшьтәгеләр җәйге чесуча пәлтә, перчатка һәм, әлбәттә инде, эшләпә кигән. Хатын-кызлар кояш нурларыннан зонтиклар астына качкан һәм җилпәзәләр тотып йөргән. Хәтта дачаларында да сөенеп киемнәрен салып ташламаганнар, корсетларын ычкындырсалар һәм галстукларын бушатсалар гына инде...

Поезд белән Европа буйлап сәяхәткә чыгарга яисә тәгәрмәчле пароходта Идел буйлап круизга чыгарга мөмкин булган. Ул чактагы бер реклама менә ничек дип кызыктыра: «Америка тибындагы 40 комфортабельле җиңел пассажир пароходы көн саен, һәрбер шәһәрдә тукталышлар ясап, Тверьдән Әстерханга кадәр рейслар оештыра».

Әлбәттә инде, «диңгезгә» совет чорындагы кебек массачыл туристлар агымы күзәтелмәгән. Ул чакта Сочи тирәсендә малярия таралган. Кырым – кыйммәтле элиталы урын, анда үз яраннары белән патша үзе һәм иҗади даирә ял иткән! Чит илләргә чыкканнар, ләкин ажиотажсыз гына. Төркия һәм грек утраулары – алары инде бик кыю сәяхәтчеләр өчен экзотика булган. Европага барып чыккан Россия кешесенең сагынуын безнең якташыбыз, рәссам Иван Шишкин менә ничек тасвирлый:

«Моңсуланып, рус җырларын көйләп утырам, алда әле тагын эчпошыргыч һәм күңелсез күп нәрсәләр көтә. Ни өчен мин Россиядә түгел, ә монда, Штадт-Кабург номерында утырам, шайтан белә. Күңелсез, коточкыч күңелсез, әмма шул ук вакытта рәхәт тә. Бирсен Ходай, каһәрләнгән чит илдә өстерәлеп йөргәндә, бу хис югалмасын иде».

«ДРЕЗДЕН ЧИКТӘН ТЫШ ТУЙДЫРДЫ, ИРТӘГӘ МОННАН ЫЧКЫНАСЫ ИДЕ!»

«Эльба мәзәк, бигрәк тә хәзер, яңгырлар яугач, күрәсең, су таулардан балчык буйлап аккандыр, шуңа елгадагы су мумия кебек җирәнгеч. Гомумән, Эльба безнең шагыйрьләребез үзе турында юмарт рәвештә сипкән шигърият буяуларына лаек түгел!»

«Без монда һәм Берлинда күргәннәребез – бездә күп тапкырлар яхшырак. Мондагыча ямьсез һәм зәвыксыз сынлы сәнгатьне мин беркайда да күрмәдем, ә биредә Дрезден рәссамнары гына түгел, ә Мюнхеннан, Цюрихтан, Лейпциг һәм Дюссельдорфтан да бар... Моңа кадәр минем чит илдә күргәннәремнән мине бернәрсә дә, көткәнемчә, шаккатырмады...»

«Болар барысы да үле нәрсә, ә миңа тизрәк натурага кайтырга кирәк, кояш кызуына. Табигать һәрвакыт яңа һәм моның ише бернәрсә белән дә тапланмаган һәм үз бүләкләренең чиксез запасы белән һәрчак бүләкләргә әзер, һәм без аны тормыш, дип атыйбыз!»

Россиядәге беренче дачалар Петр I заманында Санкт-Петрбургка китерүче Приморье юлы буйларында барлыкка килә. Җир участоклары патша күрсәтмәсе буенча аристрократларга һичшиксез өй салу һәм бакча ясау шарты белән бушлай («дача» сүзе – әнә шуннан килеп чыккан) бирелгән. Беренче дачник граф Александр Данилович Меньшиков булган, һәм ул буш җирне апельсин агачлары (немецча – Oranienbaum) белән тутырган, шулардан барлыкка килгән сарай паркына Ораниенбаум исеме бирелгән.

PRESSA.RU

ДАЧА ТОРМЫШЫНЫҢ ЯМЕ

Тотрыклы керемнәре булса да, әле утар сатып алырга акчалары җитеп бетмәгән Казан байлары, җәй җитүгә, шәһәр тирәсендә вакытлы дачалар алган. Хуҗалар белән алдан ук килешеп куйганнар, җәйгә өйләр бирелү турында газетадан рекламалар укыганнар, үз күзләре белән күрү өчен, алдан ук барып караганнар, арадашчыларын җибәргәннәр. Ерак Кабандагы дача урыннары популяр булган, анда кечкенә пароходлар белән йөргәннәр. Мәскәү белән ике арада тимер юл элемтәсе ачылгач, Казаннан башлап, Романовлар күперенә кадәр урнашкан авылларны да үзләштерергә керешкәннәр. Әмма төрле исләр аңкып торган терлек киртәләре булган, авыр хезмәт белән яшәүче һәм сезне эшлексез итеп күргән крестьяннар белән бер авылда яшәү – бер хәл, ә инде борчу-хәсрәтсез яшәгән үз ишләрең белән бер ук дача бистәсендә ял итү – бөтенләй башка!

Мисал өчен, Красная Горка (Юдино), Займище, Лаврентьево (Обсерватория), Васильево бистәләрендәге кайбер урамнар әнә шундый булган. Биредә инде кандалалы тынчу авыл өйләре түгел, ә бәлки махсус җәй көне яшәргә көйләнгән верандалы җиңел дачалар төзелгән. Газеталарда спектакльләр һәм үзешчән концертлар оештырыла торган заллар, шулай ук түләүле коену урыннары – суга төшүче баскычлары булган сарайчыклар турында языла. Аларда чишенгәннәр, чәй яки башка көчлерәк эчемлекләр белән сыйланганнар. Керү урынында – ирләр һәм хатын-кызлар сәгатьләре күрсәтелгән расписание эленеп торган.

Иртәләрен дачникларны күмәч, сөт, колбаса, яшелчә сатучыларның тавышлары уяткан. Шәһәрдән яңа әзерләнгән сыра һәм бозлы тартмаларда туңдырма китергәннәр. Җәйге фасылда авылларның булдыклы кешеләре дачниклардан шактый файда туплап калган.

Без шул чордан калган бер генә өйне булса да табарга тырышып карадык. Һәм без моңа ирештек шикелле. Обсерватория бистәсе тавында, яңа планетарий юлында тулы бер дача исән торган. Кайчандыр монда яшәүчеләр балконда чәй эчкәндә, самавырның бакыр кырларында аларның алсу йөзләре чагылгандыр. Алар, чия төшләрен аска төкерә-төкерә, Идел өстендә кояш баеганын күзәткәннәрдер. Гайбәт сатканнар, яшьлекләрен искә төшергәннәр, хөкүмәтне сүккәннәрдер. Барысы да һәр замандагыча. Әңгер-меңгердә хезмәтче хатын керосин лампасын чыгаргандыр. Гаилә башлыгы, портсигарын чертләтеп ачып, хуш исле папиросын тартып җибәргәндер. Буш графинда шөпшә безелдәгәндер. Ире, хатынының юан муенындагы черкинең кызарып тулуын ләззәтләнеп күзәтеп торгандыр да, ояты килеп, «Казанскій вечеръ» газетасыннан «күсәк» бөтерергә керешкәндер. Балалар исә аста шау-гөр килгәннәрдер, июнь коңгызын тотып, аны стакан белән каплап куйганнардыр…

Тагын бер агач өйне без планетарий территориясендә таптык. Бу – астрономның торак йорты. Әлеге өй дача саналмаса да, бай йортларындагыча эшләнгән агач сыр-бизәкләре революциягә кадәрге бай дачаларның нинди булганын күзалларга мөмкинлек бирә.

ОРИГИНАЛЬ ПРОЕКТ КИРӘК!

Совет эшчеләре һәм хезмәткәрләре өчен әлеге дә баягы «коллектив бакчалар» шәһәр тирәли узган гасырның 30 нчы еллары уртасында барлыкка килә башлый. Алар – зур булмаган җир биләмәләре һәм кечкенә өйләрдән торган, чөнки бу төзелешләргә җитди регламент куелган. Икешәр катлы фазендалар, мунча, гараж төзергә, кролик, кош-корт, кәҗә ише җан ияләре тотарга ярамаган. 60 нчы елларда минем Борисково янәшәсендәге зур бакчачылык ширкәтендә ниндидер җитди комиссия абзыйларының линейкалар белән корылмаларны үлчәп йөргәнен күзәткәнем булды. Безнең күршебезгә капиталь сараен һәм хәтта турнигын да сүтәргә кушылды. Кем дә булса уенчык дачасын төзергә керешсә (фин өйләре соңрак барлыкка килде), ул председательгә төзелеш материаллары өчен бөтен чекларын күрсәтергә тиеш иде.

Әмма барлык кеше дә тыйнак совет дачаларының стандарт архитектурасы белән килешә алмады. Төрле юллар белән, таныш-белешләре яисә ветеран бабаларының элемтәләреннән файдаланып булса да, кайбер хәйләкәр дачниклар үз участокларында архитектура ягыннан гәҗәеп корылмалар «койдылар». Мондый «диссидентлар» бармак белән генә санарлык, һәм аларга әкәмәт кеше итеп карыйлар иде. Яшел Үзән ягына баручы электричка тәрәзәсеннән, Адмиралтея бистәсен узуга, әле бүген дә бөтен әйләнәсе балконлы һәм бер колоннада торучы түгәрәк дачаны күрергә була. Мондый дача төссезлек һәм бертөрлелек белән килешмәү билгесе бит!



ГАЕПЛЕ ИМПЕРАТРИЦАНЫҢ БҮЛӘГЕ

Тагын бер сакланып калган дача Архиерей дачасы Урта Кабан күле янындагы яшел калкулыкта урнашкан. Аны зурлап Яңа Иерусалим дип йөрткәннәр. Бу Екатерина II тарафыннан митрополит Вениаминга, Пугачёвка ярдәм итүдә нахакка гаепләнеп, вакытлыча читкә кагылуы өчен бүләк ителгән. Җәй буена митрополит биредә күчеп торган булган. Монахлар белән бергә ул балык тоткан һәм суга куелган кәнәфидә чәй эчәргә яраткан, дип сөйлиләр. Тагын әле аның кармагына табан балыклары бернинди җим куймасаң да эләгеп чыккан, диләр. Хәтта ряса җиңенә дә кергәннәр, ә парктагы тиеннәр аңа үз чикләвекләрен ташыган имеш!

1978 елның юлкүрсәткечендә әлеге урын турында шигъри дә, моңсу да итеп язылган:

«Архиерей дачасының борынгы паркы аңлатып булмастай ямьгә ия: чаган белән аралашкан ике йөзәр яшьлек юкәләр аллеясы, ябалдашлары белән кушыла язып, түгәрәк мәйданчыкларны тирән күләгәләренә урап, чәчәк аткан кояшлы аланнар аша сузыла, нурлар сыман тарала да, акрынлап парк артындагы әрәмәлеккә барып тоташа. Кайчандыр биредә беседкалар торган, инде алар күптән юкка чыккан».

Ә менә тиеннәр калган, һәм тәреләр дә элеккечә кояшта ялтырый. Биредә, ташланганлык белән бергә, ниндидер провинциаль ямь тоемлана.

PRESSA.RU

ГКЗ ГЛАЗОВСКИЙ комбикормовый завод

Входит в группу компаний КОМОС ГРУПП

ПОДБИРАЙТЕ КОМБИКОРМА ПРАВИЛЬНО!

ДЛЯ ЛИЧНЫХ ПОДСОБНЫХ ХОЗЯЙСТВ.

Комбикорма ЭКОНОМ – «Доброе подворье» разработаны специально для животных, которые содержатся в условиях домашних хозяйств с традиционной технологией выращивания. Необходимое количество питательных веществ, витаминов и минералов обеспечат здоровье и продуктивность ваших животных.

• Фасовка 5 и 25 кг. •

ДЛЯ ПРОМЫШЛЕННЫХ ЖИВОТНОВОДЧЕСКИХ КОМПЛЕКСОВ И ПТИЦЕФАБРИК.

Рецептуры комбикормов ПРОФИ разработаны с учетом рекомендаций от создателей пород и кроссов сельскохозяйственных животных и птицы, оптимальны для применения в условиях промышленных комплексов с интенсивной технологией выращивания.

• Фасовка 25 и 40 кг. •

Реклама

АДРЕСА ТОРГОВЫХ ТОЧЕК

УДМУРТИЯ

«Глазовский комбикормовый завод»
г.Глазов,
ул. Красногорский тракт, 15
Отдел продаж:
тел.:(34141)3-85- 33
Фирменный магазин:
тел.:(34141)3-81- 20

«Можгинский элеватор»
г.Можга,
ул.Железнодорожная, 93
Фирменный магазин:
тел.: (912)019-54- 60

УДМУРТИЯ

«Крестьянский рынок»
Завьяловский район,
уд.Пирогово, ул.Торговая, 1
тел.: (3412)62-33- 89

БАШКИРИЯ

«Янаульский элеватор»
г. Янаул,
ул. Социалистическая, 19А
Фирменный магазин:
тел.: (34760)5-95-93

ТАТАРСТАН

«Крестьянский двор»
г. Набережные Челны,
п. Сидоровка,
ул. Магистральная, 47 Б
тел.: (927)416-95-07

«ИП Садреев»
г. Чистополь,
ул. Привалова, 86
тел.: (917)905-95-85

«ИП Минабутдинова»
г. Казань,
Горьковское шоссе, 113 В
тел.: (919)633-83-32

ПЕРМСКИЙ КРАЙ

«Агро-Торг»
г. Пермь,
ул. Буксирная, 4
тел.: (922)24-34-224

КИРОВСКАЯ ОБЛАСТЬ

«Оникс»
тел.: (912)874-82-00
тел.: (912)852-31-93

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

КАЙСЫ шәһәр Болгар иленең башкаласы

Лангепаста татарлар **НИЧЕК** яши

Актаныш чәкчәге **НИНДИ** була

Академик булыр өчен **НИНДИ** китаплар укырга кирәк

Кошлар тавы **КАЙДА** урнашкан

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

ЛЕНИНОГОРСК: БУ ШӘҺӘРНЕ ЯРАТМАСКА МӨМКИН ТҮГЕЛ

Алсу Дәүләтшина фотолары

Әле бик күптән, «Татарстан» хәбәрчеләре өстәл астында үрмәләп йөргән чакта ук, әбием миңа еракта-еракта, биек таулар, яшел болыннар, тирән елгалар артында яшеренгән искиткеч гүзәл шәһәр турында әкият сөйләгән иде... Һәм анда бик матур һәм дустанә, явызлыкның ни икәнен белмәүче һәм аны эшләмәүче кешеләр яши, дигән иде. Һәм бу аларның шундый гүзәл җирләрдә яшәве, чиста чишмә сулары эчүе белән бәйле, һәм анда ләмнең дә... – бары тик дәвалый торганы гына, шуңа да бу шәһәр кешеләре бер дә авырмый, озак һәм бәхетле яшиләр икән.

Бу әкият шулай әкият булып калыр иде дә. Әгәр безнең «Татарстан» Лениногорск шәһәренә барып чыкмаган булса. Менә шунда инде әкият чынбарлыкка әверелде. Туган як буйлап шактый бай сәяхәтләр тәҗрибәсенә ия буларак, без беренче тапкыр матур һәм уңайлы итеп яшәр өчен барысы да булган урынга килеп чыктык: монда – Лениногорск районын җил-давылдан ышыклаучы таулар да, шәһәр суүткәргечен тәэмин итеп торучы саф сулы чишмәләр дә, шәһәр кешеләренә авырмаска һәм картаймаска булышучы шифалы ләмнәр дә бар.

Лениногорск үзе – төсле картинадан төшкән кебек. Чиста, җыйнак, якты, шуңа күрә яңгырлы көндә дә кояшлы кебек. Аның архитектурасы сокландыра, тукталып калырга һәм фотоаппаратларны чехолыннан чыгарырга мәҗбүр итә: монда гадәти хрущёвкалар да – алар салават күперенең төрле төсләренә буялган – иң яхшы архитекторлар иҗат иткән биналар да бердәй кызыклы күренә. Бер ЗАГС бинасы гына да ни тора! Мондый ЗАГСта туктаусыз никахлашырга була, ләкин Лениногорск тәртипләре моңа юл куймый – бирредә гашыйкларны бер тапкыр һәм гасырларга җитәрлек итеп бәйләгән мәхәббәт хуплана. Шуңа да шәһәр урамнары балалы әниләр белән тулы – ә бу сыйфатлы һәм тотрыклы тормышның беренче билгесе. Әниләр үсеп килүче буынны һавада йөртә, әтиләр эшли, әбиләр агачләр күләгәсендә ял итә, шәһәр чәчәк ата. Безнең гид булырга ризалашкан Лениногорск егете Артур менә нәрсә диде: «Мин тумышым белән моннан түгел, Норильскидан, әмма гаиләм белән бирегә күчкәнебезгә ике ел инде. Бирредә ике балабыз туды. Бу шәһәр минем өчен отпуск, бәйрәм белән тәңгәлләшә – чөнки монда ялга килә идем. Шул чакта ук аңа гашыйк булдым. Хәзер шушында яшим, Лениногорскины биш бармагым кебек беләм. Һәм, бик күп җирләрне күргән булсам да, Лениногорскидан яхшырак урынны белмим».

PRESSA.RU

PRESSA.RU



ЛЕНИНОГОРСК: КҮР ӘЛЕ, СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИНДИ МАТУР!

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДАГЫ КЕЧЕ ҺӘМ УРТА БИЗНЕСКА ЯРДӘМГӘ

«Татнефть» ГАҖнең бүлендек предприятиесе булган «Татнефть-Актив» ҖЧҖ шул исәптән «Татнефть» компаниясенең профильле эшчәнлеге белән ярашучы һәм Татарстан Республикасында да, аннан читтә дә ихтыяҗга ия кече һәм урта җитештерүләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерү өчен киң мөмкинлекләр тәкъдим итә.

2015 елда «Татнефть-Актив» ҖЧҖ, аккредитация үтеп, Түбән Мактама бистәсенең җитештерү базасында сәнәгать мәйданы статусын алды. Сәнәгать мәйданы арендага бирелә торган җитештерү, офис, склад һәм хуҗалык объектларына ия.

Безнең резидентлар – бизнесның төрле формаларын, шул исәптән инновацион юнәлештәгеләрен дә уңышлы үстерүче кече һәм урта эшкуарлык вәкилләре. «Татнефть-Актив» ҖЧҖнең заманча инфраструктуралы яңа җитештерүләр булдыру өчен потенциалы бар.

«Татнефть-Актив» ҖЧҖ балансында ТРның Аксубай, Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Алабуга, Лениногорск, Нурлат, Зәй, Сарман һәм Тукай районнарында урнашкан биналар һәм корылмалар эчендә 163 мең кв. метр буш мәйдан һәм 2320 мең кв. метр җир биләмәләре исәпләнә.

Файдаланылмый яткан милек «Татнефть-Актив» ҖЧҖнең аукцион интернет-мәйданчыгы аша куллануга тапшырыла, аның адресы: www.torgi.tatneft.ru

► Куллану өчен әзерләнгән офис, җитештерү, склад һәм хуҗалык мәйданнары;

► Кирәк булган инженерлык коммуникацияләре белән тәэмин итәлеш;

► Керү юллары;

► Сак хезмәте, видеокүзәтү;

► Телефон элемтәсе линияләре;

► Тиешле җиһазлар белән комплектлаштыру мөмкинлеге;

► Җитештерү ихтыяҗларына туры китереп, җылылык, электр һәм энергетика егәрлекләрен арттырырга ярдәм итү.

«Татнефть-Актив» ҖЧҖ мәйданнарының үсеш перспективалары

► ТР һәм РФнең фәнни учреждениеләрен, шул исәптән ресурсларны саклаучы һәм халыкара стандартларга туры килгән югары экологик технологияләрне җәлеп итеп, алдынгы технологияләр эшләп чыгару һәм кулланылышка кертү;

► Илебезнең һәм чит илләрнең яңа инвесторларын җәлеп итү;

► Импортны алыштыру юнәлешендәге һәм экспорт өчен каралган җитештерүләрне үстерү;

► «Татнефть» ГАҖ төп нефть табу һәм нефть эшкәртү җитештерүе базасында тармак кластерын формалаштыру;

► Пыяла сүс заводы һәм «ТАНЕКО» АҖ продукциясе нигезендә кече җитештерүләрне үстерү (кече химия);

► «Татнефть-Актив» ҖЧҖ милкен файдаланып, металл эшкәртү, агач эшкәртү, эретеп-ябыштыру җиһазлары, авторемонт җиһазлары юнәлешләрендә җитештерүләр оештыру;

► Муниципаль хакимиятләр белән берлектә социаль әһәмияттәге проектлар булдыру.

«Татнефть-Актив» ҖЧҖ үзара ихтирамга һәм гомуми эш мәнфәгатьләренә нигезләнгән тотрыклы партнёрлык мөнәсәбәтләрен югары бәяли.

«Татнефть-Актив» ҖЧҖ
ТР, Әлмәт шәһәре,
Объездная ур., 5 йорт
www.tna.tatneft.ru
www.torgi.tatneft.ru
aktiv@tatais.ru
tatneftaktiv@mail.ru
тел.: (8553) 37-03-22, 30-07-10, 37-10-48

Реклама

НЕФТЬ СКВАЖИНАЛАРЫНА – ИКЕНЧЕ ТОРМЫШ

Уникаль Ромашкино «кара алтын» чыганагы районында урнашкан Лениногорск – Татарстанның нефть сәнәгате үзәкләреннән берсе. Аның икътисады эре нефть-газ табу һәм нефть сервисы предприятиеләренең эшенә нигезләнә. «ЛениногорскРемСервис» ҖЧҖ шулар исәбенә керә, ул, даими рәвештә эшнең яңа технологияләрен һәм ысулларын үзләштерә барып, республиканың нефть тармагы үсешенә саллы өлеш кертә.

Александр Щербаков, «ЛениногорскРемСервис» ҖЧҖнең башкарма директоры

Скважиналарга капиталь ремонт ясау хезмәте Татарстанның Ромашкино чыганагында нефтьне сәнәгать юлы белән таба башлаганнан бирле гамәлдә. 1950 елдан 1970 елга кадәр ул «Татнефть» берләшмәсенең нефть промыселы идарәләре составына кергән һәм, скважиналарга хезмәт күрсәтеп, аларны куллану срокларын озайткан.

– Әмма ахыр чиктә чыганакны эшкәртүнең котылгысыз чоры, ягъни скважиналар фондының картаюы, чи нефтьнең сусыллануы белән бәйле соңгы стадиясе килеп җиткән, – дип сөйли компаниянең башкаручы директоры Александр Щербаков. – «Татнефть» берләшмәсе җитәкчелеге һәм белгечләре әлеге мәсьәләләр белән шөгыльләнүче махсуслашкан предприятие оештырырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. Һәм 1970 елда Лениногорскида катламнарның нефть бирүен күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсе оештырыла.

Бүгенге көндә «ЛениногорскРемСервис» ҖЧҖ – ул 4 төп җитештерү цехы: скважиналарга капиталь һәм агымдагы ремонт белән шөгыльләнүче цех; скважиналар төзү цехы; катламны гидравлик юл белән шартлатуның технологик процессларын башкаруда һәм пакер технологияләрен кертү хезмәтләрендә махсуслашучы технологик эшләр цехы һәм җитештерүне тәэмин итү цехы.

Предприятиедә даими рәвештә «ТатНИПИнефть» эшкәртмәләре сынала, катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү өчен яңа технологияләр һәм материаллар кертелә.

– Бүгенге көндә нефтьнең авыр чыгарыла торган запасларын эшкәртү киң кертелә, – ди Александр Михайлович. – Аларны ачу һәм нефтьне сайлау темпларын арттыру өчен, скважиналарның продуктлылыгын күтәрүнең нәтиҗәле ысулларыннан берсе – катламны гидравлик шартлату кулланыла.

Предприятие эшли башлаганнан бирле, «ЛениногорскРемСервис» белгечләре тарафыннан зур профессиональ уңышларга ирешелгән, капремонтчылар – ремонт технологияләренең, нефть чыгышын арттыру методлары һәм ысулларының күптөрлелегендә кыйммәтле тәҗрибә туплаган, һәм бу технологик схемаларны классификацияләргә һәм аларны Ромашкино чыганагын эшкәртүнең үзгәреп торучы шартларында кулланырга мөмкинлек биргән.

Предприятие оешкан көннән алып, «Татнефть» ГАҖ, Татарстанның кече нефть компанияләре өчен, шулай ук «Оренбургнефть» ААҖ, «Самаранефть-газ» ААҖ, «Лукойл-Пермь» ҖЧҖ, «Роснефть» НК» ААҖ, «ТатРИТЭКнефть» НГТИ һ.б. өчен барысы 35 меңнән артык скважина ремонтланган һәм сафка бастырылган. 2006 елдан, предприятие үз эшчәнлегендә яңа юнәлеш – кече диаметрлы скважиналар төзүне үзләштергәч, Татарстан, Башкортостан, Удмуртия, Самара һәм Оренбург өлкәләре территорияләрендә 800дән артык кече диаметрлы скважиналар төзелгән.

«ЛениногорскРемСервис» ҖЧҖ технология яңалыкларын гына түгел, ә бәлки җитештерүне оештыру өлкәсендәге бөтен алдынгылыкларны уңышлы үзләштереп бара. Компаниянең 80%тан артык хезмәткәре җитештерү, технологик процессларны һәм эшләрне оештыруны даими яхшырту программасына җәлеп ителгән.

Предприятиенең катламнарны гидравлик шартлату һәм кече диаметрлы скважиналар төзү буенча күрсәтә торган хезмәтләренең сыйфаты югары бәяләнгән. «ЛениногорскРемСервис» «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» һәм «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсларында лауреат булган.

1970 елның 1 августында Лениногорскида, илдә беренче буларак, катламнарның нефть бирүен күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсе оештырылган, хәзер предприятие «ЛениногорскРемСервис» ҖЧҖ дип атала. Шушы көннән башлап, «Татнефть» ГАҖнең ремонтланган скважиналардан алган өстәмә нефть күләме **10,5 млн тоннадан артып киткән.**

Реклама

PRESSA.RU

ҖЫЛЫЛЫКНЫ – ҺӘР ЙОРТКА

Шәһәр һәр предприятиене һәм һәр йортны җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итә торган күзгә күренмәс инженерлык челтәре белән капланган. Бу – чакрымнарга сузылган җир асты коммуникацияләре, насос станцияләре, күпсанлы җылылык үзәкләре. Һәм ике йөз иллеләп квалификацияле белгеч. Алар көтелмәгән очракларда җылылык һәм су белән тәэмин ителеш өзелмәсен һәм Лениногорск кешеләренең тормышы уңайлы булсын өчен, барысын да эшли.

Компания Лениногорскида һәм Лениногорск районында сәгатенә 165,9 Гкал гә якын егәрлектәге 77 җылылык үзәген эшләтә һәм аларга техник хезмәт күрсәтә. Җылылык челтәрләренең гомуми озынлыгы 179,3 км.

Айдар Хисмәтуллин, «Лениногорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖнең генераль директоры

«Лениногорск җылылык челтәрләре» 2010 елда оешкан. 2015 елдан предприятиегә зур хезмәт тәҗрибәсенә ия оештыручы һәм җитәкче Айдар Хисмәтуллин җитәкчелек итә. Ул эшләгәндә предприятие, челтәрләрне модернизацияләү һәм егәрлекләрне үстерүне дәвам итеп, үсешенең яңа этабына чыккан.

– 2013 елдан «Җылылык хуҗалыгын модернизацияләү, яңадан төзү һәм техник яктан үзгәртеп кору» программасын үзләштерүгә республика хөкүмәте, «Татарстан Республикасын газлаштыру фонды» ДКУ һәм Лениногорск муниципаль районы хакимияте тарафыннан 500 миллион сум акча бүлеп бирелде, – ди «Лениногорск җылылык челтәрләре» ҖЧҖ генераль директоры Айдар Хисмәтуллин. – Безнең белгечләр, модульле-блоклы җылылык үзәкләре урнаштырып, җылылык белән тәэмин итү системасына реконструкция ясадылар. 2013 елдан 2016 елга кадәр гомуми озынлыгы 42,7 км булган җылылык челтәрләре алыштырылды.

2016 елда без Лениногорск районындагы тагын 61 җылылык үзәгенә хезмәт күрсәтергә керештек, аларны кышкы чорга яхшылап әзерләдек. Үзебезнең төп бурычлардан тыш, без шулай ук Шөгер һәм Иске Шөгер авыл җирлекләрен чиста су белән тәэмин итү һәм тотылган суны чыгару хезмәтләрен күрсәтә башладык.

Бүгенге көндә «Лениногорск җылылык челтәрләре» компаниясендә 251 кеше эшли, уртача хезмәт хакы 30 мең сумга җитте, 2015 ел белән чагыштырганда, бу 9%ка артыграк.

Предприятиенең «Мактау тактасы»нда – безнең иң яхшы хезмәткәрләребез: энергорайон башлыклары Андрей Чоботько һәм Евгений Чернов, эксплуатация буенча баш инженер урынбасары Марат Нурмөхәммәтов, КИПиА участогы башлыгы Сергей Логинов, җылылык үзәкләре операторлары Ирина Трифонова һәм Елена Лапаскина, авария-диспетчерлык хезмәте башлыгы Марат Вәлиуллин, 5 нче разрядлы электр һәм газ белән эретеп-ябыштыручылар Ринат Саримов һәм Иван Горбунов, слесарь Сергей Кочербитов, җылылык үзәге операторы Любовь Курочкина, слесарь Марат Гаязов, электр белән эретеп-ябыштыручы Иван Чернов һәм машина йөртүче Николай Звонарёв.

Предприятие эшчеләре даими рәвештә яңадан укытылалар, өстәмә белгечлекләр үзләштерәләр, яңа эшкә тиешле рөхсәтләр алалар. «Челтәрләр»нең горурлыгы – хезмәт династияләре, мәсәлән, Ионовлар гаиләсе. Хезмәткәрләребезнең күбесе яхшы эшләп кенә калмый, предприятиебезнең җәмәгать эшләрендә, шәһәрдә үткәрелә торган мәдәни һәм спорт чараларында да актив катнаша.

Реклама



Лениногорскидагы технопарк гомуми мәйданы 16 гектар тәшкил иткән өч җир биләмәсендәге объектлар комплексыннан гыйбарәт. Көйләнгән инфраструктуралы территориядә офислар өчен каралган һәм җитештерү эчәнлегенен тәэмин итү өчен билгеләнгән бүлмәләр бар.



КИЛӘЧӘККӘ КАРАУЧЫЛАР ӨЧЕН СТАРТ МӘЙДАНЫ

«Идея – Юго-Восток» инновацион-җитештерү паркы Лениногорск шәһәрендә 2004 елда «Татнефть» компаниясе һәм Казанның «Идея» технопаркы тарафыннан Татарстан Хөкүмәте ярдәме белән булдырылган. Ул – республиканың нефть районындагы кече һәм урта бизнес үсешенә заманча теләктәшлек итү үзәге. Җирле эшкуарлар һәм башлап китүче талантлы инженерларга хәзер үз проектларын һәм ачышларын тормышка ашыру өчен барысы да бар.

Технопарк алдына Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышындагы эшкуарларга үзләренең новаторлык идеяләрен тормышка ашыру, үз җитештерүләрен булдыру, товарларын һәм хезмәтләрен тәкъдим итүдә ярдәм күрсәтү максаты куелган. Биредә стартапны эшләтеп җибәрү өчен бөтен шартлар да тудырылган.

Технопарк карамагында консалтинг компаниясе эшли. Ул башлап җибәрүче эшкуарга икътисад һәм предприятиеләр белән идарә итүнең теләсә кайсы өлкәсендә диярлек квалификацияле консультацияләр тәкъдим итә. Компаниянең бурычы – эшкуарларның теркәү органнары белән элемтәләрен җиңеләйтү, бизнесны алып барганда килеп чыгарга мөмкин булган административ киртәләрне киметү, консультацион, бухгалтерлык һәм юридик мәсьәләләрдә тулысынча ярдәм күрсәтү.

Яхшы инфраструктура булуы предприятиеләргә бизнесны башлап җибәрү һәм үстерү өчен кирәк булган хезмәтләрнең тулы комплексын күрсәтергә мөмкинлек тудыра. Бүгенге көндә технопарк территориясендә 45 предприятие үз җитештерүләрен һәм вәкиллекләрен урнаштырган. Резидентлар эшчәнлегенең нигезен түбәндәге төрләр тәшкил итә: җитештерү һәм сәүдә итү-сатып алу, төзелеш, проектлаштыру һәм энергия белән тәэмин итү, автошиннарны утилләштерү һәм эшкәртү, коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү.

Технопарк ярдәме белән 2017 елның мартында төзелеш һәм сервис өлкәләрендәге ике предприятие булдырылган. Төзелеш компаниясенең беренчел бурычы – технопаркны яңа җитештерү корпуслары белән тәэмин итү һәм гамәлдәге биналарны кышкы чорга әзерләү. Идея «Юго-Восток» Төзелеш компаниясен киләчәктә шәһәр һәм республика әһәмиятендәге проектлар көтә.

«Идея-Юго-Восток» Сервис предприятиесе транспорт һәм клининг хезмәтләре күрсәтә. Автопарк җиңел һәм йөк-пассажир транспортының 25 берәмлегеннән тора, алар «Татнефть»ГАҖнең биш предприятиесенә хезмәт күрсәтә. Компания якын арадагы планнарында – паркны һәм хезмәт күрсәтү күләмен яңа заказчылар җәлеп итү ярдәмендә тагын да баетуны күздә тота.

Клининг хезмәте эшчәнлегенең төп юнәлешләре – ул биналарның эчен һәм тышкы ягын көндәлек җыештыру, яшелләндерү, корылмаларга техник хезмәт күрсәтү. Беренче чиратта эшләр технопарк территориясендә алып барыла. Хәзерге вакытта хезмәткәрләрнең штатын киңәйтү һәм заказлар портфелен формалаштыру буенча оештыру чаралары алып барыла.

«Татнефть» ГАҖ белән берлектә технопаркның тагын бер перспективалы проектына – «Идеяләр остаханәсе» дигән яшьләр инновацион иҗат үзәгенә нигез салынган. Ул Лениногорск шәһәренең яшь кешеләрен техник белем алу белән кызыксындыру максатында оештырылган. Әлеге үзәктә материалларны фрезерлау (3D-сканерлау «головкасы» һәм борылу үзәге җайланмасын кую мөмкинлеге белән), лазер ярдәмендә кисү һәм гравировкалау җиһазлары бар. Коллективның бурычы – яшьләрдә заманча цифрлы технологияләр белән практик эшләү күнекмәләрен булдыру, модельләштерү өлкәсендә инновацион фикерләүне үстерү һәм яңа мөмкинлекләр турында күзаллауны формалаштыру.

Киләчәк – яшьләр кулында һәм инновацияләр юнәлешендә! Технопарк үзенең кыю фикерләрен тормышка ашырырга әзер булган һәркем өчен ачык, һәм ул эшкуарларны нефть ягының икътисадый үсешендә катнашырга чакыра.

Реклама

PRESSA.RU

ЛЕНИНОГОРСК ХАЛКЫ УҢАЙЛЫ ШАРТЛАРДА ЯШӘРГӘ ТИЕШ



ТКХ – иң четерекле һәм үзенә карата җентекле игътибар таләп итә торган тармакларның берсе, чөнки ул һәр кешенең көндәлек тормыш-көнкүрешенә кагыла. Бу өлкәдәге проблемалар барлык кешеләрне дә борчый, гражданнарның җирле үзидарә органнарына шикаять һәм тәкъдимнәр белән баруына иң төп сәбәп булып та тора. Лениногорск районында соңгы елларда торак фондын яхшыртуга һәм ТКХ эшчәнлегенең сыйфатын арттыруга зур игътибар бирелә. Әмма эшләнәсе эшләрнең күпчелеге алда әле.

Лениногорск районында торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп кору җирле халыкны сыйфатлы хезмәт күрсәтү белән тәэмин итәргә һәм инженерлык системалары эшчәнлегенең ышанычлылыгын арттырырга мөмкинлек бирде. ТКХны яңартып коруның максаты системаны үтәкүренмәле һәм нәтиҗәле итү өчен кирәк. Барлык үзгәртүләр дә башкарма хакимият белән тыгыз бәйләнештә гамәлгә ашырылырга тиеш. Шәһәр коммуналь хуҗалыгындагы бурычларны уңышлы хәл итәр өчен, башкарма хакимиятнең ролен муниципалитет алдында хисап тотарга тиешле идарәче оешманы сайлау юлы белән арттыруны кулай дип таптылар. 2015 елда шәһәрдәге күпфатирлы йортларның күпчелеге белән идарә итүне «ЛМР» МБнең «ТКХ һәм Төзелеш Мәгълүмат ресурслары үзәге» ҖЧҖнә тапшыру турында карар кабул ителде.

2008 елдан башлап, Лениногорскида капиталь ремонт буенча федераль программа эшли башлады. Шәһәрдәге 318 йортта комплекслы ремонт эшләре үткәрелде, аларның гомуми суммасы 1 081,5 млн сумны тәшкил итте. Һәр йортта уртача 8,6 млн сумлык эш башкарылды. Программа кысаларында 2016 елда 12 күпфатирлы йорт ремонтланды, төзекләндерү эшләре 101 656,426 мең сумга төште.

Лениногорскидагы капиталь ремонтның үзенчәлеге шунда: ремонт эшләренә нәкъ менә шушы йортларның төзеклеген тәэмин итүче подрядчы оешмалар җәлеп ителә. Алар, әлбәттә, сыйфатлы ремонт ясау яклы! Бу эш 2008 елдан бирле гамәлдә, нәтиҗәләре дә югары. Моннан тыш, подрядчыларны да кирәгеннән артык контрольдә тоту зарурияте юк, чөнки бу очракта һәркем үзе өчен, озакка җитәрлек булсын, дип эшли. Бу юнәлештә аеруча зур уңышка ирешкән коллективлар «Арго» ҖЧҖ, «Коммунальник» ҖЧҖ, «Техника» ҖЧҖ булды.

Капиталь ремонтны башкарганда «Энергияне саклау һәм энергетик нәтиҗәлелек турында»гы федераль закон шартлары үтәлә. Иң мөһим моментларның берсе җәмәгать урыннарындагы гадәти электролампаларны тулаем энергия саклый торган яктырткычларга алыштыру булды. Нәтиҗәдә 4 млн сумга кадәр экономия ясарга мөмкинлек туды.

Бүген Лениногорскида барлык биналар да гомумйорт исәпләү узеллары белән җиһазландырылды, шәһәр халкы шулай итеп ут, су һәм җылылык өчен киткән чыгымнарын кыскарта алды. Исәпләү җиһазларының күрсәткечләрен контрольдә тоту өчен дә махсус система кертелде, бу система 495 торак йортны мониторинглый. Хәзер ресурсларны куллану картасын онлайн режимда күрергә була, димәк ки, аварияле ситуацияләр дә – күз уңында. Мондый хәлләрне тиз арада күреп алу һәм булдырмый калу чыгымнарны кыскартырга да мөмкинлек бирде. Лениногорск Татарстанда энергия ресурсларын исәптә тоту буенча бердәм системаны гамәлгә керткән беренче шәһәрләрдән булды.

Лениногорск районының Торак фонды бүгенге көндә 1 912 500 кв. м. ны тәшкил итә. Лениногорскига 2 идарәче компания (404 йорт) һәм 17 ТМШ (92 йорт) хезмәт күрсәтә.

Реклама

«БлагСтрой-ДорХоз» МУП – бу шәһәр бакчалары һәм Лениногорск урамнарындагы яшел агачлар, шулай ук 100 меңнән артык сандагы чәчәк утыртылган күпсанлы клумбалар.

НЕФТЬ ЯГЫНДАГЫ ШӘҺӘР-БАКЧА

Шәһәр таш джунглиларга әверелмәсен һәм кешеләрнең сәламәтлегенә тискәре йогынты ясамасын өчен, аны уңайландыру һәм яшелләндерү буенча планлы эш алып барырга кирәк. Урамнарда һәм бакчаларда клумбалар чәчәк атарга һәм газоннар яшелләнеп утырырга тиеш. Болар шәһәр халкында бәйрәмчә кәеф тудыра һәм яшәүнең уңайлылык дәрәҗәсен күтәрә.

Денис Толмачев, «БлагСтрой-ДорХоз» МУП директоры

Уңайлыклар булдыру һәм яшелләндерү шәһәр хуҗалыгының катлаулы юнәлеше булып тора. Лениногорскиның чисталыгын һәм матурлыгын «БлагСтройДорХоз» МУП тәэмин итә.

– Шәһәрне чәчәк бакчасына әверелдерү – бу җиңел бурыч түгел, – ди предприятие директоры Денис Толмачев. – Монда барысын да исәпкә алырга кирәк: туфракның торышын, үсентеләрнең сыйфатын, чәчәкләрнең сортын һ.б. Үз вакытында су сибү, ашламалар кертү, агачларның ботакларын кыскарту, картайганнарын кисү – барысы да тиешенчә эшләнгәндә генә нәтиҗә бирә. Көз көне без яшь традицион һәм декоратив сортлы агачларны утыртабыз, яз көне алар яшелләнеп китәчәк һәм күзләрне сөендерәчәк, җәй челләсендә күләгә бирәчәк. Безнең предприятие хезмәткәрләре җирне яратырга һәм матурлыкны аңларга тиеш, чөнки клумбада эшләү ул рәссам иҗаты кебек, бары тик бездә буяулар урынына – чәчәкләр генә. Ә инде сквер һәм паркларга килгәндә, монда ландшафт дизайныннан башка булмый. Әлбәттә, барысы да эскизлардан һәм аларны раслаудан башлана. Аннары «палитра» сайлана: тоташ чәчәк ату күренешен тудыру өчен аерым сорт һәм колердагы чәчәкләр, шулай ук куаклар һәм агачлар. Шул ук вакытта, бер-берсенә оптималь рәвештә ярашып торсын өчен, аларның биеклеге, ябалдашларының формасы һәм төсе исәпкә алына. Шәһәрдәге бәйрәм чараларына әзерлек аерым игътибар сорый. Без бәйрәм үткәрү урыны Лениногорск халкының исендә калсын өчен тырышабыз.

Шәһәр клумбаларын һәм яшеллекне тәрбияләп тору – «БлагСтройДорХоз» МУП эшчәнлегенең бер ягы гына. Лениногорск урамнарында һәм ял итү урыннарында көн саен тротуарлар һәм газоннар җыештырыла. Кышларын предприятие хезмәткәрләре урамнарны, тротуарларны, җәяүлеләр күперләрен һәм җәмәгать транспорты тукталышларын кар һәм боздан арындыру белән мәшгуль. Хәтта иң карлы кышларда да шәһәр халкының зарланганы булмады. Барысы да Лениногорскида «БлагСтройДорХоз» муниципаль предприятиесе оешканнан бирле шәһәрнең күпкә чистарып һәм матурланып китүен белдерә. Урамнарда юл эшчеләре һәм җыештыру машиналары даими эшли, һәр көн якты һәм бәйрәмчә булсын өчен чәчәк бизәкләре яңартылып тора.

– Предприятие башкара торган эшләр һәм хезмәтләр комплексы гаять киң һәм ул безнең оешманың исеменә чагыла, – ди Денис Владимирович. – Кыш ахырында агачларны формалаштыру үткәрелә. Яз көне, көтелмәгән хәлләрне кисәтү өчен, «БлагСтройДорХоз» су басуга каршы чаралар үткәрә – бу инеш тамакларын, сууткәргеч торбаларны һәм яңгыр канализацияләрен чистарту. Яз көне шулай ук шәһәр юлларындагы чокыр-чакырларга ремонт ясала. Җәй көне шәһәрне чәчәкләр белән бизәү һәм зур шәһәр бакчасын тәрбияләп тору чираты җитә. Ел әйләнәсе без шәһәр территориясендә ремонт-төзелеш эшләре алып барабыз; күперләр, автомобиль юллары һәм тарихи-архитектура һәйкәлләре кебек объектларны карауны тәэмин итәбез. Биредә яшәүчеләр Татарстандагы иң матур һәм тәрбияле шәһәрләрнең берсе – үз шәһәрләре белән горурлансын өчен тырышабыз.

Реклама



ЛЕНИНОГОРСКИНЫҢ ИҢ ТӘМЛЕ УРЫНЫ*

«ТАТАРСТАН» ТАРАФЫННАН ТИКШЕРЕЛДЕ

Адрес: 423250, Лениногорск ш., Чайковский ур., 26
Тел.: 88559521962
polet_kafe@mail.ru

Реклама

* «Татарстан» журналы версиясе буенча

ЛЕНИНОГОРСК «КОЛОС»Ы ҺӘРКЕМНЕ АШАТЫР!

«Колос» икмәк заводы продукциясен Лениногорскида белмәгән кеше юк. Көн саен табыннарны «Колос»та пешкән ипи һәм күмәчләрнең берничә төре бизи, макароннар, өй токмачы, торт һәм кондитер ризыклары – барысы да яңа пешкән һәм табигый!

Радик Мөгыйнов, «Колос» ҖЧҖ генераль директоры

– «Колос» ҖЧҖ икмәк заводына 2005 елда нигез салынган иде, – ди предприятие директоры Радик Габделхәевич Мөгыйнов, – ә ул Ильинның зур булмаган шәхси пекарнясыннан һәм «Лениногорск икмәге» ААҖнән үсеп чыкты. 2009 елда заводта, предприятиене яңарту максатында, реинжиниринг үткәрелде. Без инвестицияләр җәлеп итеп, эш кырын киңәйттек, яңа цех төзеп, анда Скандинавиянең танылган фирмаларында эшләнгән заманча җиһазлар урнаштырдык. Бу шунда ук җитештерелә торган продукциянең сыйфатында чагылыш тапты. Продукциябез шәһәребез кешеләренә дә, республиканың башка көньяк-көнчыгыш калаларында яшәүчеләргә дә ошады. «Колос» пешергән икмәк-күмәч ризыклары кибетләрдә озак ятмый.

Завод төрле юнәлешләрдә үстерелде: җиһазлар, сыйфат, ассортимент, товарны сату базарында тәкъдим иту… 2010 елда ребрендинг буенча чаралар комплексы үткәрелде: уңайлырак һәм матуррак төргәкләү гамәлгә кертелде. Соңгы унъеллыкта без ассортиментны сизелерлек арттырдык, хәзер ул 200 дән артык төрне үз эченә ала.

Сәламәтлек өчен файдалы булган натураль продукциягә юнәлеш тотыла. Мәсәлән, «Целебный» яисә «8 злаков» икмәкләренә. Сүз уңаеннан, ипинең генә дә бездә 14 төре пешерелә. «Колос» маркасы белән 2010 елдан – кукуруз таякчыклары, ә 2011 елдан макарон ризыклары чыгара башладык. 2015 елда кондитер цехы эшләп китте, аның татлы продукциясе Татарстанның нефть төбәге кешеләренең бәйрәм табыннары өчен тәмле-томлы бизәккә әверелде. Пешкән ризыклар һәм кондитер тәм-томнары балаларга да, өлкәннәргә дә ошый.

Предприятиенең заманча лабораториясендә җитештерелүче продукциянең һәм кулланыла торган чималның сыйфатына контроль ясала. Моңа бездә аерым игътибар бирелә!

Бүгенге көндә Лениногорскиның «Колос» икмәк заводы – динамик үсештәге предприятие. Без шәһәр, район, край һәм төбәкләрдә үткәрелә торган күп кенә азык-төлек күргәзмәләрендә һәм конкурсларда даими катнашабыз. «Колос» продукциясенең сыйфаты күпсанлы бүләкләр белән бәяләнгән!

2015 елның 15 июнендә күптән көтелгән хәләл җитештерү цехы ачылды. Лениногорск районы мөселманнары өчен мондый юнәлешнең булуы – продукциябезнең дини канунннарга туры килүенә дәлил булып тора. Безнең продукция Мөселман диния нәзарәте тарафыннан сертификацияләнгән.

Бүгенге көндә **«Колос» брендлы** продукция Лениногорскида, Әлмәттә, Нурлатта, Баулыда, Азнакайда, Бөгелмәдә, һәм шулай ук Лениногорск һәм Әлмәт районнарында сатыла. «Колос» ул – 200дән артык исемдәге икмәк-күмәч ризыгы.

Реклама

PRESSA.RU

Агрохолдинг республиканың биш районын үз эченә ала: Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Зәй, Түбән Кама, шулай ук Самара өлкәсенең Келәүле районын. Авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданы 70 мең гектарны тәшкил итә, анда бөртеклеләр һәм май культуралары, бәрәңге үстерелә.

«СОЮЗ-АГРО»: ТЫРЫШЛЫКЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРЕП, ИҢ ЯХШЫГА ОМТЫЛАБЫЗ...

Соңгы егерме елда илнең авыл хуҗалыгы структурасы җитди үзгәрешләргә дучар булды – коллектив хуҗалыкларның күбесе моны кичерә алмады. Әмма үрнәк мисаллар да һәрвакыт табыла, «Союз-Агро» ҖЧҖ – әнә шундыйларның берсе.

Ринат Вафин,
«Союз-Агро» ҖЧҖ директоры

Унөч ел элек, берничә колхозны берләштереп һәм акча һәм персонал белән җитәкчелек итүне үзәкләштереп, агрохолдинг бу хуҗалыкларның күтәрелүенә ирешә. Аякка басу юлында күп киртәләр үтелә, әмма нәкъ менә хуҗалыкларга бердәм система буларак консолидацияле мөнәсәбәт һәр аерым хуҗалыкның бурычларын хәл итәргә мөмкинлек тудыра.

Хәзерге вакытта «Союз-Агро» ҖЧҖ авыл хуҗалыгы тармагында төбәк әйдәманнарының берсе булып тора һәм җир мәйданнары һәм терлекнең баш саны буенча республика предприятиеләренең беренче унлыгына керә.

«Союз-Агро» ҖЧҖдә заманча авыл хуҗалыгы техникасы паркы кулланыла, анда заманча 50 комбайн, 260тан 560ка кадәр ат көче егәрлегенә ия 30 трактор һәм биш мал азыгы җыю комплексы бар.

Төбәк сәнәгать комплекслары белән идарә итү аппараты (РПК) «Союз-Агро»ның Әлмәт шәһәрендәге бердәм офисында үзәкләштерелгән. Мәсьәләнең болай куелышы финанс агымнары хәрәкәтен грамоталы бүләргә һәм координацияләргә, логистика һәм транспорт системасын вакытында күзәтеп торырга, бердәм бухгалтерлык исәбен алып барырга ярдәм итә. Агрохолдингның эшләү дәвамында аңа бөлү чигенә җиткән хуҗалыклар да килеп кушылды. Аларның эшчәнлеге тиешле тәртипкә китерелеп хуҗалыклар инде бердәм агрофирма составында кабат торгызылды.

Хәзерге вакытка холдингның эше җитештерелә торган продукциянең сыйфатын яхшыртуга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә юнәлтелгән. Соңгы биш елда «Союз-Агро» мөгезле эре терлекнең баш санын өч меңнән сигез меңгә кадәр җиткерде. 3800 баш савым сыерына исәпләнгән «Актүбә» заманча терлекчелек комплексының беренче чираты кулланууга тапшырылды, үсемлекчелектә агрохолдинг яңа технологияләр куллана, узган елдан анда No-TiLL* ысулы гамәлгә кертелде, ул җирне эшкәртү чараларына гына экономия ясап калмый, хезмәт чыгымнарын да оптимальләштерергә мөмкинлек тудыра. Предприятиедә хәзер 600дән артык кеше эшли, квалификацияле белгечләрнең – механизатор һәм агрономнарның җитешмәвенә карамастан, предприятие, яшь белгечләрне җәлеп итү максатында, югары һәм махсус урта уку йортлары белән элемтәләр урнаштыра алды. Холдинг эшчеләре өчен тудырылган хезмәт шартлары хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга ярдәм итә һәм җитештерү ярышларында югары урыннар яуларга мөмкинлек тудыра.

«Союз-Агро» ҖЧҖ авыл хуҗалыгы күргәзмәләрендә берничә тапкыр бүләкләр алды. Предприятие бөтен көчен яңа уңышларга ирешүгә һәм компаниянең киләчәк үсешенә юнәлтә. Бер үк вакытта яңа җитештерү объектлары төзелә, булганнары үзгәртеп корыла, ике элеваторны киңәйтү буенча эшләр алып барыла, үсемлекчелек һәм терлекчелектә өр-яңа технологияләр кертелә. Алга барырга һәм камилләшергә омтылу – бу һәрвакыт уңышның нигезе!

* Ноу-Тилл.

Фото: elitat.ru

Реклама



«ЛЕНИНОГОРСКАЯ» АГРОФИРМАСЫ – РАЙОНДА ИҢ ЭРЕСЕ

Районда авыл хуҗалыгы гадәти булмаган шартларда алып барыла: таулы җирлек, бөтен җирдә – нефть «качалка»лары. Игелекле Лениногорск җире район кешеләрен бай уңышы белән тәэмин итә, ә җир асты татарстанлыларга үзенең кара алтынын бирә! Әмма бу бүләкләрне алу өчен бик күп көч куярга, заманча механизмнар һәм машиналарны эшкә җигәргә кирәк.

Ирек Ягафәров, генераль директор

«Лениногорская» агрофирмасы» 2010 елда 11 хуҗалык базасында оештырыла һәм Лениногорск муниципаль районының иң эре авыл хуҗалыгы җитештерүчесе булып санала. Культураларны эшкәртү 32270 гектар сөрү җирләрендә алып барыла, аның 6540 гектары Чирмешән районы территориясенә туры килә.

– Узган ел авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре өчен җиңел булмады, – ди генераль директор Ирек Ягафәров. – Агрофирма эшчеләреннән бик күп көч, тәҗрибә һәм һөнәрилек таләп ителде. Гамәлгә куючыбыз – «Татагролизинг» ААҖ һәм төрле баскычтагы бюджет ярдәме белән агрофирманың җитештерү-икътисадый потенциалын саклап калырга һәм лаеклы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин булды. 2016 елда агрофирма тарафыннан 52743 мең тонна бөртеклеләр алынды. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 30%ка күбрәк иде. Уртача уңыш бер гектардан 29,4 центнерны тәшкил итте – бу 2015 елгыдан 7 центнерга артыграк. Без – районда шикәр чөгендере һәм бәрәңге кебек культуралар үстерүне яңартып җибәргән берданбер предприятие. 2016 елда шикәр чөгендеренең гомуми уңышы – 8810 тонна, гектарыннан 320 центнер тәшкил итте. 2015 елдан без кукурузны орлыкка үстерә башладык, ә 2016 елдан – көнбагыш һәм карабодайны.

Районда терлекчелекнең торышы да күбесенчә «Лениногорская» агрофирмасының хезмәт нәтиҗәлелегенә бәйле. Бүгенге көндә биредә 5054 баш мөгезле эре терлек асрала, шулар исәбендә – 1600 сыер. Район терлекләренең 38%ы «Лениногорская» агрофирмасында тупланган. 2017 елның 1 июненә 3784 тонна сөт җитештерелгән (узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 214 тоннага артыграк), ул районда җитештерелгән гомуми сөт күләменең 51%ын тәшкил итә. Мондый күрсәткечләргә югары культуралы җир эшкәртү һәм тиешле ветеринар-зоотехник чаралар үткәрү нәтиҗәсендә ирешелгән.

Агрофирма үсешенә салынган капиталь кертемнәр күләме соңгы елларда үсә бара, әйтик, 2016 ел өчен ул 552 млн сумны тәшкил иткән. Кыска арада автопарк яңартылган һәм баетылган. Ел саен агрофирма бүлекчәләрендә планлы төзелеш эшләре алып барыла.

Бүгенге көндә «Лениногорская» агрофирмасында 450 кеше эшли, аларның аена уртача хезмәт хакы 24813 сумны тәшкил иткән, 2015 ел белән чагыштырганда – 8%ка артык. Алар – үз эшләрен белүче әйбәт белгечләр. Агрофирма җитәкчелеге җитештерүчән хезмәт өчен бөтен шартларны тудырырга тырыша, алдынгыларны бүләкли һәм башка эшчеләрдә дә уңышка мотивация тудыра.

«Лениногорская» агрофирмасы – бай уңыш бирә торган 32270 гектар сөрүлек җирләре. Техника һәм квалификацияле кадрлар Лениногорск ягының байлыкларыннан максималь рәвештә нәтиҗәле файдалану мөмкинлеге бирә.

Реклама

PRESSA.RU

Лениногорск үзәк хастаханәсендә 877 табиб һәм урта медицина хезмәткәре эшли. Алар арасында ТРның алты атказанган табибы бар, икесе «Сәламәтлек саклау отличнигы» билгесе белән бүләкләнгән.

ЛЕНИНОГОРСК ҮРХ – УЛ ӨР-ЯҢА ҖИҺАЗЛАР ҺӘМ КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ПЕРСОНАЛ

Үзенең эшләү дәверендә зур булмаган стационар өр-яңа технологик җиһазлар һәм диагностика аппаратурасы белән тәэмин ителгән күп профильле дәвалау учреждениесенә әверелгән. Лениногорск районы хакимияте шулай ук башка шәһәрләрдән чакырылган яшь белгечләрнең уңайлыклары булган фатирларга урнашуын да кайгырткан – моның өчен хастаханә бүлекләренең берсен үзгәртеп корганнар.

Айдар Яркәев,
«Лениногорск ҮРХ» ДАССУнең баш табибы

Хастаханәнең тарихы 1946 елдан, 25 койкалы стационардан башлана, беренче баш табиб Николай Семёнов була. 1956 елда аны Нури Хәсәнов алыштыра, бу вакытка хастаханәдә инде 260 койка куелган була, хезмәтләр махсуслаша башлый, нефтьчеләргә хезмәт күрсәтүнең цех принцибын кулланырга, халыкка диспансеризация үткәрергә керешәләр.

Хәзер «Лениногорск үзәк хастаханәсе» ДАССУ – заманча зур комплекс, ул үз эченә реанимация һәм операция блогын; дәваханәне һәм терапия, травматология, кардиология, инфекция, хирургия бүлекләре булган стационарны; районара балалар хирургиясе һәм реанимация үзәкләре булган балалар стационарын; бала тудыру йортын һәм гинекология бүлеген; неврология, отоларингология, офтальмология һәм эндокринология буенча ярдәм күрсәтүче медицина-санитария частен; ашыгыч медицина ярдәме станциясен; стоматология дәваханәсен; Шөгер һәм Иске Куак табиблык амбулаторияләрен; 29 фельдшер-акушерлык пунктын ала. Үзәкнең үз клиника, биохимия, бактериология, серология һәм СПИД-лабораторияләре бар.

Лениногорскига нигез салынуның 60 еллыгына 1978 елда торгызылган балалар хастаханәсе үзгәртеп төзелгән. Модернизация өчен акча республика бюджетыннан бүлеп бирелгән. Дәвалау учреждениесендә югары технологияле реанимация, хирургия һәм диагностика җиһазлары урнаштырылган.

Авыл халкына сыйфатлы хезмәт күрсәтү өчен күп нәрсәләр эшләнә. Лениногорск ҮРХ белгечләре, профилактик күзәтүләр үткәрү һәм дәвалануга мохтаҗ пациентларны ачыклау максатында, ел саен участок хастаханәләренә чыга. Беренчел медицина-санитария ярдәмен камилләштерү буенча республика программасы кысаларында районда модульле ФАПлар төзелә. Алтысы инде төзелгән һәм эшли башлаган, быел тагын берсе – Керкәле авылында ачылачак.

2017 елда 30 койкага исәпләнгән кан тамырлары үзәге ачыла. Ул төгәл диагнозны ачыкларга мөмкинлек бирүче тулы диагностика үткәрү өчен кирәкле бөтен нәрсә белән тәэмин ителәчәк. 2018 елда гемодиализ үзәген ачу күздә тотыла.

Хастаханәнең бердәм коллективына баш табиб Айдар Яркәев җитәкчелек итә. Ул матди-техник базаны ныгыту, дәвалау һәм диагностика процессларын камилләштерү, Лениногорск ҮРХгә квалификацияле белгечләр җәлеп итү өчен бик күп хезмәт куя.

Хезмәткәрләргә эшләү һәм яшәү өчен яхшы шартлар, профессиональ үсеш мөмкинлекләре һәм коллективтагы игелекле атмосфера – болар барысы да кешеләрнең хезмәткә мөнәсәбәтендә яхшы чагылыш таба. Медиклар һәр пациентка мөмкин булганча ярдәм итү өчен бөтен көчен куя.

Реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

«Родничок» балалар бакчасында 170 бала тәрбияләнә. Биредә алар өчен заманча техника чаралары, интерактив такталар, балалар компьютерлары, акыл сәләтен үстерә торган уеннар һәм әсбаплар булдырылган. Болар барысы да нефтьчеләр бүләге.

«РОДНИЧОК» – КЕЧКЕНӘ ШАҺИНӘЛӘР ҺӘМ ШАХЗАДӘЛӘР ӨЧЕН ӘКИЯТИ САРАЙ

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен оешмаларның бала тәрбияләүдәге төп бурычлары – аның табигать тарафыннан бирелгән талантларын ачу, балада шәхес күрү һәм тәрбияләү, сабыйда җәмгыятьтә үзен дөрес тоту күнекмәләрен булдыру. «Родничок»та моның белән мөдир Надежда Загородская һәм өлкән тәрбияче Вера Павельева җитәкчелегендәге тулы бер квалификацияле педагоглар штаты шөгыльләнә.

2013 елда, Татарстан нефтенең табылуына 70 ел тулу датасы уңае белән, Лениногорскиның яшь нефтьче гаиләләр яши торган микрорайоннарының берсендә «Бала тәрбияләүнең заманча үзәге – «Родничок» балалар бакчасы» үз ишекләрен ачып җибәрә.Ул без моңарчы ияләшкән балалар бакчаларыннан тышкы кыяфәте белән дә, өр-яңа концепциясе белән дә аерылып тора – фасады әкияттәге сарайларны хәтерләтә. «Лениногорскнефть» НГТИ ГАҖ нефтьчеләре һәм шәһәр администрациясе чын мәгънәсендә тырышканнар. Монда балалар акыллы һәм тәрбияле булып үссен, телләр үзләштерсен, мөмкинлекләрен ача алсын, сәламәт һәм бәхетле булсын өчен барысы да каралган. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен психолог, татар теле һәм инглиз теле кабинетлары бар, төрле түгәрәкләр, рәсем һәм хореография студияләре эшли, шулай ук логопункт, музыка залы, кышкы бакча, бассейн, спортзал, галокамера һәм физиотерапевт кабинеты да күздә тотылган.

«Родничок» педагогларның профессиональ осталыгын үстерү үзәге дә. Биредә квалификацияне күтәрү курслары, төрле дәрәҗәдәге педагогларның методик берләшмәләре бар, ике дәүләт телен үзләштерү буенча укыту-методик курсын тормышка ашыру мәйданы уңышлы эшли. Балалар бакчасы базасында муниципаль, региональ һәм республика дәрәҗәсендәге чаралар уздырыла.

Балалар бакчасына үз эшенең чын осталары тупланган, аларны «балалар тәрбияләүче белгечләр» дип атасаң, дөресрәк булыр: педагоглар Галина Хәсәнова, Людмила Чилигина, Анджелла Рыкова, Людмила Дорошина, Зөлфия Гордеева, Анастасия Галимова, Елена Никифорова, Галия Әгълиева.

Рәсем студиясендә рәсем ясауның һәм гомумән рәсем сәнгатенең төп нечкәлекләренә өйрәтәләр. Укытучылары – Нина Крылова. Музыка буенча җитәкчеләр – Земфира Ганиева белән Ольга Семенова балаларны җырларга һәм биергә өйрәтә. Алар тәрбиясендәге сәләтле балалар «Лениногорская звезда», «Одарята», «Музыкальный калейдоскоп», шулай ук «Созвездие-Йолдызлык» кебек бәйгеләрдә берничә тапкыр югары урыннар яулаган.

«Родничок»та юлда йөрү кагыйдәләре турында да онытмыйлар. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар заманча тематик җиһазлар урнаштырылган махсус кабинетта шөгыльләнә: биредә юл билгеләре белән светофорлардан башлап, тренажер һәм интерактив уеннар өстәленә кадәр бар. Дәресләрне инспекторлар Наталия Голунова һәм Кристина Фазлыева алып бара. Җәен юл йөрү кагыйдәләре серләренә балалар «Родничок»ка Зөлфия Рахманова җитәкләгән «Юл йөрү куркынычсызлыгы» ДБУ тарафыннан бүләк ителгән автошәһәрчектә төшенә.

Балалар үзәгендә тәрбияләнеп чыгучыларның мәктәп бусагасына килгәндә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар үзләштерергә тиешле программа буенча күрсәткечләре гаять югары була.

Балалар «Родничок»ны ярата, чөнки мондагы педагоглар «Баланың балалар бакчасында уздырган һәр көне игелек, яктылык, ярату белән өретелгән һәм кабатланмас булырга тиеш» дигән кагыйдәне нигез итеп эшли.

Реклама

PRESSA.RU

ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

ЛЕНИНОГОРСК ПОЛИТЕХНИКА КӨЛЛИЯТЕ

ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ТАРМАК РЕСУРС ҮЗӘГЕ

ПРОФЕССИОНАЛЛАР ӘЗЕРЛИБЕЗ – КИЛӘЧӘКНЕ ТӘЭМИН ИТӘБЕЗ!

Көллияттәге барлык әзерлек юнәлешләре дә төбәк үсешенең тармак өстенлекләре белән тыгыз бәйләнештә тора һәм Лениногорск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары гаризаларына нигезләнеп башкарыла.

Лениногорск политехника көллиятенең барлыкка килү тарихы Ромашкино нефть чыганагының ачылуы һәм Лениногорск шәһәренә нигез салыну белән бәйле. Шушы еллар дәвамында уку йорты шәһәр, район һәм республика предприятиеләре өчен 30 000нән артык квалификацияле эшче кадр әзерләде.

Рафаэль Кашапов, Лениногорск политехника көллияте директоры

– Безнең көллият үз эшенең осталарын әзерләүнең чын остаханәсе, дисәк тә була. Бездә укып чыккан ике меңнән артык белгеч югары дәүләт бүләкләренә ия булды, күбесе икътисадның төрле тармакларында җитәкче урыннарда эшли, – дип сөйли уку йортының директоры Рафаэль Кашапов. – 2015 елдан көллият һөнәри белем бирүнең тармак ресурс үзәге булып исәпләнә, «Транснефть-Прикамье» АҖнең бу юнәлештәге партнёр предприятиесе дә булып тора ул. Безнең студентлар җитештерү һәм диплом алды практикасы базалары белән тәэмин ителгән, укытучылар исә шәһәр һәм район предприятиеләрендә стажировка уза һәм квалификациясен күтәрә. Күп кенә оешма җитәкчеләре студентларга уку практикасын уздыру мөмкинлеге тудыру өчен, уку йортын җиһазларга булыша.

Лениногорск политехника көллиятен алдынгы уку йорты дип исәпләнеләр, чөнки биредә уку-укыту процессы барышында укытуның нәтиҗәле формалары һәм ысулларын куллануга, эшчеләр һәм белгечләрне һөнәри яктан әзерләүдә заманча практикалар кертүгә өстенлек бирәләр. Көллият Worldskills хәрәкәтендә катнаша – яшь профессионалларТОП-50 исемлегенә кергән уку-укыту программаларын тормышка ашыра, Гамәли квалификацияләрнең күпфункцияле үзәге (ГККҮ) базасында кадрлар әзерләү белән шөгыльләнә. ГККҮ – политехника көллиятенең структур бүлекчәсе, аның төп бурычлары түбәндәгеләр: квалификацияне әзерләү, яңадан әзерләү һәм күтәрү; яңа җиһазларны, чиктәш һөнәрләрне һәм белгечлекләрне үзләштерү.

– Көллияттә күпкырлы, гармонияле шәхес тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирелә, – дип дәвам итә Рафаэль Фәритович. – Студентның берничә елга сузылган уку барышында бу максат һөнәри әзерлек белән беррәттән башкарыла, шулай ук заманча иҗтимагый шартлар һәм җәмгыятьтәге таләпләр дә исәпкә алына. Студентлар шәһәрнең үзендә, районнарда һәм республикада уза торган күпсанлы спорт бәйгеләрендә һәм мәдәни чараларда катнашалар. Гадәттә призлы урыннар белән куандыралар.

Реклама

МОНДА БАЛАЛАРНЫ МАТУРЛЫККА ӨЙРӘТӘЛӘР

Хыялларның чынга ашу гадәте бар. Моның өчен үҗәтлек күрсәтергә, күп көч сарыф итәргә, гомереңне кызганмаска һәм җаныңны шушы хыял хакына корбан итәргә кирәк! Халык рәссамы Мәснави Хәйретдинов күптәнге хыялын нәкъ шулай тормышка ашырган да. Ә хыялы – Лениногорскида балалар өчен Сәнгать мәктәбе ачу була. 1976 елда Балалар сәнгать мәктәбе үз ишекләрен ачып җибәрә һәм бирегә шәһәрнең бөтен почмакларыннан сәләтле балалар агыла башлый.

1980 елда уку йорты яңа дүрт катлы бинага күчеп урнаша – тәрәзәләре һәм диварлары пыяладан булган иркен, якты бүлмәләре, уңайлы остаханәләре, диварда эленеп торган киндерләре һәм холл буйлап тезелеп киткән сыннары белән күзне иркәли ул. Балалар сәнгать мәктәбендә яшь талантларны үстерү өчен барлык шартлар да тудырылган: җиһазланган остаханәләр, күргәзмә залы, бай китапханә, натуралар фонды, әвәләп ясау һәм уеп ясау өчен махсус лаборант бүлмәләре, сәнгати тукыма остаханәсе. Мәктәпкә 600 яшь рәссам, сынчы, декоратор һәм дизайнер йөри.

1982 елдан алып 2007 елга кадәр Балалар сәнгать мәктәбен ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Полина Неклюдова җитәкли. Талантлы оештыручы, яхшы күңелле зат буларак искә алалар аны биредә. Нәкъ менә ул килгәч, коллектив актив рәвештә шәһәр тормышында катнаша башлый, балаларның эшләрен төрле дәрәҗәдәге конкурсларга алып чыгалар.

Мәктәп – охшаш фикердә һәм карашта булган кешеләрнең берләшмәсе. Хәзер Балалар сәнгать мәктәбе штатында 35 хезмәткәр исәпләнә. Һәр мөгаллимнең үз юнәлеше бар: рәсем, рәсем сәнгате, композиция, сәнгати тукыма, батик, кәгазь пластика, әвәләп ясау, дизайн. Бер генә шәһәр чарасы да Балалар сәнгать мәктәбе катнашыннан башка узмый, чөнки биредә иҗади һәм тынгысыз мөгаллимнәр эшли, укучыларын да шуңа өйрәтәләр.

Балаларга бик күп көчен һәм мәхәббәтен бүләк иткән педагогларның берсе – уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Т.Сувернева, хәзер аның вазыйфасында – Т.Постнова. Директорга хуҗалык эшләре буенча А.Ильина ярдәм итә.

2007 елдан мәктәпне Эльмира Галәмова җитәкли. Аның кул астындагы яшь коллектив балаларны сәнгатькә якынайта, матурлыкны күрергә һәм сурәтле белергә өйрәтә. Педагоглар үз укучыларын шулай ук республикабызның мәдәни мирасына игътибарлы булырга, милли колоритны тояргa күнектерә. Тирә-ягындагы матурлыкны күрмичә-тоймыйча, ватаныңны яратырга да өйрәнеп булмый бит!

Лениногорск Балалар сәнгать мәктәбе укучылары – «Мәгариф» милли проекты кысаларында ТР талантлы яшьләргә ярдәм итү өчен булдырган премия лауреатлары, ТР Мәдәният министрлыгы стипендиантлары. Алар республика һәм халыкара бәйгеләрдә ел саен призлы урыннар яулыйлар.

Реклама

ЛЕНИНОГОРСК ХАЛКЫ ТОРМЫШЫНДА МУЗЫКА

Лениногрскиның гаҗәеп матур урынында – су янында Н.М. Кудашев исемендәге Балалар музыка мәктәбе урнашкан. Бу мәктәп ике елдан үзенең 65 яшьлеген билгеләп узачак. Күптән көтелгән яңа бинаны мәктәп өчен нефтьчеләр 2005 елда торгыза. «Татнефть» ГАҖ һәм «Лениногорскнефть» НГТИ шәһәрнең 50 еллыгы уңае белән бу бинаны балаларга бүләк итә. Мәктәптә үсеп килүче буынга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү өчен барлык уңайлыклар тудырылган.

– Биредә югары һөнәри осталыкка ия булган дустанә коллектив оешты. Директор инициативасы белән укытучылар икенче музыка коралын үзләштерде. Бу аларның иҗади эшчәнлегендә кирәк булган диапазонны киңәйтергә ярдәм итә, шулай ук кадрлар мәсьәләсен эчке резерв ярдәмендә хәл итәргә мөмкинлек бирә. Мөгаллимнәр хәзер ике уен коралы буенча да класс алып бара алалар.

Мәктәптә үз эшен яраткан, музыкага тугры кешеләр эшли. Алар – музыка сәнгатенең чын белгечләре. Шуңа да укучылары искиткеч нәтиҗәләр күрсәтә – халыкара, бөтенроссия һәм республика бәйгеләрендә даими рәвештә призлы урыннар алалар.

«Владимира Спиваков Фонды Академиясе» оештырган «Балалар-балаларга» мәдәни-мәгариф проектында катнашулары да – әһәмиятле вакыйгаларның берсе. Проектның йомгаклау чарасы үткән ноябрьдә нәкъ менә Лениногрск шәһәрендә булды. Балалар музыка мәктәбендә инде өч тапкыр фортепиано ансамбльләренең төбәк бәйгесе дә уздырылды.

– Һәр елны музыка мәктәбенә язылырга теләүчеләрнең саны арта гына бара, конкурс нигезендә сайлап алырга туры килә, – ди музыка мәктәбенең директоры, югары квалификацион категорияле укытучы Рафаэль Шакирҗанович Әхмәтҗанов. – Ата-аналар шушы прагматик дәвердә балаларны матурлыкны тоярга өйрәтүнең ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген күңелләре белән тоялар. Музыка аша бала дөньяның гармониясен ишетә-күрә башлый. Музыка шулай ук сабырлыкка, чыдамлыкка, тырышлыкка, дисциплинага өйрәтә, моннан тыш, фикерләү сәләтен үстерә һәм күзаллауны киңәйтә. Бу сыйфатлар исә балага киләчәк тормышында һичшиксез кирәк булачак.

Монда эшләүче 28 укытучының 16сы югары квалификацион категориягә ия, берсе – ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, икесе «Мәдәният өлкәсендәге казанышлар өчен» күкрәк билгесен йөртүчеләр. Музыка мәктәбенә 340 бала йөри.

Реклама

PRESSA.RU

«САРЕТ» – КИЛӘЧӘКНЕҢ КОМФОРТЛЫ ЙОРТЛАРЫ

Лениногорск бүген күзгә күренеп үзгәрде, заманчалашты. Яңа типтагы биналар белән микрорайоннар ыспай һәм матур гына мондагы мохиткә ярашты. Үзенчәлекле архитектура проектлары, тәвәккәл дизайн, якты, җете төсләр... – бу йортларда яшисе килә!

Шәһәрнең яңача төзелешен һәм яңарышын гадәти булмаган исемгә ия компания тәэмин итте – «Сарет». Борынгы голланд телендә бу сүз «кондыз» дигәнне аңлата икән. Нәкъ менә әлеге тырыш, булдыклы җәнлектәй, компания дә йорт арты йорт торгыза, шулай итеп яңа территорияләрне үзләштерә һәм Лениногорскиның иске районнарына заманча төсмер кертә. Җирле халык «Сарет» төзегән йортларда яшәргә хыяллана.

– Безнең компания 2006 елда барлыкка килде, шуннан соң инде дистәләгән торак йорт төзелде һәм кулланылышка тапшырылды, – дип сөйли «Сарет» ҖЧҖнең директоры Рафис Гәрәев. – Без даими үсештә, төзелешнең традицион ысуллары белән беррәттән өр-яңа технологияләрне дә үзләштерәбез. Төзүчеләребез планировканы рациональ эшләүгә генә ирешеп калмады, ә фасадларны югары сәнгати күркәмлеккә ия итеп бизи дә алды. Совет дәверенең мирасы булган хрущевкалар, сталинкалар һәм ленинградкалар инде үткәнгә күчеп бара. «Сарет» турында, шикләнмичә, шәһәр төзелеше юнәлешендәге яңа сүз, дип әйтергә була. Төрле биеклектәге заманча торак йортларны Лениногорск халкы үз итә. Бу йортлар Европа өйләрен хәтерләтә – кешегә яшәргә уңайлы булсын дип эшләнгән, шуңа да анда яшәүчеләр үзләрен рәхәт һәм ышанычлы хис итә.

«Сарет» компаниясенең финанс-хуҗалык сәясәте җентекләп уйланылган – өстенлекне җитди сыйфат сынавын узган җирле төзелеш материалларына бирәләр, шулай ук җирле подрядчы оешмаларны җәлеп итәләр, монысы да хезмәт базарындагы шартларны яхшырта.

«Сарет» югары комфортлылыкка ия булган торак йортлар төзү барышында энергия саклау һәм экология бурычларын да комплекслы хәл итә. Фатирдагы сәламәт микроклимат – бу җылылык белән һава агышының дөрес бүленеше дә, читтән кергән тавышларның йотылышы да, җил йөрешенең һәм тузан әйләнешенең үтемле көйләнеше дә, җылы идәннәр белән тәэмин ителеш тә. Фатирларда вентиляциянең үтемле ысулы файдаланыла – тышкы һава «Пурмо Эйр» фин фирмасы җитештергән вентиляция системасы аша торакларга инде чистартылып һәм җылытылып килеп керә. Подъездлар энергияне саклый торган яктыртү системасына көйләнгән. Барысы да Европаның иң шәп йортларындагы кебек!

«Сарет» компаниясе төзегән йортлар – бу әйләнә-тирә мохитне һәм кешене, биосферага зыян китермичә, гармонияле, уңайлы рәвештә берләштерү. «Сарет» төзегән йортларда яшәүчеләр өй тирәсендәге территориянең уңайлы булуына да куана: балалар өчен хәстәрләнгән уен мәйданнары, кунаклар өчен каралган парковка урыннары, каплаулы кер элү урыннары, беседкалар. Төзелеш башланганчы әйләнә-тирәдә үсеп утырган агачлар белән куакларны да юкка чыгармаска, сакларга тырышалар.

– «Сарет» үз алдына шәһәр халкын киләчәк йортлары белән тәэмин итү бурычын куйды, – ди Рафис Рәисевич. – Лениногорск кешеләре бүгенгә заманның һәм үзебездәге, һәм чит илләрдәге тенденцияләренә туры килердәй йортларында яшәргә хокуклы.

Алдагы планнары арасында үзенең эчке уңайлыклары буенча да, тышкы кыяфәте ягыннан да моңа кадәр төзелгән тораклардан бөтенләе белән аерылып торучы күпкатлы йорт торгызу каралган. Проект якын арада Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты белән берлектә тормышка ашырылачак.

Реклама

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

PRESSA.RU

Ибн Фадлан Алмыш хан каршында Багдад хәлифе әл-Мөкътәдирнең хатын укый. Авторы: Н.Хаҗиәхмәтов, 1997 ел.

БЕРЕНЧЕ БАШКАЛА

Журналыбызның узган санында болгар тарихындагы әлегә кадәр җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән, кайбер очракларда галимнәр арасында хәтта кискен бәхәсләр уятып җибәргән проблемалар хакында сөйләшә башлаган идек. Бу кызыклы теманы дәвам итәргә кирәк, дип саныйм. Болгар иленең әүвәлге башкаласы һәм болгарларда ислам дине таралуына кагылышлы проблемалар әле бүген дә галимнәрнең игътибар үзәгендә.

БАШКАЛА БОЛГАРМЫ?

«Болгармы беренче башкала, Биләрме?» проблемасын чишүдә, минемчә, эчтәлеген тәрлечә, кем ничек тели шулай аңларга мөмкинлек бирә торган фрагментар язма чыганакларны түгел, бәлки археология материалларын кулланып эш итү әһәмиятлерәк.

Соңгы елларда кайбер рус галимнәре болгар калалары һәм авыллары, элегрәк уйланылганча, IX гасыр ахырында – X гасыр башында түгел, ә бераз соңрак, X гасырның икенче яртысында һәм ахырларында гына барлыкка килгәннәр, дип тәкрарлый башладылар. Дөрес, Болгарны алар иң борынгы кала дип санайлар һәм аның барлыкка килү вакытын X гасырның 20–30 нчы еллары дип раслыйлар. Әмма шунысы бар: әгәр дә без моңа кадәр Болгарның иң борынгы өлеше хәзерге Җәмигъ мәчете, Төньяк һәм Көнчыгыш тәрбәләр тирәсендә булган дип йөрсәк, хәзер аны көнчыгыштарак, Кече Иерусалим чокыры тамагында, аның Иделгә якын урнашкан җирендә эзлиләр. Эш шунда ки: 1980–1990 нчы елларда П.Н. Старостин биредә казу эшләре алып барган иде. X гасыр башларына караган табылдыклар арасында 894/95, 898/99 елларда Саманид идарәчеләре тарафыннан сугылган көмеш дирһәмнәр дә бар иде. Шул табылдыкларга нигезләнеп, Болгарның барлыкка килү вакытын X гасырның 20 нче еллары дип билгеләделәр. Димәк, әлеге галимнәр фикеренчә, 922 елда Багдад илчелеге килгәч, Алмыш хан Ибн Фадланны һәм аның юлдашларын шушы чокырда, аның ике сөзәк ярына урнашкан кечкенә «шәһәрчектә» каршылаган булып чыга.

П.Н. Старостин казылмаларыннан чыккан табылдыкларны, минемчә, башкача да аңлатырга мөмкин. Ныгытылган кала буларак, Болгар буш урында барлыкка килмәгән. Шәһәр төзелә башлаганчы ук, һәрхәлдә, IX гасырның ахырларында (элегрәк тә булырга мөмкин) биредә, һичшиксез, халык яшәгән – көмеш дирһәмнәр шул хакта сөйлиләр. Әмма «чын» шәһәрнең, ягъни без бүген белгән Болгарның барлыкка килүе соңрак чорга карый кебек, чөнки Ибн Фадлан үзенең язмаларында бер генә болгар шәһәрен дә телгә алмый. Белгәнебезчә, Алмыш хан Багдад хәлифе Мөкътәдиргә язган хатында, дошманнарыннан саклану өчен кочле кала торгызырга ярдәм итәрлек тәзүче осталар җибәрүен сорый, һәм аның бу үтенече үтәлә. Болгар, Сувар, Биләр ише калалар якынча бер үк вакытта барлыкка киләләр һәм аларны торгызуда, археология материаллары күрсәткәнчә, Шәрык илләреннән килгән осталар катнаша.

Болгар археологиясен ярыйсы гына тирән өйрәнгән галим буларак, басым ясап әйтәсем килә: X–XI гасырларда тупланган юка гына VI катламда әлеге шәһәрне башкала буларак күрсәтә торган материаллар юк дәрәҗәсендә. Шәһәр кечкенә, соңгы 80 ел чамасы вакыт эчендә казып тикшерелгән торак йортлар саны дистәдән артмый, кирпеч-таш биналарның эзе дә юк, табылдыклар сирәк очрый…

БИЛӘР ҺӘМ ӘҖМЕР

Бәлки болгар бабаларыбызның башкаласы Биләрдә булгандыр? Гомеремнең яртысын Биләр археологиясенә багышласам да, бу сорауга кистереп кенә җавап бирергә ашыкмыйм. Беләбез ич: 922 елда Ислам динен дәүләт дине буларак рәсми рәвештә кабул итү тантанасы Идел буенда урнашкан бер җирдә, әйтергә кирәк, сәүдә үзәгендә (Ибн Фадлан биредә ерак Скандинавиядән килгән рус/варяг сәүдәгәрләре белән очраша) үткәрелә. Ул «җир» кайда урнашкан икән соң? Болгарда, диләр күпләр, уйлап та тормыйча. Шигем бар.

Ибн Фадлан язмаларына күз төшереп алыйк. Ул үзенең Болгар иленә килү юлын болай тасвирлый: «Без башкортлар иленнән кузгалып киттек һәм Чирмешән (Олы Чирмешән, хәзерге Самара өлкәсендә – авт.) елгасын кичеп чыктык, аннан соң Үрән (Урень) елгасын, аннан соң Урым елгасын, аннан соң Байнах (Майна, хәзерге Ульяновск өлкәсендә – авт.), аннан соң Ватыг (Утка) елгасын, аннан

Автор:
Фаяз Хуҗин

Фотолар автордан алынды

Багдад илчесенең Болгарга килүе. Рәссам: В.Лаптев.

соң Нийасна (Бездна) елгасын, аннан соң Җаушыз елгасын кичеп чыктык». Билгеле булганча, Ватыг елгасында Сувар шәһәре урнашкан. Картага күз төшерегез: Сувар белән Болгар арасында (аралары 70 чакрым) елгалар юк, ә Ибн Фадлан Ватыг елгасыннан соң тагын ике елганың исемен атый, аларның берсен, Нийасна исемлесен, галимнәр Бизнә (Бездна) елгасы белән тиңләштерә. Дөрес, Бизнә Иделгә түгел, Камага коя, ә бит Каманы Шәрык географлары Идел/Итил дип атаганнар. Менә шул Бизнә белән Актай елгалары арасында, Спас районының Әҗмер авылы янында, 1961 елдан башлап, Казан археологлары болгарларның бик зур – мәйданы 62 гектарга җитә торган сәүдә-һөнәрчелек үзәген тикшерәләр. Кызганыч, бу археологик истәлек Куйбышев сусаклагычы астында калган, әмма язын-көзен, су бераз кимегән чорда, борынгы авыл урынында күпсанлы табылдыклар җыеп алырга, төрле корылма эзләрен казып чыгарырга мөмкин. Ә табылдыклар гади генә түгел: ике йөздән артык көмеш дирһәм (арада 814, 902–908 елларда сугылганнары да бар!), дүрт йөзләп тимер һәм бронзадан ясалган үлчәү герләре, йөзләгән муенса төймәләре, бакыр-көмештән эшләнгән бизәнү әйберләре, һөнәрчеләрнең эш кораллары...

Хәзер менә чагыштырып карагыз Болгар белән Әҗмер материалларын, теләмәсәң дә, әүвәлге башкалабыз һәм дә болгарларның ислам динен кабул иткән урыны Әҗмердә түгелме соң, дип уйлап куярга мәҗбүрсең.

Ә Биләрне кая куярга, ул да бит башкала статусына дәгъва кылучы шәһәрләр арасында?! Әйе, Биләр дә шул ук X гасырда башкала булган дип уйларга нигез бар. Башкала бит ул – бигрәк тә урта гасырлар чорында! – еш кына күчеп йөргән. Ханның ставкасы кайда – шунда башкала. Болгар илендә сәүдә нык үскән, язын-җәен Иделдә урнашкан калаларда ярминкәләр үткәрелгән. Ярминкәләргә ерак илләрдән сәүдә кәрваннары, елга буйлап сәүдә кораблары килеп торган. Ибн Фадлан язганча, Алмыш хан чит ил корабларын шәхсән үзе каршы ала торган була, чөнки сатарга алып килгән товарларның уннан бер өлеше, кагыйдә буларак, дәүләт казнасына тәгаенләнгән. Шулай икән, Алмыш хан елның бер өлешен шул заманның атаклы сәүдә үзәкләрендә – Болгарда һәм Әҗмердә (тарихи исеме билгеле түгел) үткәргән, дип уйларга нигез бар. Ханның җәйге ставкасы Болгарда икән, димәк, чит илдән килгән сәүдәгәрләр күзлегеннән чыгып караганда, ул – башкала, Әҗмердә икән, Әҗмер – башкала. Ә бит шул ук сәүдәгәрләр – Шәрык географларына Болгар иле турында мәгълүмат биреп торучы затлар да.

Ә менә Болгар иленең иң зур һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге буларак танылган, Евразиянең гигант калалары рәтендә йөргән Биләрдә ханның даими резенденциясе урнашкан булырга тиеш, минемчә. Аның чын исеме дә Болгар булмадымы икән әле, чөнки 1135, 1150 елларда Болгарда торып киткән Андалузия (Көньяк Испания) сәяхәтчесе Әбү-Хәмид әл-Гарнати аны «искиткеч зур шәһәр» дип атый. X гасырда яшәгән Шәрык галимнәренең хезмәтләрендә «халыкара сәүдә пункты», «сәүдә пристане» буларак танылган «Тышкы Болгар» исемле «кечкенә генә» шәһәр телгә алына. Бу шәһәрне хәзерге Болгар белән тәңгәлләштерергә мөмкиндер, дип уйлыйм (бу фикерне элегрәк остазым Альфред Халиков әйткән

Алмыш хан 921 елда Багдад илчелеген кабул итә. Рәссам: Ф.Халиков.

PRESSA.RU



Болгар һәйкәлләрен казу вакытында табылган Каргалы кылычлары.

Сугышчан болгар балталары.



Болгар һәйкәлләре.

иде). Аның чәчәк атып яшәгән, икътисадый һәм мәдәни яктан иң нык үскән чоры Алтын Урда дәүләте кысаларында була. Болгарның шул чордагы данын беренче нигезсез рәвештә монголларга кадәрге чорга күчереп куюу тарихи чынбарлыкка туры килми. Фәндә ныклап урнашкан рәсми концепцияләрне, традицияләрне сындыру ничек кенә авыр булмасын, әлеге мәсьәлә киләчәктә үзенә яңача караш ташлауны, бу өлкәдә җитди тикшеренүләр алып баруны таләп итә.

ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮ

Болгарларда рәсми рәвештә ислам дине кабул итү тантаналары борынгы Әҗмер авылы янында үтмәдеме икән, дип фаразлаган идек. Мин үзем әлеге проблеманы артык җитдигә санамыйм. Әмма бу проблеманың галимнәр арасында җитди бәхәсләр кузгата торган принципиаль яклары да бар. Шулар турында бер-ике сүз әйтеп китү урынлы булыр.

Билгеле булганча, болгарлар ислам дине белән әле VIII гасырда ук танышалар. 737 елда, Хәзәр дәүләте гарәпләр тарафыннан җиңелгәннән соң, каган ислам динен кабул итәргә мәҗбүр була. Илдә әкренләп ислам дине тарала башлый, әмма археология материаллары (мөселман йоласы буенча күмелгән каберләр-зиратлар болгарлар күпләп яшәгән Азов диңгезе һәм Дон елгасы тирәләрендә өйрәнелгән) башлыча IX гасырга гына карый. Хәзәр иленнән Урта Иделгә күчеп утырган болгарлар арасында мөселманнар да була. Фарсы географы Ибн Рөстәнең X йөз башында язылган бер хезмәтендә (андагы мәгълүматлар IX гасыр ахырына карый) болгар авылларында-мәчетләр, ә мәчетләр каршында башлангыч мәктәпләр булуы турында хәбәр урнаштырылган. Ибн Фадлан язмаларына караганда, тарихи 922 елга кадәр болгарларның күпчелеге ислам диненә күчеп беткән була инде. Бу факт археология материаллары белән дә раслана: Болгар дәүләте җирлегендә X гасырга караган мәҗүси зиратлар юк. Авыл-шәһәр урыннарын казыганда килеп чыккан меңләгән хайван сөякләре арасында мөселманнарда хәрам саналган бер генә дуңгыз сөяген дә очратмассың. Зиратларда мәетләрне тулысынча мөселман йолалары белән күмгәннәр. Язма документлардан күренгәнчә, болгарлар мөселманча киенеп йөргәннәр, яшәү рәвешләре белән дә саф мөселманнардан аерылып тормаганнар. Мәчетләр төзегәннәр, балаларын мәктәпләрдә укытканнар, мөселман илләре белән тыгыз элемтә урнаштырганнар.

Әмма соңгы елларда рус һәм чуваш галимнәре арасында, монгол яуларына кадәрге Болгар илендә ислам динен башлыча югары катлау кешеләре генә тоткан, гади халык исә элеккечә мәҗүси аллаларына табынуларын дәвам иткән, дигән караш тарала башлады. Яңача ка-

раш археология материалларына нигезләнгән, имеш. Нинди материаллар соң алар?

Чувашия Республикасының көньяк-көнчыгыш өлешендә, Батыр районы Тигашево авылы янында, кечкенә генә бер болгар шәһәрлеге урнашкан. Бу шәһәрлек урынында, имеш, элегрәк мәҗүси болгар кабиләләренең килеп гыйбәдәт кыла, төрле йолалар үткәрә торган изге урыны булган. Бу изге урынның эзләре койма белән уратып алынган мәйданчык эчендә казылган дүрт чокыр рәвешендә сакланып калган. Чокырларның берсендә сыерның, икенчесендә атның баш сөякләре, өченчесендә атның аяк сөякләре, ватылган чүлмәк кисәкләре, көл-күмер ише нәрсәләр табылган. Шуның белән шул, кем әйтмешли. Мондый чүплек чокырлары борынгы торак пунктларын казыганда күпләп табыла; аларны, көл-күмер бар икән, димәк, бередә учак якканнар, ат-сыер сөяге табылган икән – корбан китергәннәр дип аңлатырга, чүп базыннан изге урын ясарга берниндн нигез юк. Изге урын булса, аны җимертеп, юкка чыгарып, урынына ныгытылган утар – «замок» төзеп куймас иде мәҗүси болгар феодалы.

Чуваш галиме Н.И. Егоров фикеренчә, ислам дине болгар-татарларга бары тик Алтын Урда чорында гына актив рәвештә тарала башлый, Казан ханлыгы чорында исә ныклап тамыр җәя. XVIII йөзгә кадәр мәҗүсилектән котыла алмаган чувашларның «болгар бабаларын» мәҗүсиләр итеп күрергә теләүләре аңлашыла, әлбәттә, әмма бит фактлар мондый фикерләргә ачыктан-ачык каршы килә. Аларны күрмәмешкә сабышу – мәгънәсезлек. Бөҗра уртасына үрдәк урнаштырылган алтын алкаларны да, барс фигурасына охшатып эшләнгән бронза йозакларны да, хайван, кош сурәтле балалар уенчыкларын да болгарларда «чәчәк аткан» мәҗүсилек билгеләре итеп карарга кирәкмидер, минемчә.

Шулай да монголларга кадәрге Идел Болгарында мәҗүсилекнең эзе дә булмаган дип әйтү чынбарлыкка туры килмәс иде. Күршедә генә Урал-Идел буе финнары – бүгенге коми, удмурт, мари, мордваларның борынгы бабалары яшәгән иҷ. Болгар аларны магнит кебек гел үзенә тартып торган, күчеп утыручылар да бихисап булган. Бирегә килеп яши башлауга ук, алар ислам динен кабул иткәннәр, дип уйларга ярамый. Болгарлашу, ислам диненә күчү процессы буыннарга сузылган. Чыннан да, XI гасырга караган кайбер зиратларда мөселман күмү йоласыннан тайпылышлар күзәтелә, аларны шул процессның чагылышы, дип карарга кирәктер.

Болгар тарихында ахыргача хәл ителеп бетмәгән бәхәсле мәсьәләләр күп әле. Аларның бер өлешен киләчәктә табылачак яңа чыганаклар нигезендә чишәрбез, дигән өмет бар.

Варяг – рус дружинасында скандинав сугышчысы. X гасыр уртасы. О. Федорова реконструкциясе.



Болгардагы Ага-базар. Рәссам: К.Нәфыйков. 1976 ел.

PRESSA.RU

СУСАУ...

Татарлар кайда гына яшәми! Ерак Көнчыгыштан алып Көнбатышка кадәр. Күбесенең тамырлары Татарстанга барып тоташа. Соңгы вакытта аларның шактые янә туган якларына әйләнеп кайта башлады. Күрәсең, лаеклы ялга чыккач, адәм баласын ата-ана нигезе, туган туфрак тартадыр.

Редакциябезгә Лангепас шәһәрендә гомер иткән Наилә Әхмәдиева килеп китте. Ул – җирле телевидениедә татар тапшыруы булдырган, гимназиядә татар балаларына туган тел дәресләре ачкан, «Агыйдел», «Ләйсән» җыр-бию ансамбле оештырган, Татар автономиясен төзүне башлап йөргән тынгысыз ханым. Аның белән Лангепас татарлары, халыкның яшәеше, андагы милләттәшләрне борчыган проблемалар хакында сөйләштек.

Автор:
Руфия Фазылова

ВАГОНЛЫ ТОРМЫШ

Лангепас – Төмән өлкәсенең Ханты-Манси округына караган шәһәре. Хантлар теленнән «Тиеннәр атавы» дигәнне аңлата. Мондый исем юкка гына бирелмәгән, җирле урманнарда тиеннәрнең исәбе-хисабы юк. Биредә 44 меңгә якын кеше яши, шуларның 10 меңе – татарлар (халык саны буенча татарлар өченче урында). Лангепас чагыштырмача яшь әле: 1980 елда нигез салынган. Аны махсус нефтьчеләр өчен төзегәннәр. Биш ел эчендә эшчеләр бистәсе шәһәр статусы алган, чөнки кеше саны көнләп түгел, сәгатьләп арткан. СССРның барлык төбәкләреннән халык биредә эшкә агылган.

Бүгенге Лангепас – Көнбатыш Себернең заманча, яшәргә уңайлы булган шәһәре. 2007, 2008, 2009 елларда ул «Ханты-Манси округының иң төзек, барлык уңайлыклары булган шәһәре» исеменә лаек булган. Биредә әлегә ун микрорайон бар. Һава шартларына килгәндә, җәй бездәгегә караганда салкынча, уртача 18 градус җылы. Ә кышын 50 градуска кадәр суык. Табигать тә үзенчәлекле: мүк җиләге, каражиләк, нарат җиләге, әрбет чикләвеге үсә. Әйткәнемчә, агачларда тиеннәр сикерешә, урманда аюлар яши...

Наилә Әхмәдиеваның Лангепаска барып төпләнүенә 34 ел узган. Һөнәре буенча татар теле, әдәбияты укытучысы. Тумышы белән Апас районы Урта Балтай авылыннан. Педагогия институтын тәмамлагач, яшь белгечне күрше Олы Бакырчы авылына эшкә җибәрәләр. Шунда ул булачак тормыш иптәше Илгиз Әхмәдиев белән таныша. Ул вакытларны искә төшереп Наилә апа болай дип сөйләде:

–1983 ел. Илгиз армиядән кайтып, Лангепас шәһәренә эшкә урнашкан иде. Без шул җәйне өйләнештек. Гаилә корып яши башлагач, ирем: «Китикме? Калыйкмы?» – диде. «Китик», – дидем. Минем эшем бар, ә Илгиз нишли? Аннан, Себердә бит хезмәт хаклары да әйбәтрәк. Шулай итеп бер чемоданыбызны кулга алып, колак ишетмәгән, күз күрмәгән шәһәргә яшәргә киттек. Баштагы мәлдә аптырап калдым: урамга чыга торган түгел, черкиләр сырып ала, краннан соргылт, комлы су ага. Аны чиләктә тондырабыз, аннан әллә ничә кат марля аша сөзәбез. Соңыннан шул су белән юынабыз. Ә эчәргә яраклы суны машина алып килә, чиләкләр белән ташыйбыз. Үзебез исә 12 квадрат метрлы вагонда яшибез. Ул елларда Лангепаста һәр гаилә диярлек шундый

Фото: Александр Ефремов

вагон-өйләрдә торды. Хәтерлим, кешеләр бер-бер артлы ике катлы агач йортларга күченә башлады. «Эх, болар нинди бәхетле кешеләр. Зур фатирда яшәячәкләр, барлык уңайлыклары өйдә», – дия идек.

Беренче улыбыз Айратка өч яшь булганда икенче улыбыз Булатны алып кайттык һәм аерым йортка күчендек. Дүрт бүлмәле фатирда ике гаилә яшәдек. Утыз сигез яшемдә төпчек кызыбыз Раиләне таптым. Ул вакытта без барлык шартлары булдырылган өч бүлмәле фатирда яши идек. Балалар бер-бер артлы үсеп буй җитте. Җәй буе әби-бабайлары янында авылда булгангамы, Татарстанны яраттылар. Укырга да Казанга киттеләр. Улларыбыз югары уку йортын тәмамлап эшли инде, кызыбыз КФУның журналистика факультетында укый.

«БЕЗ КҮБӘҮ!»

Лангепаста Наилә апа белгечлеге буенча эш тапмый. Гаҗәп түгел, Себер балалары татар теле укымый бит! Шуннан ул ире янына – элемтә бүлегенә эшкә урнаша. Авылларда спектакль, концертлар куеп йөргән, әдәбиятны, сәнгатьне яраткан яшь ханым, зур-зур җайланмалар артында утырып, элемтә сигналы киләме-юкмы икәнен тикшерергә тиеш була.

– Баштарак утырып елаган чакларым күп булды, – ди Наилә апа. – Туган якны, әти-әнине, мәктәп балаларын сагыну өстенә, җанга татар мохите җитми! Берсендә шулай эштән кайтып киләм, күзем афишаларга төште. Ялгыш күрәмме дип торам: Түбән Варта шәһәреннән татарча концерт килә. Лангепаста концерт залын тутырырлык татар бар микәнни? – дип аптырадым. Барсак, шаккаттым: зал тулы халык утыра. Түбән Варта артистларына аягүрә басып кул чаптылар. Бу хәлне күреп, күзгә яшьләр килде. Димәк, Лангепаста бар икән бит якташларыбыз, дип сөендем. Нәкъ менә шунда туды үзебезнең шәһәрдә үзешчән ансамбль төзү фикере. Ирем Илгиз каршы килмәде, чөнки үзе дә жырлый, баянда уйный. Репетицияләрне башта өйдә ясадык. Аннан мәдәният йортына бүлмә сорап баргач, директор бик хуплады. Шулай бер уйламаган җирдән ансамбль оештырдык. «Агыйдел» дип исем куштык, чөнки бу елга Татарстан белән Башкортостан арасында. Безнең ансамбльдә татар-башкортлардан тора бит. «Якташ» исемле җәмгыятебез дә барлыкка килде. Ирек Махиянов, Эдуард Галимов кебек башлап йөрүче, һәр эшебезне хуплап каршы алучы якташларыбыз бар иде.

Ике ай эчендә татарча концерт әзерләдек. Милләттәшләр бик җылы, яратып кабул итте. Шул көннән соң безнең өчен яңа тормыш башланды: милләттәшләр белән аралаштык, берләштек. 1989 ел иде ул. Бертуктаусыз концертлар куйдык. Хәтта Ханты-Манси округының 60 еллык юбилеенда чыгыш ясарга чакырдылар. Тагын да канатландык, димәк, татарларны хөрмәт итәләр...

Әлбәттә, Себер җирендә татарларның чәчәк атуы илдә барган вазгыять белән дә бәйле була: 1990нчы еллардагы милли хәрәкәтләрнең җиле Лангепаска кадәр барып җитә. Гимназиядә факультатив рәвешендә татар балалары өчен ана теле дәресе укытыла башлый. Зурлап Сабантуйлар үткәрәләр. Татар-башкортлар өчен генә түгел, бөтен халык бәйрәменә әйләнә ул. Чәй табыны артында шигырь бәйрәмнәре уза. Милли күлмәкләр тектерәләр, читекләр сатып алалар.

1991 елда Наилә Әхмәдиева Лангепас телевидениесендә «Туган тел» исемле тапшыру алып бара башлый. Әлбәттә, моның өчен башта бер ишекне бишәр кат шакырга туры килә аңа. Җирле телевидение җитәкчеләре: «Лангепаста бик күп милләтләр яши. Ни өчен татарларның гына үз тапшырулары булырга тиеш?» – дип карыйлар. Татарлар сан буенча шәһәрдә өченче урында, үзләренең ансамбльләре бар икәнлеген кат-кат аңлаткач, бушка эшләргә риза булуны ассызыклагач, ярты сәгатьлек эфир вакыты бирәләр. Шуннан җирле халык хантлар: «Ни өчен татарларга вакыт бирелә, безгә юк», – дип күтәрелеп чыга. Тик алар, башлап йөрүчеләре булмаганга, барыбер үз тапшыруларын әзерли алмый.

Лангепаста яшәүче милләттәшләребез 2011 елда Татар милли-мәдәни автономиясе төзүгә дә ирешә. Биредә рәсми рәвештә теркәлгән өч кенә милли-мәдәни автономия бар, шуларның берсе – татарныкы.

– Чит җирдә берләшәсең икән ул, – ди Наилә Әхмәдиева. – Башкортлар белән тамырлар уртак бит. Шуңа күрә татар-башкорт булып йөрибез. «Күмәк көч тау күчерә», диләр. Тагын әле «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар», дигән гыйбарә дә бар. Шуңа күрә бердәм булу кирәк. Миннән соң да Лангепаста шушы кыйммәтләр, традицияләр югалмас, дип ышанам...

PRESSA.RU

«ТАТАРЛАР ЧӘЧӘК АТМЫЙ ИНДЕ»

Наилә Әхмәдиева Себер каласыннан туган ягына кайтырга җыенуын әйтте. Җырдагыча:

«Яз да сайрый, көз дә сайрый,
Бер нәни кош бакчамда.
Шул кошны сагынып кайтам,
Кая гына барсам да...»

– Олыгайган көнебездә туган якка кайтачакбыз дип яшәдек, – ди Наилә апа. – Тормыш иптәшем Илгиз Лангепаста быел гына эшлим дип тора. Аннан туган ягыбызда йорт салырга ниятлибез.

– Ә «Туган тел» тапшыруы, ансамбль, татар теле дәресләре, Татар-башкорт милли-мәдәни автономиясе? – дим.

– Дөресен әйтергә кирәк, Лангепас татарларының милли-мәдәни тормышы 1990–2000нче еллардагы кебек чәчәк атмый инде. Сәбәпләр төрле: татар теле нәрсәгә кирәк диючеләр дә байтак. Бу эшләрне башлап, оештырып йөрүче активистлар да күп түгел. Сер түгел, җәмәгать эшләре өчен акча аз яки бөтенләй түләнми. Телевидениедә тапшыру ябылды. Ансабль эшли үзе, төрле бәйрәмнәрдә чыгыш ясыйлар. Татар теле дәресләрен миннән соң Мөслимнән килгән Лиза Бикбаева алып барды. Хәзер лаеклы ялда инде. Узган уку елыннан башлап балалар белән Гүзәл Гомәрова шөгыльләнә. Ул Татар-башкорт милли-мәдәни автономиясе рәисе Ринат Гомәровның тормыш иптәше. Бөтен өмет аларда. Эшкә үзләре кебек яшьләрне тартырлар, дип ышанам.

Лангепаста ике катлы зур мәчет бар. Җомга намазларында, Гает бәйрәмнәрендә халык шыгрым тулы була икән. Аллаһ йортына татарларга караганда Кавказ халыклары күбрәк килә. Әле берара мәчетнең имамы да чечен кешесе булган. Төрле милләт халыклары арасыннан тавыш кубудан куркып, аерым кешеләр, шәһәр администрациясенә хатлар язып, имамны эшеннән алдырганнар. Хәзер мәчеттә Самара өлкәсеннән килгән татар егете Фаил хәзрәт Салихов имамлык итә.

– 2011 елдан башлап, татар балалары ана теле дәресләрен мәчет бинасында укый, – ди Наилә Әхмәдиева. – Дәресләр шимбә, якшәмбе көннәрендә уза. Элегрәк туган телен өйрәнергә теләүче балалар

күбрәк иде, хәзер исә ун-унбиш укучы җыела. Шулай ук мәчет базасында мәдрәсә эшләп килә. Анда татардан кала мөселман диненнән булган башка малай-кызлар да килә. Шулай ук җомга көнне мәдрәсәгә хатын-кызлар да җыела, вәгазь тыңлыйлар. Ничек кенә булса да, тел, дин төшенчәләре Лангепаста әле бар. Алга таба ничек булыр, вакыт күрсәтер. Әйткәнемчә, күп очракта бу чаралар аерым кешеләр инициативасы белән генә эшләнә. Ә андый кешеләр соңгы вакытта бик күренми. Чын милли рухлы кешеләрнең күбесе пенсиягә чыгып, туган якларына кайтып китте.

КАЗАН БЕЛӘН МӨНӘСӘБӘТ

Лангепас татарларының Бөтендөнья Татар конгрессы, Казан белән мөнәсәбәте ничек соң? Бу очракта «начар түгел» сүзе кулайрак буладыр, мөгаен. Себердә яшәүче милләттәшләр Бөтендөнья Татар конгрессы, Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы үткәргән һәр чарага килә икән. Татар конгрессы Себер балаларын татар теле, әдәбияты дәреслекләре белән дә тәэмин итә.

– Казанда узган төрле чаралардан канатланып кайтабыз, – ди Наилә апа. – Башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләр белән аралашабыз, тәҗрибә уртаклашабыз. Мондый очрашулар бик кирәк. Мисал өчен, узган ел «Ак калфак» уздырган хатын-кызлар форумыннан кайткач, «Чәкчәк бәйрәмен» үткәрдек. Барлык катнашучыларга да татар халкының милли киемнәреннән килергә кушылды. Сигез уңган хуҗабикә, осталыкларын эшкә җигеп, кунаклар алдында чәкчәк пешерү серләре белән уртаклашты. Татар көйләре яңгырап торды. Бик күңелле, милләттәшләребезне берләштерүче бәйрәм булды ул. Шулай ук узган елның декабрь аенда Татар милли-мәдәни автономиясе активистлары көче белән «Бишек җыры» бәйрәме оештырдык. Себер җирендә бишек табуы авыр булыр дигән идек, хәтта ике бишек табылды! 4 бала тәрбияләүче Гүзәл һәм Ринат Гомәровлар ул-кызларын бишектә үстергән икән. Бәйрәмнең төп максаты: әбиләребез, әниләребез көйләгән бишек җырлары яшьләр дә белсен, онытмасын. Менә шундый чаралар гел уздырып тордык.

Наилә Әхмәдиева тагын бер теләк-тәкъдимен җиткерде:

– Бәлки Бөтендөнья Татар конгрессы ярдәме белән төбәкләр өчен аерым белгечләр – оештыручы көчләр әзерләргә кирәктер? Хакимият дәрәҗәсендә элемтәләрне ныгыту, татарларны берләштерү өлкәсендә күбрәк эш эшләнсә, тагын да әйбәт булыр иде. Чит җирләрдә милләттәшләр үзләренең ялгыз түгеллеген, татар теленең кирәклеген, әһәмиятен аңласыннар. Шул вакытта татар кайда гына яшәсә дә, телен, динен югалтмас.

Утыз өч ел Себердә яшәгән Наилә Әхмәдиеваны Казанга кайткач иң гаҗәпкә калдырган нәрсә – татар балаларының рус телендә сөйләшүләре икән. Аларның өч балалары да камил дәрәҗәдә туган телләрен белә. Бу руслар арасында үсеп. Ә монда, татар башкаласында, үзебезнең егет-кызлар ана телләрендә бер җөмлә әйтә алмасын!Әллә аларны Лангепаска җибәрергә инде?!

Булат Бәдретдинов, Ханты-Манси округында Татарстан Республикасының вәкаләтле вәкиле:

– Ханты-Манси округы белән Татарстанны мәдәни һәм сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләр бәйли. Округның һәр шәһәрендә, муниципаль районында ел саен Сабантуйлар уза. Моны гадәттә җирле администрация оештыра. Татарстан исә әлеге чараларга үз хисабына җырчылар, алып баручыларны җибәрә. Ханты-Манси округында яшәүче балаларга туган тел әсбаплары белән булыша. Зур чаралар булганда җитәкчеләр бер-берсенә кунакка бара, милләттәшләрнең яшәеше, мәдәнияте белән таныша. Киләчәктә дә Татарстан белән элемтә шулай тыгыз, дустанә мөнәсәбәттә булыр, дип ышанам.

PRESSA.RU

Татарстан
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
BOL'ŞEVIGE
БОЛЬШЕВИК
ТАТАРИИ

Редакция кухнясы

АКТАНЫШ ЧӘКЧӘГЕ

Автор:
Руфия Фазылова

Җәй-көз – туйлар вакыты. Безнең редакциядә ул бигрәк тә сизелә, чөнки эш бүлмәбезнең тәрәзәләре «Казан» гаилә үзәгенә карап тора. Атна азагы җитте исә үзәккә матур итеп бизәлгән дистәләгән туй машинасы агыла. Ак күлмәк кигән яшь кәләшләргә карап сокланабыз.

...Татар туена күп җирдә чәкчәк пешерәләр. Әлеге затлы ризык яшьләрнең гаилә тормышын баллы-татлы итсен, диеп, әлбәттә. Аны төрле якта төрлечә әзерлиләр. Кайдадыр ул вак кына, кайдадыр түгәрәк. Ә менә Актаныш, Азнакай, Сарман якларында аны зур итеп эшлиләр. Мондый чәкчәк авызда эреп китә. Шуның өчен без бу юлы Актанышка барырга булдык. «Иң тәмле чәкчәкне анда пешерәләр», – диделәр безгә.

«КҮРДЕМ ДӘ АЛЫП КАЙТТЫМ»

Актанышта чәкчәкне күпләр пешерә, үзе өчен. Ә менә мәҗлес, кунак җыясы, яисә күчтәнәчкә алып барасы булса, аерым кешегә әйтәләр икән. Сер түгел, һәр нәрсәнең үз остасы бар. Усы авылында яшәүче Наилә Гарипова – шундыйлардан. Чәкчәк пешертер өчен хәтта күрше районнардан да аңа киләләр икән.

Наилә апа безне бик җылы каршы алды: тавыгын суйган, токмач басып ашын пешергән. Ә йорттагы чисталык, зәвык – сокланып карап тордым.

– Йортыгыз яңа, заманча. Кайда эшлисез? – дидем сөйкемле хуҗабикәгә.

– Өйдә генә. Ирем фермада, терлекче.

– Мондый йортны ничек салып чыктыгыз? Берәр дәүләт программасына кергән идегезме?

– Юк, үзебез салдык, кредитларга бата-чума, дигәндәй. Күп итеп мал асрыйбыз. Мин элек Мәдәният йортында эшләдем. Аз гына акчага көн-төн шунда ятарга кирәк. Йорттагы эшләргә вакыт калмый башлагач, эштән киттем.

Гариповлар өч ул үстерә. Олы малайлары Фәдис үз гаиләсен корган инде. Уртанчылары Рәдис Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятендә белем ала. Кечесе Вәдис – мәктәптә, дүртенче сыйныфны тәмамлаган.

Без аш өстәленә утыргач, гаилә башлыгы Фазылҗан абый да кайтып җитте. Берничә йорт аркылы гына яшәүче әнисе – Кәшифә апаны алырга киткән булган.

– «Казаннан кунаклар килә», – дигәч кенә безгә килергә ризалашты, – дип көлде Фазылҗан абый. Җор телле, шат күңелле улына җавап итеп Кәшифә апа:

– Аякларым бетте, йөрергә кыен. Шуңа өйдән чыгарга бик тырышмыйм, – дип куйды.

Кәшифә апага 90 тулган. Мәрхүм тормыш иптәше белән дүрт бала үстергән. Фазылҗан абый төпчеге икән.

– Башка балаларым авылда калмады. Әле ярый төпчеге янымда гына яши. Көнгә ике дә, өч тә керәләр, – ди Кәшифә апа.

Ир белән хатынның танышу тарихлары турында сорашам:

– Дустым: «Уразай авылында чибәр, бик тырыш кыз бар. Таныштырыйммы?» – дигән иде, ике дә уйламыйча шунда киттем, – дип сөйли башлады Фазылҗан абый. –Яшь бар, 33 тулган иде. Бер яхшы кыз очраса, өйләнәм дип йөргән чагым. Наилә ул вакытта колхоз ашханәсендә эшли. Башта ашханәгә кереп күзәтеп чыктым. Бик сөйкемле, җыйнак гәүдәле,

НАИЛӘ ГАРИПОВАДАН ЧӘКЧӘК РЕЦЕПТЫ:

1. Йомырка – 10 данә
2. Он – 0,5 кг
3. Сыек май – 1 литр
4. Бал – 0,5 кг
5. Шикәр комы – 0,5 кг
6. Су – чама белән (кайнап торган сыек майга салу өчен)

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU

1. Туглыйбыз!

2. Он кушабыз!

3. Тәгәрәтәбез!

4. Кисәбез!

5. Майга салабыз!

6. Сөзәбез!

7. Балландырабыз!

8. Тезәбез!

аңа гашыйк булмыйча мөмкин түгел иде. Шуннан дустым безне таныштырды. Без очрашып озак йөрмәдек, бер ай дигәндә өйләнештек. Мин гади, туры кеше, Наиләгә: «Әйдә, вакытны бушка уздырып йөрмик, өйләнешик!» – дидем. Ул ризалашты.

Сүзгә Наилә апа да кушылды:

– Кияүгә чыкканда миңа 23 яшь иде. Без гаиләдә 11 бала. Акыллы, тырыш егет булса, кияүгә чыгар идем, дип уйладым. Бер йортта әллә ничә кеше җыелышып ятып булмый бит инде. Үз оямны корасы килә. Шуңа күрә Фазылҗан тәкъдимен кире какмадым.

– Ә ярату? – дим.

– Ярату булган инде ул, – ди Фазылҗан абый тыйнак кына. – Шундый кызны яратмый мөмкин түгел. Ун яшькә олы булгач, Наиләнең әти-әнисе каршы килмәсме, дип, башта борчылган да идем. Шикләрем юкка булган. Мин хәзер дә хатыныма сокланам. Сабыр да ул, чибәр дә. Өч ул бүләк итте. Тагын ни кирәк?!

Кәшифә апа улы сөйләгәннәрне тыныч кына тыңлап утырды. Аннан, нәтиҗә чыгаргандай:

– Мин дә өйлән дип гел әйтә килдем. Ир кешегә гаиләсез калырга ярамый, – диде.

«ТУҢДЫРЫЛГАН ЙОМЫРКА КИРӘК»

Кәшифә апа Гарипова кайчандыр үзе дә чәкчәк пешерү остасы булган. Кунак килсә дә, балалар сораса да – хәстәрли идем, ди. Дөрес, ул чагында алар бу татлы ризыкны туң майда пешергәннәр.

– Актанышта чәкчәк ясый белми торган хатын-кыз юк иде, – дип сөйләде Кәшифә апа. – Хәзер аны озынча итеп кисәләр, безнең чәкчәк түгәрәк формада була иде. Наилә аны икенче төрле пешерә.

«Икенче төрле» дигәне, Наилә апа элеккегеләрдән аермалы буларак, чәкчәккә дигән йомыркаларны башта суыткыч камерасына куеп туңдыра икән. Болай иткәндә камыр әйбәтрәк килеп чыга, майга пешерергә салгач, күбек кебек кабара, ди.

Без Кәшифә апа белән сөйләшкән арада Наилә апа чәкчәк өчен кирәк булган ризыкларны өстәлгә тезде.

– Йомырканы суыткыч камерасыннан кичтән алып калдырдым, – диде хуҗабикә. – Төн чыкканчы эри ул. Шуны миксер белән яхшылап берничә минут болгатам да он кушам.

Наилә апа, тизрәк булсын өчен, чәкчәкне ун йомыркадан эшлим, диде. Гадәттә, 20–30дан ясый. Өчәр килолы чәкчәккә заказ бирәләр икән. Ә гаилә өчен әзерләгәндә уннан да җитә, өч зур савыт чәкчәк чыга.

– Йомыркага чәй содасы, шикәр комы да салмыйсызмы? – дип сорыйм Наилә ападан, кызыксынып.

– Юк, бернәрсә дә кирәк түгел. – Камыр уңсын өчен, иң мөһиме – йомырканы әйбәтләп болгату. Ул үзеннән-үзе кабара. Кайбер вакытта камырга бер-ике кашык сыек май да кушам. Кәефкә карап, төрлечә. Майның әллә ни файдасын да, зыянын да күрмим үзе.

Шуннан Наилә апа йомшак кына камыр басты. Йомырка һәм он гына салып, башка берни дә өстәмичә. Камырны бүлеп алып, озын «бармаклар» тәгәрәтте. Һәм шуларны, ике башын очлы итеп калдырып, 7–8 см озынлыгында кисеп чыкты.

– Мин чәкчәкнең очларын озынча итәм, чөнки аларны бер-берсе эченә тыгып өеп менәм, – диде Наилә апа.

Бу урында Гариповларның уртанчы улы Рәдис ясаган видеоролик турында язасым килә. Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте студенты, әнисенең чәкчәк пешергәнен видеога төшереп, интернетка куйган. Һәм һәр эш алымының астына аңлатма язган. Мисал өчен: куна

тактасында яткан киселгән төшләргә: «Безне нәрсә көтә?», төшләрне кайнап чыккан майга салгач: «Әй, коткарыгыз, монда пешәм!», аннан: «Нишләттегез, ни өчен мин болай кабардым?» кебек шаян юллар бар. Бу, чынлап та, дөреслеккә туры килә. Кечкенә төшләр, майга салгач, акрын-акрын кабара, аннан кызара башлый. Өч-биш минут дигәндә, чәкчәк төшләре әзер була.

– Төшләрне кайнап торган майга салырга ярамый, шартлап ярылалар, – дип, киңәшләрен бирә барды Наилә апа. – Сыек майны, кайнап чыккач, азрак суытып алырга кирәк. Ләкин чәкчәкне күпләп әзерләгәндә, майны һаман саен суытып торырга җай булмый. Шуңа күрә мин майга бер-ике кашык салкын су салам.

– Май чәчрәмиме? – дим.

– Юк, чәчрәми. Әйбәт кенә була.

Наилә апа төшләрне табагы белән сөзгечкә салды. Пешкән төшләр сөзгечтә калды, ә кайнар май кәстрүлгә агып төште. Ул майны янә табакка салып, газга куйды. Һәм 1–2 аш кашыгы су салды. Янәдән төшләрне салды. Шул рәвешле барлык төшләрне пешереп бетергәнче, кырык минутлап вакыт узды.

– Утыз йомыркадан пешерәм дисез, бик күп вакытны ала икән бит, – дим Наилә апага.

– Әйе, кайвакыт төне буе йокламыйм. Гадәттә, кемне дә булса ярдәмгә чакырам: иремне яки улларымны. Алар төшләрне бутап тора, мин камыр әвәлим, кисәм. Бергә эшләгәндә тизрәк ул. Ә төшләрне бал белән кушу, аннан матурлап тезү, бизәү – анысы минем өстә генә.

«ЧИТ ИЛЛӘРГӘ ДӘ АЛЫП КИТӘЛӘР»

Эшнең иң күңелле урынына җиттек: төшләрне «балландыру». 10 йомыркадан ясаган чәкчәк өчен 500 граммлы банка белән бал һәм шуның кадәр үк шикәр комы кирәк.

– Тәмле балдан күп нәрсә тора, – диде Наилә апа. – Чәкчәк төшләре бер-берсенә ябыша да, тәме дә татлы була. Шуның өчен яхшы бал алырга тырышам.

– Балны кайдан аласыз?

– Авылдашлардан, танышлардан. Еш пешергәч, бездә бал тиз бетә.

– Күпмедән саталар?

– Гел ала торган клиент буларак миңа ташлама ясыйлар, өч литрлы банканы 1000 сумга бирәләр. Быел бал начар диләр, ничек булыр, белмим.

Наилә апа бал белән шикәр комын бергә кушып, яхшылап болгатты да сүрән утка куйды. Кайнап чыкканнан соң 5–7 минут утта торарга кирәк. Бал белән шикәр комы бергә кушылып, куе бер масса хасил итәргә тиеш.

– Гадәттә, тикшереп карыйм: әзер массаны кашык белән алам да бер-ике тамчы салкын суга тамызам. Бал белән шикәр комы катнашмасы, суда таралып китмичә, тамчыланып тора икән, димәк, ул әзер, катнашманы төшләр өстенә салырга була, дигән сүз.

Наилә апа төшләр белән баллы катнашманы бергә кушты. Чәкчәк әзерләүдә безнең өчен иң ошаганы шушы эш булды. Төшләр ялтырап, гәрәбәдәй балкып киттеләр. Әйтерсең лә аларга җан керде: бер-берсенә ябышып «йөри башладылар».

– Төшләр балланды, эш бетте, – диде Наилә апа да. – Чәкчәк булсын өчен, аларны бергә өясе генә калды. Мин, гадәттә, заказ белән эшләгәндә, моның кадәр төштән бер оя ясыйм. Бу юлы, айдә, өчкә бүлик…

Хуҗабикә төшләрне тезеп чыкты: берсен болай гына, ничек туры килде, шулай өйде. Икенчесен пирамидага охшатып ясады. Фантазияне эшкә җигеп, төшләрне төрлечә өяргә була икән: кәрзин ясарга да, түгәрәк тә…

– Заказларыгыз күпме? – дим Наилә апага.

– Җитәрлек, аеруча җәй көннәрендә, туйлар чорында, күп була. Кайберәүләрнең өйләренә барып пешерәм. Кучтәнәчкә дип заказ бирәләр. Актаныш администрациясеннән дә киләләр. Әле менә шушы көннәрдә ике зур чәкчәк пешереп җибәрдем. Татарстаннан Казахстанга бер төркем халык делегация булып бара икән, минем чәкчәкне кучтәнәчкә алып киттеләр. Районга зур кунаклар килсә дә, чәкчәк әзерләргә миңа әйтәләр. Чит илләрдә узган Сабантуйлар өчен дә пешергәнем бар.

Наилә апа хәтта Президент Владимир Путинның сыйныф җитәкчесенә дә махсус чәкчәк пешергән. Кыскасы, Актаныш районының Усы авылында әзерләнгән, татар, башкортның милли йөзе булган әлеге ризык бөтен дөньяны гизгән.

...Эш беткәч, Наилә апа янә табын янына чакырды. Ит бәлеше пешергән икән, махсус, безгә дип. Бәлеш ашап, чәкчәк белән чәй эчтек. Икесе дә искитмәле тәмле.

– Бөтен ризыкны шулай оста әзерлисезме? Кайдан өйрәндегез? – дим Наилә апага.

– Чәкчәк пешерергә яшьтән өйрәндем, әнинең апасыннан. Аларга еш кына кунакка бара идем. Ә бәлешне безнең якта бөтен кеше әзерли. Гомер иткәндә өйрәнәсең инде. Гаиләбез дә зур, тәмле әйбер пешергәнне көтеп кенә торалар.

– Заказга чәкчәк пешерүнең файдасы каламы соң?

– Бер дә калмаса, пешермәс идем. Чәкчәкнең килосын 400 сумнан сатам. Йомырка үзебезнеке, сыек майны күпләп алып куябыз. Онны тагын – капчыклап. Кулга акча кереп килгәч, чыгымнары, мәшәкатьләре дә онытыла. Авылда эш юк бит, нишлисең. Ипилек-тозлык акча чыга үзе.

Бу гаилә безне тәмам үзләренә гашыйк итте. Йортның яктылыгы, пөхтәлеге уңган хуҗабикәдән торса, балаларның тәрбиялелеге гел догада булган Кәшифә ападан күрдек. Биш вакыт намазын калдырмаган изге күңелле әбинең оныклары начар булмас. Ә җитеш тормыш, һичшиксез, үткен телле Фазылҗан абыйның тырышлыгы, булдыклылыгы нәтиҗәсе.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ



«Татарстан» журналының
әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – белешмә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.



Ләлә Нәгыйм кызы Сабирова Татарстанның Биектау районы Мәмдәл авылында туган. Казан дәүләт университетында югары белем алганнан соң, «Татарстан яшьләре» редакциясендә эшләгән. 17 ел дәвамында Биектау районы Олы Битаман авылында татар теле укыткан. 1988 елдан – «Сабантуй» газетасы редакциясендә, 1995 елдан әлеге балалар газетасының баш мөхәррире вазыйфасын үтәгән. Балалар өчен язылган китаплар авторы. «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» (1997 ел). Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (1995 елдан).

Ләлә Сабирова

РӘХӘТКӘ ЧЫДАП КАРА

ГӨЛНАЗ

– Әни, Фирдүс миңа, беләсеңме, ни дип әйтте? Ирдәүкә син, диде!

Гөлназ бик әсәренеп кайткан иде. Гөлнира аны ничек җайларга белмәде.

– Әллә ни начар сүз түгел инде ул, кызыкаем! Малайлар шикелле көчле син дип әйтүе булгандыр.

– Юк шул! Ул аны ямьсез итеп әйтте! Әйдә, барып, арт сабагын укытып кайтыйк әле!

Анысы Гөлнираның үз сүзе. Берәрсенә ачуы килеп кайтса, кызын: «Ярар, барып, арт сабагын укытып кайтырмын», – дип тынычландыра.

Башбирмәс булып үсеп килә Гөлназ... Әле мәктәпкә дә кермәгән, бөтен авыл баласын «утлы таба»да биетә. Авыл дип... Бер генә урамнан тора инде ул, бөтенесен бергә исәпләсәң, күп дигәндә биш-алты бала җыеладыр. Олысы-кечесенә Гөлназ хуҗа, авызына гына карап торалар. Гөлнисаның исе китә. Әтисе генә өнәми:

– Нишләп бер дә кыз балага охшамагандыр бу? – дип сукрана.

– Ник охшамасын! – ди Гөлнира андый чакта, башын артка чөеп. – Юаш булсаң, асарлар... Минем бәхеткә туган бала, гомерле булсын!

Ул аны олыгаеп кына тапты. Илназлары мәктәпне бетерү алдында тора иде инде. Шул бер малайны үстереп бетерсәк, җиткән дип, әллә ни пошынмый гына яшиләр иде, Гөлнира нык кына чирләп китте. Бармаган табибы калмады.

– Вакытың узмаган, бала табып карарга кирәк сиңа, – диде күрше авылдагы өшкерүче әби. – Терелтсә, шул гына терелтә сине.

Ышанды бит шуңа Гөлнира. Әллә шул ышануы ярдәм итте, Гөлназ аңа икенче тормыш биргәндәй булды. Шуңа күрә җае килгән саен кызын, алдына утыртып:

– Син булмасаң, мин дә юк идем инде, – дип, тупылдатып сөя.

Дүртенчедә укыганда микән, Гөлназ бервакыт кибеттә ак җирлегенә гөлҗимеш рәсеме төшерелгән кул сәгате күреп кайтты.

– Әйдә, әни, алып кайтыйк әле шуны миңа! – диде.

Гөлнираның каладан кунаклар көткән чагы, ашыга-ашыга мич ашы пешереп маташа иде.

– Аннары, кызым, аннары... Иртәгә дә качмый ул, өлгерербез, – диде.

Гөлназ кызарынып китте, күзләре шунда ук яшь белән тулды.

– Алай икән... Кунаклар кадерлерәк икән... Мин булмасам, ятар идең әле караватыңда сызланып, кунаклар да кирәк булмас иде...

Гөлнира аңа шаккатып карап алды да, камырлы кулларын сөртеп, кибеткә йөгерде. Дөресе шул, нихәл итәсең...

Шуннан бирле берәр нәрсә кирәк булса, шуны гына кабатлый Гөлназ. Әнисе ул теләгәнне «эһ» дигәнче эшләп ата. Дөрес анысы, шуның аркасында әтисе белән гел сүзгә килешәләр.

– Ярар, җимешләрен үзең җыярсың әле, – ди аннары әтисе, кулын селтәп.

Ә менә Илназ абыйсына һич тә ялынып торасы юк, каладан кайткан саен сумка-сумка күчтәнәчләрне ташып кына тора. Гөлназ аның авылда яшәгән чагын бөтенләй белми, ә үзен «бәйрәм абый» дип йөртә, чөнки ул кайткан чак гел бәйрәм шикелле була. Бик ярата шул сеңлесен Илназ, кечерәк чагында аның белән курчак урынына уйный иде.

Хәзер исә гел:

– Усал малайлар тимиме соң үзеңә? – дип сораштырып кына тора. – Тисәләр, үземә генә әйт, кирәкләрен биреп китәрмен мин аларның! – ди.

Тидерәме соң Гөлназ! Алай да берәрсенә ачуы килсә:

– Бәйрәм абыйга әйтеп кыйнаттырам әле мин сине! – дип куркыта.

Классларында да гел беренче булды. Укуда да, аннан тыш та. Концерт куясы булса, иң әүвәл аңа дәшәләр иде. Җырларга да, биергә дә яратты. Укытучысының телендә аның исеме генә иде инде. Булмыйча... Өчәү генә иде бит алар класста, аннан башка тагын үзләрен дә карап йөртә белми торган ике малай бар иде. Алары башлангычтан соң укып та тормады, күрше авылдагы урта мәктәпкә Гөлназ үзе генә йөрде.



Иллюстрация: «Шах-и-Зинда. Самарканд. 1921». Кузьма Петров-Водкин.

Менә анда тормышы икенчерәккә әйләнде кызның. Гарьләнгән чаклары күп булды. Чөнки монда берәү дә аңа шаккатып карамый, аерып алып мактамый. Бервакыт бәйрәмгә концерт әзерләделәр. Гөлназ: «Мин җырлыйм!» – дип чәчрәп чыкты. Тыңлап карадылар да, икенче юлга калдырдылар. Ачуыннан шартлый язды кызый. Ничек инде – икенче юлга? Ул бит киләчәктә җырчы булырга әзерләнә, зур сәхнәләргә чыгачак әле ул, оят булмас микән сезгә шул вакытта?

Ә беркөнне математикадан контроль эш эшләгәннәр иде – дәфтәрендәге зур «өчле»не күргәч, шашып калды. Ничек? Аңамы? Үзен алырга килергә тиешле әтисен дә көтеп бетерә алмады, дәресләр бетүгә, авылларына җәяүләп чыгып чапты. Әнисенә елый-елый сөйләде:

– Юри куйган ул аны, яратмый ул укытучы мине! – диде. Гөлнира: «Ник яратмый икән?» – дип сорашмады. Бер белмәгән кешенең арт сабагын укытып йөри алмый бит инде ул!

– Ярар, исең китмәсен, – дип кенә әйтте. – Бөкресе чыкканчы шул мәктәбеңдә ятачак ул укытучың, ә синең барысы да алда! – дип юатты.

Мәктәпне бетергәндә «мин-мин»леге шактый какшаган иде Гөлназның. Шулай да әүвәлге уеннан кайтмады:

– Артистлыкка барам, түлке шуңа гына! – диде. – Илназ абый әйтә, Культура институтында танышларым бар, ди. Ярдәм итәм дип тора...

Гөлназның аттестатындагы билгеләре бик өметле булып чыкмады. Шулай да ничек итсә итте Илназ абыйсы, яраткан сеңлесен үзе теләгән институтка урнаштыра алды.

КӘРИМ

Хуш ис бөркеп торган зур казанның икесе ике «колагы»ннан Кәрим белән әнисе тотып чыкты. Табынны йөзем бакчасындагы иркен сәкегә әзерләгәннәр иде, пылауны уртадагы табакка аудардылар. Кызган суган, сарымсак, пешкән ит исе борыннарны кытыклады. Кайсы чүгәләгән, кайсы кырын яткан бала-чага, бер-берсен этләли-төртләли, табакка ябырылды. Габбаска тәлинкә бирделәр, ул үз өлешен шунда алып салды да, ашый башлаганчы сәке тирәсендәгеләргә көлемсерәп карап торды.

– Әй, сеңел... Кем уйлаган сине бер көтү бала анасы булырсың дип...

Бәнат авыр сулап куйды.

– Әйтмә дә инде... Аталары барында ярый иде әле. Суга төшкәндәй юк булды бит... Исән булса, кайткан булыр иде дим, айдан артыкка китте хәзер. Милициядә Сәмәркандның гына түгел, бөтен Үзбәкстанның астын-өскә китереп эзләдек дигән булалар, дөрестерме. Белмим, тәмам башым чуалды. Ничек үстереп бетермәк кирәк боларны! Эшкә яраклысы икәү генә, калган дүртесе сорап утыручылар...

Кәримгә унике тулып китте – әнисе аны «эшкә яраклы»га кертми әле. Чөнки акча китерә торган хезмәттә түгел, өйдәгене генә карый. Бакчаны тәртиптә тоту, мал-туар тәрбияләү – нигездә аның эше. Кичә менә Габбас абыйлары кайткан хөрмәткә соңгы сарыкларын суйдылар. Кәримгә эш җиңеләйде. Тик менә алга таба ничек булыр?

– Киттең дә баттың, сеңел. Үзебездә дә тормыш начар түгел инде, югыйсә...

– Бәхтияр сорарга кайткач, бер дә алай димәдең. Җыйнаулашып үгетләдегез... Әй, ярар, вакыты шундый булгандыр инде.

Габбас – әниләренең бертуган абыйсы, этиләренең югалу хәбәрен ишетеп, ерак Татарстаннан хәл белә килгән. Килеп ни кылды инде ул – тегендә барып, монда килеп, эзләнеп йөргән булды. Нәтиҗәсез, билгеле.

– Мин нишли алам... Бераз акча калдыра алам инде, шул. Аннары ни... Бер уй килде әле башыма. Алып китим Кәримне үзем белән. Сиңа бер тамак ким булыр.

Кәримнең эче «жу» итеп китте. Үзе ялт итеп әнисенә күтәрелеп карады. Аның дәшми утыруын күреп, тынгысызлана ук башлады. Әйтәм аны, абзасы кич буе малайдан күзен алмады. Бәнатка: «Маладис, яшенә күрә түгел, таза беләкле булып үсеп килә бу улың», – дип мактап та куйды әле.

– Бездә тормыш яхшы. Йорт-җиребез иркен. Бер генә кыз булды бит безнең. Монда тыгылышып ятканчы дим... Тамагы тук, өсте бөтен булыр.

Ул хәзер моны Кәримнең үзенә карап сөйли иде. Малайның куркуы бугазына килде, йөрәген шом басты. Табынны җыеп алгач, әнисенең үзен генә туры китереп, әйтә куйды:

– Китмим мин...

Бәнат тагын дәшмәде, хәтта аңа күтәрелеп тә карамады.

Икенче көнне иртән күп сөйләшми генә улын юлга җыендыра башлады.

– Озакка түгел бит. Өс-башыңны юнәтерсең. Бераз тормыш күрерсең. Чит кешемени – үзеңнең абзаң белән китәсең... Әле чакырып торганда...

Кәрим елады да елады. Аңа карап, энеләре дә шыңшыды.

Әнисе вокзалга төшмәскә булды, ишек төбеннән генә озатты. Кәрим капкага җиткәнче аңа каерылып-каерылып карап барды, кире чакырып алыр дип өметләнде. Ул өмет вагонга кереп урнашкач та бетеп җитмәгән иде әле, поезд «пуф-пуф» итеп кузгалып киткәч, сүнде. Кәрим дә елавыннан туктады, эчен тоташ кату алды. Ничә тәүлек баруларын да санамады, өске сәкегә менеп, сузылып ятты да уйлады да уйлады. Уйларының кайсы очына барып чыкса да, әнисен аңлый да, аклый да алмады...

(Дәвамын сайтыбызда укыгыз: www.protatarstan.ru)

PRESSA.RU

РАФАЭЛЬ ХӘКИМОВНЫҢ КИТАП КИШТӘСЕ

«Татарстан» журналы «Китап киштәсе»н яңа китаплар белән баетуны дәвам итә. Бу эштә төп ярдәмчеләре – уңышка ирешкән, халык арасында танылган шәхесләр. Алар һәрдаим ассызыклый: кайсы гына өлкәдә уңышка ирешмәсеннәр, ул уңыш китаптан башка булмас иде. Һәрберсенә китап ярдәм иткән – кемгәдер һөнәр сайларга, кемгәдер тиешле мизгелдә дөрес карар кабул итәргә, кемгәдер янәшәтирәдәгеләрне ныграк аңларга...

Бүген безне яраткан китаплары белән академик, ТР ФАнең Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов таныштыра.

БАЛАЧАКТА ҺӘМ ЯШЬЛЕКТӘ ЗУР ЙОГЫНТЫ ЯСАГАН КИТАПЛАР...

– Башка күп кенә балалар кебек үк, мин дә балачакта дөньямны онытып Тукай шигырьләрен һәм әкиятләрен укый идем, татар халык әкиятләрен. Безнең гаиләдә Пушкинның авторитеты һәрвакыт бәхәссез булды. Аның татар телендә нәшер ителгән томы миндә хәзер дә саклана. Әйбәт тәрҗемә иткән булганнар. Үсмерлек чорына кергәч, яшьтәшләрем кебек, мин дә Жюль Верн белән мавыктым, аның рухында яза торган башка авторлар белән дә. Яраткан бердәнбер китабымны аерып кына әйтә алмыйм, алар шактый җыела, санасаң. Маяковский белән «авырган» чорым булды, әмма тора-бара Көмеш чор шагыйрьләре совет чорының агитацион рухын этеп чыгарды.



ИҢ ЯРАТКАН КИТАПЛАРЫМ...

– Тукайны үсә төшкәч тә, гомер буена да укырга киңәш итәм. Ул беркайчан да урынсыз булмый, Пушкин да шулай ук. Дәрдемәнд искиткеч! Шулкадәр аз язып та, тарихка мәңгегә классик булып кереп кала алу – гаҗәеп күренеш! Студент чакта Достоевскийны ноктасы-өтеренә кадәр укып чыктым. Француз шагыйрьләре үз иде – Франсуа Вийон, Гийом Апполинер.

КҮПТӘН ТҮГЕЛ УКЫГАН КИТАПЛАРДАН КҮҢЕЛЕМӘ ТИГӘНЕ ҺӘМ ТӘЭСИРЛӘНДЕРГӘНЕ...

– Тәэсирләндергәне Карл Фукс булгандыр, мөгаен. Аңардан бик гади бер сорауга җавап эзләгән идем: татарлар инкыйлабка кадәр ни дәрәҗәдә укымышлы булганнар? Ник эзләдемме? Гүзәл Яхинаның шау-шу уяткан «Зөләйха күзләрен ача» әсәрендәге бер урын шикләндерде. Романдагы вакыйгалар Казаннан ерак түгел генә урнашкан бер авылда бара, авыл янында – кара урман. Димәк, Казан арты дигән сүз. Минем өчен кадерле җирләр бу, кече ватаным. Һәм менә Казан артындагы авылда яшәүче героиня надан итеп күрсәтелгән. Ә вакыйгалар бит инкыйлаб алдыннан һәм инкыйлаб вакытында бара. Мин шушы яклардагы ул сурәтләгәнгә охшаш авылларны барлый башладым, һәм... таба алмадым. Минем туган авылым Күлле-Кимедә барысы да укымышлы, белемле генә булып калмыйча, 1913 елда ике катлы мәктәп төзегәннәр хәтта. Мәдрәсә түгел, игътибар итегез, мәктәп. Әнием ягында да хәлләр шулайрак. Әбием Башкортостан чигендә урнашкан Тымытык авылында белем алган. Ул укыган мәдрәсә бинасы хәзергә кадәр сакланган. Әллә ни затлы мәдрәсә дә түгел, гади генә – агачтан төзелгән. Һәм менә шуны тәмамлаган әбием төрек һәм гарәп телләрендә иркен укый ала иде. Һәм ул авылда бердәнбер андый хатын-кыз да түгел иде хәтта.

Карл Фукс китабына күз салдым да шундый мәгълүматка тап булдым: «Казан татарларында хатын-кызлар да билгеле бер дәрәҗәдә белем ала, араларында укый-яза белми торганнарны бик аз очратырга мөмкин. Алар биредә төзелгән яңа мәчет мулласының хатыны – абыстайга килеп белем алалар: ул үзе укыта торган предметлар буенча зур белемгә ия ханым. Мин ул укыткан хатын-кызларның мәктүпләрен үз күзем белән күрдем һәм укыдым».

Фукс биредә авыл кызларының үзенә адресланган хатларыннан өзек тә китерә: «Сезнең алдыгызда баш иям, и мөхтәрәм тиңсез зат! Сез минем күңелемне кузгаттыгыз да, газап дәрьясына ташладыгыз! Җанымның хуҗасы сез! Сезнең алда түбәнчелек белән тез чүгәм һәм, безне чакрымнар аеруга карамастан, никадәр газиз булуыгызны раслыйм. Сез басып йөргән җирне үбә-үбә, язган юлларым арасына дога энҗеләре тезә-тезә, ошбу мәктүпне юллыйм. И газиз дустым, ташламасагыз иде мине: назлы күз карашыгызны бер күрергә тилмерәм, болытлар таралып, ялтырап чыккан кояш кебек, тормышымны яктыртсагыз иде! Яшәгез, яшәгез генә! Аллаһ көннәрегезне минем хакка озайтсын!»

Мин бүгенге теләсә кайсы татар кызының мондый затлы өслүб белән яза алуына шикләнәм. Сүз уңаеннан, Карл Фуксның китабы 1843 елда басылган.

ХӘЗЕР УКЫЙ ТОРГАН КИТАБЫМ...

– Алар шактый үзенчәлекле, эшем өчен кирәкле китаплар: Мишель Фуко, Делёз, Бодрийяр, Деррида, Бадью.

КИТАП МИНЕМ ТОРМЫШЫМДА НИНДИ УРЫН БИЛИ?

– Ул мине гомерем буена озатып барды һәм бара. Мин укып кына калмыйм, язам да аларны.

КАЙСЫ ВАРИАНТ КУЛАЙРАК: ЭЛЕКТРОН КИТАПМЫ, КӘГАЗЬ БАСМАМЫ?

– Һичшиксез, электрон. Хәтта кәгазь вариант булган очракта да мин электрон нөсхәсен эзлим.

Кәгазь басма – үткән көннәрне сагынып искә алу, үзенә күрә бер ностальгия, минемчә. Басу машинкалары, типографияләр дәвере тәмамланды инде, без электрон дөньяга аяк бастык. Моңа каршы тору – ахмаклык. Киресенчә, Интернет һәм виртуаль дөнья бирә алган мөмкинлекләрдән тулаем файдаланырга өйрәнергә кирәк.

КАЗАНГА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР КИЛГӘН КЕШЕГӘ ШӘҺӘРЕБЕЗНЕҢ ЙӨРӘК ТИБЕШЕН, РУХЫН АҢЛАР ӨЧЕН НИНДИ КИТАП УКЫРГА ТӘКЪДИМ ИТӘР ИДЕГЕЗ?



– Минемчә, бездәге атаклы кешеләр турындагы китаптан башларга кирәк. Мисал өчен, Ренат Бикбулатовның «Казан. Атаклы кешеләр» китабы. Анда чынлап та Казаныбызның рухы чагылыш тапкан. Россиядә бездәге кадәр талантлы, күренекле шәхесләрне үзенә сыйдырган тагын шундый каланы табу – җиңел эш түгел.

PRESSA.RU

ЖУРНАЛИСТЛАР КҮРГӘН ҺӘМ АЧКАН ДӨНЬЯ

Журналистларның башка профессия вәкилләреннән аермасы нәрсәдә? Минем белән сәяхәтләрдә булган танышларым әйтүенчә, детальләргә аеруча дикъкатьле булуда, һәр нәрсәгә ирония, скептицизм белән карауда, һәр мәгълүматны җентекләп тикшереп чыгуда һәм тәүлекнең 24 сәгате буена кабызып куелган диктофон ролен башкаруда. Кайчакта күз алдымда бармак шартлатып: «Бу сәяхәттән мәкалә әзерләү мәҗбүри түгел», – дип күләргә яраталар. Чынлап та шулай. Без, кайда гына булсак та, һәр нәрсәдән «материал» хәстәрләргә әзербез. Менә бу икәү шикелле…

БАКАЛАРНЫҢ ЗАТЛЫ ТОРМЫШЫ, ЯКИ НИ ӨЧЕН АЛАР БАШ КҮТӘРЕРГӘ ЯРАТА?



Жанна Агалакова. «Все, что я знаю о Париже»

«Все, что я знаю о Париже» китабында бу үзенчәлек ярылып ята. Әйтергә кирәк, тележуранналист буларак миндә зур ихтирам уяткан Жанна Агалакова язу өслүбе, фикерләү рәвеше белән дә күңелне кайтармады. Киресенчә, үзем өчен аның нечкә ирониясен, йомшак-җиңел, әмма зирәк юморын ачтым, логикасына «афәрин» дидем, структуралаштыру, композиция төзү осталыгына сокландым. Дөрес, схемалылык баштарак күңелне кырды-кыруын, әмма тора-бара ул да үзен аклады.

Китап нәкъ үз жанры таләпләренә туры килгәнчә башланып китә – Парижның Агалакова тормышына ничек килеп керүен сурәтләүдән. Автор башта безгә аның туристларга күренгән, алар өчен актуаль булган тышкы антуражын күрсәтә. Ә аннары инде, әйтерсең, кулыбыздан җитәкләп ала да, бормалырак урамнары буйлап атларга чакыра. Тирәнрәк катламнарны ача.

Бу бер тарихта бигрәк тә аермачык күренә. «Париж глазами иностранных журналистов» дигән тапшыруда катнашырга чакыралар Жанна Агалакованы. Франция башкаласында алар өчен нәрсә кадерле, нәрсә ачуларын чыгара, нәрсә гаҗәпләндерә, сокландыра, үзгәртәсе килү теләгән уята… Лояльлеге белән таң калдыручы парижлылар, ни гаҗәп, Агалакованың манифестацияләр темасын сайлавына һәм бу темага карата ирония белдерүенә һич кенә дә лояль карамыйлар. Чөнки бу алар өчен – изге нәрсә. Бу аларның ирегә һәм үз-үзләренә карата булган ихтирам хисенең чагылышы. Шулай итеп, кечкенә генә бер тарих аша без менталитетның кисемтәсен, әлеге халыкның «авырткан урынын» ваемлап алабыз. Безнең 90нчы елларны уйлап куйдым ирексездән…

Менә тагын бер тарих. Бу темага да бик сак мөнәсәбәт белдерергә кирәк икәнлегенә басым ясый автор. «Лягушки-царевны» дип атала китапның әлеге бүлеге.

> «Лягушатниками» французов стали называть англичане. До середины прошлого века лягушек во Франции ели тоннами. Так ели, что почти всех съели, и в 1980 году ловля земноводных, а также разведение их для последующего употребления в пищу были запрещены законом. Теперь со своими лягушками французы «на вы».
>
> Каждый год по весне, едва пригреет солнышко, сотни добровольцев по всей стране начинают рыть вдоль автотрасс канавы и устанавливать экраны из пленки. Дело в том, что лягушки по весне мигрируют: живут они в одном месте, а размножаются в другом. Порой им приходится пересекать приличные расстояния, и далеко не все добираются до заветного болота. Ночью квакушки, не в силах перепрыгнуть барьер из пленки, скапливаются в канавах. А на рассвете милые сердечные люди, отпросившись предварительно с работы, собирают их, непутевых, и, рискуя собственной жизнью, переносят на руках на другую сторону трассы.
>
> Это благородная добровольная миссия очень поддерживается общественностью.
>
> Я представляю диалог такого добровольца со своим работодателем:
>
> – Месье Н., отпустите меня завтра.
>
> – А что такое?
>
> – У лягушек гон пошел. Без меня не справятся…
>
> – Конечно, иди. Дело важное…

Автор:
Луиза Янсуар

К этой акции привлекают также школьников. По-французски это называется буквально «развитие чувствительности у населения». Чтобы оно, это молодое население, подходило к лягушкам с чувством, а не только с вилкой и ножом.

А едят французы (потому что они все-таки их едят!) не своих лягушек, а привозных – из Греции и Албании. Самых мясистых завозят из Индонезии».

Китапта Парижның көндәлек тормышы гына түгел, ә иҗтимагый һәм сәяси вакыйгалары да мулдан сурәтләнә. Болар барысы да укучыга нәкъ парижча, җиңеллек һәм тирәнлекне бергә кушып, үзенә күрә бер тәм белән өретелеп тәкъдим ителә. Симона де Бовуарның «Прелестные картинки», Франсуаза Саганның «Любите ли вы Брамса?» повестьлары хәтердән йөгереп уза... Әмма беллетристикадан аермалы буларак, Агалакова китабына тагын бер вазыйфа йөкләгән: аны рәхәтләнеп юл күрсәткече буларак та кулланырга мөмкин. Монда ул сурәтләгән музейлар, күргәзмәләр, сарайлар, парклар, китапханәләр, кибетләр, кафеларга... сылтамалар бирелгән. Ягъни, аерым бер сайтларга кереп, сез Луврны карап чыгар өчен билетка заказ бирә, кафеларның менюлары белән таныша аласыз.

Кайсы гына теманы кузгатмасын, Жанна Агалакова «Париж характеры» дигән феноменны ачыкларга омтылыш ясый. Детальләр, вакыйгалар, асылда, барысы да нәкъ шуңа юнәлтелгән. Тагын бер ошаган үзенчәлек: Агалакова, үзе инде ничә еллар дәвамында бу шәһәрдә яшәсә, Париж килене булса да, менторлыкка күчеп, укучысына моңсу-эчпошыргыч сәфәрдән ялыгырга урын калдырмый. Ул һәр урын турында – үзе дә беренче тапкыр күргәндәй, һәр тарихны әле менә хәзер, яңа гына кичергәндәй сөйли. Хәтта Парижның ялыктыргыч гадәтләре турында бәян иткәндә дә.

Китапта туристлар өчен файдалы булган гаять бай мәгълүмат тупланган. Монмартрда ничек йөрергә, Нотр-Дам-де-Парины кайсы ракурстан төшерергә, кибетләргә кайсы сәгатьләрдә чыгарга, метрода билетларны ничек кулланырга, кайсы кафеларда нәрсәгә заказ бирергә, ә нәрсәгә кирәкми... – кыскасы, файдалы да, акыллы да, тәмле дә...

Париж тычканнарының ни өчен сырдан гайрәтләре кайткан да, Париж дегустаторлары ни өчен кефирны гаять дефицит, затлы эчемлек дип саный... – боларын инде укып карагач кына беләчәксез. Әнә шундый тарихларны журналистларча осталык белән тәкъдим итә белә автор. Нәкъ менә алар аның, язучы буларак, беллетристик нигез тудыра алуына һәм язмаларының чын-чынлап кыйммәте барлыгына да ишарә итә.

Мин үзем өчен Париж турында бихисап күп мәгълүмат алдым, ә Жанна Агалакованы – яңадан ачтым.

«ЧЫН ИТАЛЬЯНЛЫ» КЕМ УЛ, ЯКИ БОЛОНЬЯ ПЛАЩЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ СОВЕТ МИФЫ

Вадим Глускер. «Настоящий итальянец»

«Италия турында тагын нәрсә сөйләп була инде?» Әнә шундый кереш белән башланып китә Глускерның китабы. Без аны Италияне бик ярата һәм бу хакта репортажларында, проектларында кат-кат белдерә торган тележурналист буларак беләбез. 2010 елда «В поисках Франции» исемле документаль фильм төшерү белән мәшгуль булса, 2011 елда Глускер Италиягә юнәлә. «Настоящий итальянец» дип аталган проектны һәм НТВ каналы күрсәткән документаль фильмны, бәлки, кемнәрдер хәтерлидер дә. Аны хәзер дә НТВ сайтына кереп карап була.

Мин бу проектны яхшы хәтерлим, ә менә китабы турында моңарчы белми идем. Чагыштырып карау – шәп тәҗрибә булды. Гадәттә, башта һәрчак китапка мөрәҗәгать итәргә әйдиләр укучыны. Әмма бу очрак – икенче. Мин башта фильмны карарга тәкъдим итәр идем. Алар – икесе ике жанр һәм ике төрле чыганак.

Төшерү төркеме «чын Италияне» һәм «чын итальянлы»ларны эзләп, Сицилиядән – Миланга, Сардиниядән – Туринга, Сан-Ремодан Римга кадәр юл үтә. Сәбәбе бик гади: һәрбер милләтнең үз эчендә төрле-төрле төркемнәре булган кебек, италиялләрнең дә – нәкъ шулай. Төньякта яшәүче итальян кешесе белән көньяктагысы арасында, баксаң, аерма җир белән күк арасы икән. Вадим Глускер итальян мафиозилары темасын тирәнрәк ачу өчен атаклы мафиозиның агасы белән очраша, Ватиканда була, безне Тото Кутуньо белән таныштыра. Сильвио Берлускониның моңарчы журналистлар аяк басмаган, кайда икәнлеге бирәүгә дә күрсәтелмәгән вилласындагы сөйләшү дә проектны саллы итә, әлбәттә.

Әмма чын италиялеләр – урамнарда, базарларда, мәйданнарда, гап-гади йортларда, кварталларда, дигән тәэсир калды миндә фильмны караганда. Әнә шулар җитмәде. Ә менә китапка юлыккач аңладым: китап жанры аларга да урын бирергә рөхсәт итә. Чөнки, камера кебек, каләм һәм кәгазь, иң беренче чиратта, таныш йөзләргә, медиа шәхесләргә юнәлтелмәгән. Язучы буларак, Глускер да гадирәк аудиторияне ачып салуга йөз белән борыла, һәм проектның китап варианты, перспективасы ягыннан күзгә күренеп тирәнәя. Колорит та үзгәрә. Укучы буларак, минем кызыксыну дәрәҗәм дә бермә-бер арта. Чөнки, безгә әнә шул кирәк – тормышның үз эчендә кайнап-эретелгән детальләр, язмышлар...

Әйтүенчә, иң башта Италияне ул балачак тәэсирләре буенча хәтеренә кереп уелган кыйпылчыклардан эзли башлый. Совет чоры кешеләре, аннан соңгы постсовет пространствосы вәкилләре, ягъни безгә, комиссар Катаниның мафия белән озын-озак 8 сезонга сузылган көрәше турындагы сериал, Сан-Ремо фестиваленең начар сыйфатта яздырылган җырларыннан гыйбарәт магнитофон кассеталарыннан яңгыраган аһәңнәре аша таныш Италия сурәте һәм чын Италия – икесе ике нәрсә, ди Глускер. Аннан соң инде тема артыннан темага күчә: мода, кино, аш-су, музыка, футбол, тарих, архитектура, мафия, дин, гаилә, клан, һәм, һичшиксез, сәясәт.

«Вспомнил о плащах из ткани «болонья» на наших мамах, о фестивале в Сан-Ремо, который единственный, из всех западных программ, показывался в прямом эфире на советском телевидении. Я вспоминал «Феличиту» и «О соле мио», ангельский голос Робертино Лоретти и насыщенный, с хрипотцой, Тото Кутуньо. Я напевал песни Челентано, взрывавшие наши дискотеки, и быстро просматривал фрагменты бессмертных

фильмов Феллини, как ни странно, демонстрировавшихся в наших кинотеатрах...

Я прекрасно понимал, что мне никак не обойтись без подробного рассказа про «Фиат», ставший прототипом первого советского народного автомобиля. Поэтому, за несколько дней до вылета, я направил письмо в штаб-квартиру автомобильного концерна с просьбой разыскать для меня раритетный «124», который и был выбран в качестве прототипа «Копейки».

Перечисляя в голове ставшие уже такими родными все эти итальянские «образы и подобия», я вдруг отчетливо понял, что одними воспоминаниями мне отделаться не удастся. Античность Рима и каналы Венеции, вулканы Сицилии и дворцы Флоренции, трущобы Неаполя и витрины Милана. Это, безусловно, национальное достояние. Но есть же, черт возьми, и вечные ценности, без которых итальянская жизнь была бы скучна и однообразна. Пицца и паста, «Веспа» и «Феррари», Ватикан и мафия, наконец. Но главная ценность этой страны – ее люди. И тут вдруг я задал себе, в общем-то, простой вопрос: «Так кто же они, настоящие итальянцы?» Наследники древних римлян, поющие песни в Сан-Ремо? Любители макарон, побеждающие на конкурсах красоты? Жившие тысячу лет под властью римских пап и создавшие самую мощную Коммунистическую партию Запада? Совершившие настоящую революцию в кино и придумавшие новую моду XX века? Галилей и Гарибальди, Леонардо да Винчи и Софи Лорен, Феллини и Верди, Микеланджело и Челентано... Ведь все они родились именно здесь».

Глускер мифларның чынбарлыкта булганнарын да күрсәтә, ә менә кайсыберләренең бары тик миф кына булуын да яшерми. Мәсәлән, Турин базарында яшелчә, җиләк-тимеш сайлаганда, андагы сатучыларның Чиполлино турында беркайчан да ишеткәннәре булмавына исе китә. Бу сатучылар, ни кызганыч, Джанни Родари исемле язучылары барлыгы хакында да белмиләр булып чыга. Ә инде Висконти фильмнарына әллә ни хушы китмәгән, «Рокко и его братья»ны карамаган итальянлылар, аннан да бигрәк, Доменико Дольче белән Стефано Габбана үзләре үк болонья плащлары дигән кием-салымның Италиядә беркайчан да булмавы хакында кат-кат әйткәч, авторыбызның бөтенләй кәефе төшә. Димәк, совет чынбарлыгына Урта диңгез якларыннан искән шифалы, иркен сулышлы җилләрне алып килгән бу җиңел тукымалы плащлар – бер миф булган, ә аларны киеп алган һәм шунда ук үзләрен Джина Лоллобриджида, Софи Лорен биеклегендә хис иткән совет ханымнары вә туташлары... нибары иллюзия белән яшәгән?! Шулай да Стефано Габбана ул кадәр бетеренмәскә киңәш итә Глускерга:

– Послушай, а может, эту ткань делали у вас в России? Ну, вот так, в СССР, скузи (итальян телендә – гафу итегез. – Авт.). И кто-то просто назвал ее «болонской», чтобы выдать за «настоящую» итальянскую!

– Стефано, ты прав! Это гениально! Да, это такая реклама была просто. Все дело в маркетинге.

Шуннан соң, автор үзенең капиталистик рельсларга күчкәнче үк маркетинг ысулларының үтемле вариацияләрен куллана белүче ватанына – совет мәмләкәтенә горурлык хисләре белән күз сирпеп ала.

Китап үзенең төзелеше, мантыйгы буенча үтә гади һәм ир-егетләрчә, дияр идем. Жанна Агалакова вариантындагы хатын-кыз бормалары юк биредә, бар да – маңгайга терәп әйтелгән, бүлекләрнең исемнәрендә тема үзе үк төбәп әйтеп куела: 2 бүлек. Музыка; 3 бүлек. Мафия... һәм шулай дәвам итә. Бу ике авторны чагыштырып укыганда шунысы да кызыклы булачак: хатын-кызның дөньяга караш ракурсы һәм ир-атныкы. Сурәтләүдә дә гаять төрле алар.

Глускерның ирониясе дә Агалаковаңыкыннан аерыла. Әмма, журналист буларак, икесе дә төртмә телле, һәм матур, сокланргыч төртмә телле алар:

«Неужели настоящий итальянец – это тот, кто в первую очередь должен поесть, ну а потом – будь что будет? «Признаюсь, это мои маленькие слабости. Когда я путешествую, у меня всегда большие сложности с едой. На гастроли я с собой часто беру свою повариху Джованну, и когда она мне готовит пасту: карбонару, аматричану, да какую угодно, в этот момент я самый счастливый человек на свете. Мне больше ничего не нужно на свете. Верите?» Конечно, я верил. А паста «аль денте», про которую рассказывает Кутуньо в песне, – это просто способ приготовления. Спагетти не нужно доваривать до конца. Например, если на упаковке написано, что «время приготовления 9 минут», значит, воду слить нужно через 8. А последние полминуты готовить на сковороде вместе с соусом, чтобы паста впитала его в себя. То есть на вкус они должны быть чуть-чуть хрустящими, едва-едва заметно. Вообще, паста а! dente – это как раз из тех маленьких деталей, которые идеально описывают итальянцев. Разваренную пасту они терпеть не могут. И для них это просто огромная трагедия, настоящее испытание на грани с наказанием, когда они видят, как иностранцы готовят макароны.

Еда – действительно, одна из главных радостей итальянцев. А хорошая еда приносит двойное удовлетворение. Она – и культурное наследие, и повод для научных дискуссий. Неудивительно, что некоторые песни почти целиком состоят из названий продуктов.

Высокие чувства, которые настоящий итальянец может испытать по отношению к вкусной и здоровой пище, проявляются даже в самых романтических ситуациях. Чтобы признаться девушке в любви и, главное, иметь успех, надо просто назвать ее шоколадным мороженым. Вот он, мега-шлягер 1980-х, песня-победитель Сан-Ремо Gellato al ciccolato».

Бу урында Элизабет Гилбертның заманында бестселлерга әверелгән, соңыннан төп рольдә Джулия Робертс белән экраннарны да яулаган «Есть, молиться, любить» әсәре искә килеп төшә. Андагы героиня да Һиндстандагы ашрамда – догаларга өйрәнде, Балида – гашыйк булды, ә Италиядә... туйганчы ашады, «сыйлану симфониясе» кичерде.

Әмма без «чын итальянлы» булуның сере шушы икән, дип уйларга урын калдырмыйк. Һич юк! Сернең нәрсәдә икәнлегенә төшенер өчен исә... отпускка кузгалганда, йә булмаса ялларга чыкканда, бу ике китапны эләктерергә киңәш итәм. Интеллектуаль багажыбызны баетыр өчен генә булса да!

МАХСУС ПРОЕКТ

23нче чыгарылыш

Татарстан юбилярлары

PRESSA.RU

ТР Президенты ярдәмчесе, «Татнефть» ГАЖ Директорлар советы әгъзасы **Ринат Сабиров** июльдә үзенең 50 яшьлеген билгеләп үтә

Яңа максатларга таба

Владимир Бусыгин,
«ТАИФ» ААҖ генераль директорының «Түбән Кама Нефтехим» төркеме белән идарә итү һәм стратегик үсеше буенча урынбасары

Хөрмәтле Ринат Касыймович!

«ТАИФ» компанияләре төркеме җитәкчелеге һәм күп мең кешедән торган коллективы, шулай ук үз исемемнән Сезне истәлекле дата – 50 яшьлек юбилеегыз белән иң ихлас котлауларыбызны кабул итегез!

Максатка омтылучанлык, хезмәт сөючәнлек, гаять зур фидакарьлек сыйфатларына ия булганда һәрвакыт уңышка ирешергә мөмкин. Моның ачык мисалы – Сезнең профессиональ биографиягез. Гаять зур оештыру сәләтегез, тирән җаваплылык хисенә ия булуыгыз, алга карап фикер йөртә һәм конструктив сөйләшү алып бара белүегез дәүләт хакимияте органнарында, шул исәптән Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе вазыйфасында озак еллар уңышлы эшләп килүегезнең ышанычлы дәлиле булып тора.

Юбилей көнегездә Сезгә, Ринат Касыймович, зур иҗади мөмкинчелекләрегез, Татарстанның нефть һәм газ химиясе комплексының үзенчәлеген тирән белүегез, предприятиеләрнең нефть чыгару, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе проблемаларын хәл итүдә актив катнашуыгыз, Татарстан Республикасы бәхете өчен озак еллар нәтиҗәле хезмәт итүегез өчен ихлас рәхмәтебезне җиткерәсебез килә.

Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек һәм озын гомер, гаилә бәхете, яңа бөек казанышлар һәм һөнәри уңышлар телим! Киләчәккә булган ныклы ышаныч һәм үз көчегезгә таяну беркайчан да ташламасын, ә Татарстан Президентының ышанычы һәм республика халкының ярдәме изге эшләрегезнең һәм башлангычларыгызның таянычы булсын. Сезнең кебек актив һәм максатчан кеше өчен 50 яшь – икеләтә көч белән алга, яңа биеклекләргә таба бару өчен менә дигән мөмкинлек икәненә ышанам.

Үзегезгә һәм якыннарыгызга иминлек, изгелек һәм гөрләп алга бару насыйп булсын!

Реклама

Рушан Шәмгунов,
«ТАИФ-НК» ААҖ генераль директоры

Хөрмәтле Ринат Касыймович!

«ТАИФ-НК» ААҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз – 50 яшьлегегез белән ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Профессиональлегегез, белемнәрегез, бай тәҗрибәгез алга таба да Татарстан Республикасы һәм тулаем ил бәхете өчен хезмәт итсен!

Күп еллар дәвамында сез үзегезнең белемнәрегезне һәм мөмкинлекләрегезне икътисадның иң мөһим юнәлешләренең берсе – нефть һәм газ химиясе комплексы үсешенә багышлыйсыз. Гаять зур хезмәтегез, актив тормыш позициягез, оештыру сәләтегез дәүләт югарылыгындагы мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм итә. Эшчәнлегегезнең уңышлы нәтиҗәләре артында гаять зур хезмәт, эшкә заманча якын килү, принципиальлек, зур оештыру сәләте һәм Сезгә хас булган эшлеклелек һәм кешелеклелек сыйфатлары ята. Көндәлек эшегез даими фидакарьлек таләп итә, һәм бу киләчәге булган яңа идеяләрне һәм ниятләрне тормышка ашырырга ярдәм итә.

Бүгенге тантаналы көндә чын күңелдән Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге һәм барлык профессиональ һәм тормыш планнарыгызны тормышка ашыруда уңышлар телим!

Шамил Яһүдин,
«Татнефтепром-Зюзеевнефть» АҖ җитәкчесе

Хөрмәтле Ринат Касыймович!

«Татнефтепром-Зюзеевнефть» АҖ компаниясе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән ихлас котлауларыбызны кабул итегез! Сезнең бөтен тормышыгыз республиканың нефть тармагына хезмәт итүгә багышланган, һәм бу өлкәдә галим – нефть буенча белгеч буларак та, Татарстан Республикасы Президенты киңәшчесе буларак та күп эшләр башкардыгыз. Һәрвакытта да җаваплы, грамоталы һәм үзегезгә дә, кул астыгызда эшләүчеләргә дә таләпчән булуыгыз белән аерылып тордыгыз. Сезгә ныклап уйланылган һәм кат-кат үлчәнгән карарлар кабул итү хас. Шул сыйфатларыгызны күреп, Сезне республикада үз өлкәгездәге иң абруйлы белгеч буларак югары бәялиләр.

Тормышыгызда күп нәрсәгә ирештегез, әмма болар шуның белән туктап калырга сәбәп була алмый, чөнки Сезнең көчегез һәм белемнәрегез бүген дә җәмгыятькә кирәк. Ирешелгәннәр белән чикләнмәвегезне һәм Татарстанның чәчәк атуы хакына алга баруны дәвам итүегезне телим!

Без, нефтьчеләр, зур бер гаилә кебек. Безнең профессия – җир йөзендә иң мактаулыларның һәм әһәмиятлеләрнең берсе. Һөнәребез кеше тормышын җиңеләйтүгә юнәлдерелгән барлык механизмнарга энергия бирә. Без халыкка тизлек, яктылык һәм җылылык бүләк итәбез. Заман цивилизациясе безнең хезмәттән тора, дип тә әйтә алабыз. Һәм менә шушы нефть тармагына мөнәсәбәтебез булу безне бәхетле итә!

50 яшь – кеше өчен иң актив яшәү чоры. Юбилярның тормыш хәзинәсендә – теория һәм практика, тәҗрибә һәм көч, булдыклылык һәм элемтәләр. Инде күп нәрсә башкарылган, ә мөһим эшләр алда тагын да күбрәк!

Һәр эшегездә уңышлар юлдаш булуын телим! Язмыш тарафыннан билгеләнгән эшегезне үзегездән дә яхшырак итеп берәү дә башкара алмый. Ныклы сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс көч һәм энергия, республикабыз иминлеге хакына тагын озак еллар нәтиҗәле хезмәт итүегезне телим! Йортыгызда бәхет һәм иминлек хөкем сөрсен, ә янәшәгездә бары тик ышанычлы дусларыгыз булсын. Бергә булганда, барысын да булдырабыз!

PRESSA.RU

Җаваплылык һәм тәҗрибә

Дамир Шәмсин,
«Л. Я. Карпов исемендәге химия заводы» АҖ генераль директоры

Хөрмәтле Ринат Касыймович!

«Л. Я. Карпов исемендәге химия заводы» АҖ коллективы Сезне юбилеегыз белән ихлас тәбрик итә! Озак еллар дәвамында без Сезне менә дигән профессионал, республикабызга чын күңелдән бирелгән, халкыбыз хакына хезмәт итүче кеше буларак беләбез. Сезнең эшегезне берәү дә җиңелләрдән дип әйтмәс. Нефть чыгару, нефть эшкәртү, нефть химиясе кебек мөһим мәсьәләләр буенча республика Президенты ярдәмчесе булу һәм бу өлкәдә тармакның инвестицион проектларын тормышка ашыруга контрольлек итү – бу безнең төбәк өчен зур җаваплылык алу, дигән сүз. Белемнәрегез һәм тәҗрибәгез моны бик яхшы итеп алып барырга, ә киң колач белән уйлый белүегез иң катлаулы һәм актуаль мәсьәләләрне дә ышанычлы хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Ринат Касыймович, Сезгә чын күңелдән һәрчак уңышлар, нык сәламәтлек, яхшы кәеф, күңелле вакыйгалар юлдаш булуын телибез! 50 яшь – бик матур вакыт, тупланган тәҗрибә, алынган белемнәр, хәбәрдарлык һәм активлык гаять зур мәсьәләләрне һәм проектларны уңышлы тормышка ашырырга ярдәм итә. Сезгә сәламәтлек, гаилә иминлеге һәм иң изге теләкләр юллыйбыз!

Реклама

«Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» АҖнең генераль директоры **Дамир Кәлимуллин** июльдә үзенең 55 яшьлеген билгеләп үтә

Хезмәттәшлегебез файдалы һәм перспективалы

Альберт Гыйльметдинов,
А. Н. Туполев исемендәге КМТТУ – КАИ ректоры

Хөрмәтле Дамир Җәүдәтович! Вуз коллективы һәм үз исемемнән Сезне 55 яшь тулган көнегез белән тәбрик итәм!

Сез хаклы рәвештә Россия моторлар төзелешендә әйдәп баручы предприятиеләрнең берсе – «КМҖБ» АҖнең нык ихтыярлы һәм алдан күрүчән җитәкчесе булып исәпләнәсез. Соңгы елларда моторлар җитештерү берләшмәсендә гаять зур үзгәртеп корулар үткәрелде, предприятие инновацияле үсешнең яңа дәрәҗәсенә күтәрелде, җитештерү мөмкинлекләре шактый киңәйде һәм продукциянең сыйфаты яхшырды.

Үзегез җитәкли торган коллектив өчен Сез һәрвакыт борчылып яшисез, компаниянең социаль һәм кадрлар сәясәтенә зур игътибар бирәсез. Сыйфатлы кадрлар – теләсә кайсы компаниянең җитди өстенлеге икәнлеген белгән хәлдә, профильле уку йортлары, беренче чиратта КМТТУ – КАИ белән хезмәттәшлек итүгә зур игътибар бирәсез. Безнең озак еллык үзара хезмәттәшлек әүвәлгечә үк файдалы һәм перспективалы булып кала бирә.

Хөрмәтле Дамир Җәүдәтович, Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, күңел көрлеге һәм күпкырлы эшчәнлегегездә яңа казанышлар һәм җиңүләр теләргә рөхсәт итегез!

Реклама

Кече нефть компанияләренең үсү мөмкинлекләре зур

Станислав Головко,
«ГРИЦ» АҖ генераль директоры

Узган ел нәтиҗәләре буенча, 35,5 млн тонна нефть чыгарып, Татарстан республика нефть тармагы өчен рекорд саналган 4,5%лы үсеш күрсәтте. Кече нефть компанияләре дә бу казанышка үзләренең югары технологияле өлешләрен кертте. Аларның исемлегенең алтын урталыгында – «Геологик эзләнү-тикшеренү үзәге» АҖ. Үзенең юбилеен компания бер елга 140 мең тонна нефть чыгару белән билгеләп үтә.

«Кече» сүзе «ГРИЦ» АҖнең зурлыгы ягыннан караганда, алда торган бурычларга белән һич тә туры килми. Башка кече компанияләр кебек үк, ул нефть чыгаруда даими рәвештә индивидуаль якын килүләр һәм инновацияле ысуллар эзләү таләп ителәторган, авыр чыгарылучы запасларның кечкенә чыганакларын үзләштерү вазыйфасын башкара.

Ике дистә ел буена компаниянең нефть табу белән шөгыльләнүче белгечләре Татарстанның Чирмешән районы Иске Кади авылында скважина бораулау ысулларын, алардан файдалануны, аерым катламнарны ачу, төрле физик һәм химик үзенчәлекләре булган нефтьне туплау һәм транспортлау системасын камилләштерә. Шуның нәтиҗәсендә компания ун күтәрелештә нефть чыгару эшен уңышлы алып бара. Әлеге чыганаклардан алына торган запасларның күләме 300 дән 1200 тоннага кадәр исәпләнә. Аларның күп өлеше эшкәртү өчен катлаулы булган терриген һәм карбонат утырмаларда урнашкан.

Компанияне республиканың прогрессив КНК исәбенә чыгарып, «ГРИЦ» АҖ җитәкчелеге нефть чыгару процессын оптимальләштерүгә, матди-техник базаны камилләштерүгә, җитештерүне автоматлаштыруга зур игътибар бирә. Мәсәлән, предприятие девон нефтен һәм карбонат утырмалары нефтен аерым туплау һәм хәзерләүнең инновацияле ысулыннан файдалана. Ятмаларның сыйфаты нинди булуга карап, нефтьне скважинадан күтәрү өчен штангалы, чылбырлы һәм винтлы насослар, туплау һәм транспортлау системасы буенча нефтьне суыртып агызу өчен кечкенә фазалы насослар кулланыла. Барлык процесслар автоматлаштырылган, мәгълүматлар даими күзәтелеп тора һәм операторларга тапшырыла.

Нефть ятмаларын эшкәртүдә һәм чыгаруны оештыруда яңа ысуллар куллану нәтиҗәсендә «ГРИЦ» АҖ белгечләре нефть чыгару күләмен ел саен 20%ка арттыра баруга ирешә. Компания нефтьчеләре, республикада беренчеләрдән булып, катламнарны микрогидравлик җимерү технологиясен кертте. Гидродинамик ысуллар, бер үк вакытта скважиналардан аерым файдалану, СНПХ 9010 тибындагы химик реагентларны суырту һәм башка технологияләр актив файдаланыла.

Предприятие үсеше шактый зур инвестицияләр таләп итә. Тулаем алганда, предприятие җитештерүгә 2,5 млрд сум үз акчасын керткән. Нәтиҗәдә нефть чыгару елына баштагы 13 мең тоннадан бүген 140 мең тоннага җиткән, алынган нефтьнең гомуми күләме 1,78 млн тонна тәшкил иткән. Компания керемнең 60%тан артыгракы салым буларак күчерелгән. Компаниянең барлык эш чорында аның суммасы 12,1 млрд сум тәшкил иткән, шуның 1,2 млрд сумы республика бюджетына күчерелгән.

Егерме ел дәвамында предприятиедә профессиональ белгечләрнең тотрыклы коллективы тупланган. Аның күп өлеше – 102 хезмәткәрнең 68е – эшкәртелә торган чыганаклардан ерак түгел урнашкан авылларда яши. «ГРИЦ» АҖ үз нефтьчеләрен транспорт, азык-төлек, җиһазландырылган эш урыны һәм тиешле хезмәт хакы белән генә тәэмин итеп калмый, нефть сәнәгате объектларында техника куркынычсызлыгы буенча барлык тиешле шартларны да тудыра. Быелның июнь аенда предприятиенең үз авария-коткару часте хезмәткәрләре ГТХМ вәкилләре тарафыннан үткәрелгән уку-өйрәнүләрне уңышлы узган.

Компания район һәм республика тормышында актив катнаша. Беренче сыйныфка баручы авыл балаларын мәктәп кирәк-яраклары, форма һәм аяк киеме, Иске Кади авылының балалар хоккей командасын кием-салым белән тәэмин итү, республиканың балалар хоккей командаларына булышу, Чирмешән мәктәпләренә һәм мәдәният учреждениеләренә акча бүлеп бирү – бу әле компаниянең матди ярдәм күрсәтү буенча төрле дәрәҗәдәге җитәкчелекнең рәхмәтенә лаек булган эшләреннең берничәсе генә. «ГРИЦ» АҖ – «Яңарыш» республика проектларында даими катнашучылар исәбендә. Предприятие тарафыннан матди ярдәм күрсәтү өчен бүлеп бирелгән акча 53,7 млн сум тәшкил итә.

– 1997 елда республиканың кече нефть компанияләрен төзү турында Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев кабул иткән зур колачлы карар нефть чыгаручы күп кенә предприятиеләр һәм аларның коллективларының тормышын һәм язмышын уннарча елга алдан билгеләде, – ди «ГРИЦ» АҖ генераль директоры Станислав Головко. – Компаниябезнең 20 еллык юбилее көннәрендә без кече нефть компанияләрен төзү процессында катнашкан, практик ярдәм күрсәтүен бүген дә дәвам иткән барлык кешеләргә кабат җылылык һәм рәхмәт сүзләре белән мөрәҗәгать итәбез. Бүген зур ышаныч белән әйтергә була: кече нефть команияләренең, шул исәптән «ГРИЦ» АҖнең нефть чыгару эше әле озак еллар буе ышанычлы дәвам итәчәк.

Реклама

PRESSA.RU

ТОРМЫШКА, КЕШЕЛӘРГӘ, ЭШКӘ МӘХӘББӘТ БЕЛӘН

Марс Алиев, «Татптицепром» ЖЧҖ генераль директоры, Казан дәүләт ветеринария академиясенең икътисад, оештыру эшләре, менеджмент һәм мәгълүмат технологияләре кафедрасы мөдире, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, профессор, РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге премиясе лауреаты.

Бүгенге тел белән әйтсәк, республика кошчылыгының булачак «драйверы» 1947 елда Татарстанның Буа районының Иске Тинчәле авылында авыл укытучысының ишле балалы гаиләсендә дөньяга килә.

КЫРЫС ТӘРБИЯ ҖИМЕШЛӘРЕ

Сыйныфташ дуслары белән бергәләп кылган шуклыклары өчен әтисеннән, беренче чиратта, үткен һәм җитез Марска эләгә. Кайчакта: «Бусы киләчәк кыланмышларың өчен!» – дип, әтисе аны алдан ук җәзага тартып куя. Мондый кырыс «педагогика» үзенең җимешләрен бирә: балачактан тәрбияләнгән ныклык һәм кыюлык Марс Шәрифовичка үзенең һөнәри эшчәнлегендә бик күп сынауларны намус белән үтәргә һәм, берничә дә карамый, үз дигәненә ирешергә ярдәм итә.

Көче ташып торган, хезмәттән курыкмаган үсмер 15 яшендә «Идел» хуҗалыгында тәүге хезмәт юлын башлый. Холкының тере, эшлекле булуы аңа Казан ветеринария институтында укыганда да ярдәм итә. Комсомол, спорт (ул көрәш, бокс белән шөгыльләнә), студотряд – һәркайда инициативалылыгын эшкә җигә. Ә дәресләрдән соң эшкә йөгерә – урам себерүче, каравылчы, кочегар – аның өчен һәр хезмәт кадерле була, әти-әни җилкәсендә яшәргә теләми.

Институтта алган тәҗрибәсе Марска чын белгеч булып җитешергә ярдәм итә. Диплом алу белән аны «Биектау» совхозына билгелиләр. Совхозның терлекчелек буенча директор урынбасарын кырыс таләпләр һәм эш көннәренең нормаланмаган булуы каршы ала. Әмма моңа карап Марсның эшләү теләге кимеми, киресенчә, арта гына. Биш ел эчендә институтта алган белемнәрен максималь нәтиҗәлелек белән файдалану өстенә, ул үзендә оештыручы, администратор, хуҗалыкчы сыйфатларын да үстерә.

КҮРКӘ ИТЕН – ҺӘР ГАИЛӘГӘ

Марс Шәрифович совхозлар һәм колхозлар белән егерме ел җитәкчелек итә. 80нче еллар азагында авыл хуҗалыгы тармагында хуҗалык исәбе, коллектив һәм гаилә подряды, аренда мөнәсәбәтләре дигән төшенчәләр әле телгә генә керә, ә ул инде аларны актив тормышка ашыра башлый. Ул чакта үз адресына күп кенә тәнкыйть сүзләре ишетергә дә туры килә, шулай да бирешми.

Актив һәм тәҗрибәле идарәчене республика җитәкчелеге дә күреп ала. 1995 елда Марс Шәрифовичны Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының беренче урынбасары итеп билгелиләр. Һәм шунда ук алдына мөһим бурыч куялар: республика кошчылык тармагын саклап калырга. 1998 елдан «Татптицепром» җитештерү берләшмәсен җитәкли башлап, Марс Алиев кошчылык предприятиеләрен һәм республика инвесторларын файдалы сөйләшүләргә тарту ысулларын таба. «Ак Барс» банкының беренче булып Питрәч кошчылык фабрикасына акча кертүе нәтиҗәле була. «Ак Барс» үрнәгенә башкалар да кушыла. Тармак әкренләп кризистан чыга.

Ирешелгәннәрдә тукталып калу Марс Шәрифович холкына хас түгел. 2000 нче еллар уртасында ул чакта әллә ни киң таралмаган юнәлеш – күркә асраучылык аның игътибарын җәлеп итә. Теманы өйрәнеп, «Татптицепром» җитәкчесе Татарстанда күркә үрчетү кирәкле һәм перспективалы эш, дигән нәтиҗәгә килә. Беренче зур партия – Лениногорск кошчылык фабрикасыннан китертелгән

Реклама

биш мең күркә чебие республикада бу диетик, тәмле һәм файдалы ризык әзерләүнең башлангычы була.

ҺӘРЧАК ЯНӘШӘҢДӘ БУЛГАННАР

Балачактан хезмәткә күнегеп үссәң, ул сине гомерең буе озата бара. Бүген 70 яшьлеген билгеләп үткән Марс Шәрифович, икътисад, оештыру эшләре, менеджмент һәм мәгълүмат технологияләре кафедрасы мөдире буларак, профессиональ һәм укыту өлкәсендә актив эшчәнлек алып баруын дәвам итә. Төрле юнәлешләр кисешкәндәге фәнни-практик проблемаларны хәл итү өстендә дә эшли. «Умартачылыкның икенчел чимал чыганакларыннан яңа биологик актив субстанцияләр технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертү һәм аларны кош асраучылыкта файдалану» дигән хезмәте өчен, Марс Шәрифович РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге премиясенә лаек булды.

Барлык әлеге эшләр һәм вакыйгалар, шулай ук һәркемгә һәрвакыт ярдәм итәргә омтылуы (берәрсенең үтенечен кире кагарга туры килсә, Марс Шәрифович рухи уңайсызлык кичерә – шундый булып яратылган инде ул) арасында елдан-ел ишәя барган гаиләсе өчен дә вакыт таба. Сөйкемле хатыны, өч баласы, алты оныгы… Гаилә белән җыелып фотога төшү өчен бер көн дә вакыт җитми! Өлкән оныгы Диләрә – КФУ студенты, отличница. Кәрим оныгы – математик та, футболист та. Марс Шәрифович кечерәкләре дә югалып калмас, дип ышана. Үрнәк алыр кешеләре бар бит! Марс Шәрифовичның хатыны Мөнирә апа исә һәрчак янәшәсендә. Әлеге шигъри юлларны да ул иренә багышлап язган:

Мин бәхетле синең янәшәңдә,
Тормышыбыздан бик канәгать.
Балалар һәм оныкларга телим
Эчкерсезлек, тәүфыйк, итагать.

Еллар узган саен ныграк тоясың
Парың белән яшәү рәхәтен.
Агач аумый, тамыры тирән булса –
Безнең тамыр җирдә бик тирән
Яшәү дәрте, сүнмәс көч белән!

Реклама

Җир кешесе

Ирек Закиров,
«Татагропромстрой» ААҖ
генераль директоры,
Буа якташлыгы
президенты

Хөрмәтле Марс Шәрифович, кадерле якташыбыз! Буа якташлар җәмгыяте исеменнән 70 яшьлек юбилеегыз белән тәбрикләргә рөхсәт итегез!

Сез уңышлар белән дә, кыенлыклар белән дә тулы тормыш юлы үттегез – моның белән чын мәгънәсендә горурлана аласыз. Хезмәт эшчәнлегегезне яшь белгеч – Биектау районының терлек симертү совхозында зоотехник буларак башлап, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасарына, «Татптицепром» АҖБ генераль директорына кадәр авыр һәм данлы юл үттегез, Россия Федерациясенең фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты дигән югары исем, Россия АСКның мактаулы хезмәткәре, ТР авыл хуҗалыгының атказанган хезмәткәре исемнәрен алдыгыз.

Авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, профессор булуыгыз җитештерү эшчәнлеген фәнни эшчәнлек белән уңышлы бәйләп алып баруыгыз турында сөйли. Республика авыл хуҗалыгы үсешенә керткән өлешегез ил һәм Татарстан җитәкчелеге тарафыннан югары бәяләнде – Сез «Халыклар дуслыгы» ордены, «За трудовое отличие» медале һәм күп кенә башка бүләкләргә лаек булдыгыз.

Кадерле Марс Шәрифович! Сезгә ихлас күңелдән нык сәламәтлек, барлык планнарыгызның тормышка ашуын, максатларыгызга ирешү юлында уңышларга ирешүегезне телибез! Күңел күтәренкелеге һәм олы гаилә бәхете юлдаш булсын! Тормышыгызның һәр көне иҗат шатлыгы, бәхет һәм җылылык белән тулып торсын!

Без Сезнең белән горурланабыз!

«Туполев» ГАҖ филиалы – С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының техник директоры **Эдуард Соркин** июльдә үзенең 65 яшьлеген билгеләп үтә.

Альберт Гыйльметдинов,
А. Н. Туполев исемендәге КМТТУ – КАИ ректоры

Бәяләп бетергесез белем һәм тәҗрибә

Хөрмәтле Эдуард Матвеевич, КМТТУ – КАИ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән 65 яшьлегегез белән ихлас тәбрикләүләребезне кабул итегез! Сезнең югары профессиональлегегез, хезмәт сөючәнлегегез, фикерләү сәләтегез һәм иң кыен хәлләрдән дә чыгу юлы таба белүегез нәтиҗәсендә «Туполев» ГАҖ филиалы – С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы катлаулы 90нчы елларда да яшәвен дәвам итә алды. Югары класслы белгечләр коллективы сакланып калды, һәм бүген каилылар авиация төзелешенең заманча мәсьәләләрен хәл итүдә уңышлы эшли.

Күп кенә башка сәләтле конструкторлар һәм инженерлар кебек үк, Сез Россиянең иң яхшы техник университетларының берсен тәмамлагансыз, һәм нык ышаныч белән шуны әйтә алам: бәяләп бетергесез тәҗрибәгезне һәм белемнәрегезне бүгенге яшьләр белән бик теләп уртаклашасыз.

Мин Сезне авиатөзүче генә түгел, аралашу өчен уңайлы һәм күп нәрсәләргә өйрәнергә мөмкин булган кеше буларак та яхшы беләм. Сезгә сәламәтлек һәм һәр нәрсәдә иминлек юлдаш булсын, яңа фәнни, иҗади уңышларга ирешүегезне һәм билгеләнгән планнарыгызның тормышка ашуын телим!

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:
тел: (843) 222-06-05

Реклама 16+

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ КАЙЛАРДА САТЫЛА

КАЗАН

«МИР ПРЕССЫ – РЕГИОН» ҖЧҖ

«ДЕЙЛИ» КИБЕТЛӘРЕ
К. Маркс ур., 59
Н. Ершов ур., 78
Зорге ур., 93
«Тукай мәйданы» метро станциясе
Н. Ершов ур., 1 а («Корстон»)
«Горки» метро станциясе
Белинский ур., 4
«Җиңү проспекты» метро станциясе
Чуйков ур., 69
Парк ур., 6
Короленко ур., 81
Фрунзе ур., 5
Мусин ур., 68 б
Лаврентьев ур., 9
Даурия ур., 40

«ТАТАР КИТАП НӘШРИЯТЫ» ТР ДУП
Декабристлар ур., 2
Бауман ур., 19
Бауман ур., 29/11

«ГОРПЕЧАТЬ» ЯАЖ
Фрунзе ур., 7
Пушкин ур., 2
Сахаров ур., 13
Межлаук ур., 15
Ямашев пр., 49
Вишневский ур., 2
Н. Назарбаев ур., 47
Н. Назарбаев ур., 63
Восстание ур., 83
Кави Нәҗми ур., 7
К. Цеткин ур., 17/20
Восстание, 23 / Декабристлар ур.
Копылов ур., 5/1
Адоратский ур., 29
Максимов ур., 34/24
Липатов ур., 5
Достоевский ур., 74 а
Себер тракты, 7
Декабристлар ур., 189
Татарстан ур., 72
Даурия ур., 36
Даурия ур., 23
Автовокзал
«Казан Оргсинтез»
Горький шоссесы / Можайский ур.
Н. Ершов ур., 53
Кошевой ур., 16
Декабристлар ур.,178 а
Восстание ур., 56
Айдаров ур., 8 а
Окольная ур., 23
Себер тракты, 34
Декабристлар ур., 102
Челюскин ур., 31
Краснококшайская ур., 164
Максимов ур., 4
Ш. Усманов ур., 12
Гвардейская ур., 42
Батыршин, 16 / Коләхмәтов ур.
Революция ур.
Ильич ур., 30
Попов ур., 7
Беломорская ур., 73
Газовая ур., 9
Декабристлар ур., 115
Н. Назарбаев ур., 35
Черноморская ур., 3
Восстание ур., 6
Калинин ур., 73
Мәүлетов ур., 17
Гагарин ур., 22
Гагарин ур., 12
Халитов ур., 34 ж
Белинский ур., 9
Фучик ур., 72
Тынычлык ур., 33
Карбышев ур., 13
«Океан»
Чуйков ур., 38
Н. Ершов ур., 32
Гвардейская ур., 38
Чехов ур., 6
Халезов ур., 21
(Дәрвишләр бистәсе)
Короленко ур., 89
Декабристлар ур., 150

«ТАТАРСТАН ПОЧТАСЫ» ФПЭИ ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ
Сахаров ур., 27
Мәүлетов ур., 9
Забайкальская ур., 3
Маршал ур., 25
Һ. Такташ ур., 75
Мехчылар ур., 3
Бауман ур., 37
Меридиан ур., 14
Әмирхан пр., 10 а
Максимов ур., 2
Салмач, Тынычлык ур., 6 а
Адоратский ур., 29 а
Адоратский ур., 12
Мусин ур., 68
Гаврилов ур., 40
Җиңү пр., 17
Ю. Фучик ур., 34
Кремль
Нокса авышлыгы, 1
К. Маркс ур., 44
Яңа аэропорт
Татарстан ур., 11
К. Цеткин ур., 33
Фрунзе ур., 1
Айдаров ур., 22
Декабристлар ур., 191
Юбилей ур., 1/43
Вишневский ур., 14
Волгоград ур., 22
Шатура ур., 155
Качалов ур., 95
«Оргсинтез» заводы
Беломорская ур., 1
Карьер, Нокса ур., 29
Мирный, Яңа Дәүлекәй ур., 16 а
Нагорный, Круговая ур., 12
Павлюхин ур., 116
Рәхимов ур., 33
Ирек мәйданы, 1
Черноморская ур., 3
Петровск, Үзәк ур., 1
Тынычлык ур., 45
Гвардейская ур., 42
Яңа Юдино ур.,140
Красиков ур., 8
Завокзальная ур., 57
Альберт Камалиев ур., 12
Беломорская ур., 73
Зур Урам, 11
Я. Гашек ур., 1
Дәрвишләр бистәсе,
Краевая ур., 8 а
Товарищеская ур., 28/70
Б. Заречная ур., 22
Кадыш, Калинин ур., 1
Кремль
Оренбург тракты

Реклама 16+

PRESSA.RU

КОШЛАР ТАВЫНА СӘЯХӘТ

Республикабызның үзенчәлекле, бай тарихлы авылларын барлауны дәвам итәбез. Бу юлы Апас районының Коштаулы авылына юл тоттык. Җәй бит, табигатькә якынрак буласы килә. Ә мондый исемле авылда, һичшиксез, табигать тә гүзәл, кошлар да үзгә булырга тиештер кебек. Өметләр акланырмы? Киттек.



Автор:
Руфия Фазылова

«ҖЕНАЗАҢ ШУШЫ ЙОРТТАН ЧЫКСЫН»

Коштаулы – аңлатмасы гади: кошлар тавы. Авыл урыны гомергә сазлыклы, күлле булган. Шуның өчен биредә кошлар да күпләп яшәгән. Әле кошларның да ниндие!

Биредә Аккош күле бар. Шунда ел саен аккошлар, каз-үрдәкләр килеп бала чыгарган. Җәй җитте исә күл буе авылның иң матур, иң сихри урынына әйләнгән. Ни өчен үткән заманда язам, чөнки бүген бу әкияти могҗиза юк инде. Сәбәбе турында авылның иң үткен, абруйлы кешеләреннән саналган Мәгъфирә апа Хәмидуллина сөйләде:

– Коштаулыда тудым, үстем, картайдым. Тиздән 93 яшь тула. Мин белгәннән бирле Аккош күленнән, авылның яше-карты су ташыды, шунда ял итте. 1965 елда Коштаулыга күрше Килдураз авылыннан сөт-май заводын күчереп куйдылар. Заводтан чыккан бар пычрак һәм кислоталы су күлгә агып төште. Хәтта күл янына килеп булмый башлады, зәһәр бер ис килә иде. Балыклар гына түгел, бака һәм башка тереклек ияләре дә һәлак булып бетте. Ә аккошлар, казүрдәкләр турында әйтеп тә торасы юк. Сөт-май заводы берничә ел элек ябылды, тик күл дә корыды инде. Бичаракайларым, хәзер дә берничә аккош ел саен килеп, күл буенда йөри-йөри дә очып китәләр икән. Алар мөгаен безнең күлдә үскән кошлардыр.

Фото: Александр Ефремов



Мәгъфирә апа авырлыклар күп күрсә дә әле яшәү дәртен, тормыш егәрлеген югалтмаган, заманча фикерле. «Сезгә бер дә 93 яшьне биреп булмый» – дигән идем: «Балалар хәсрәте булмаса, мин әле кызлар кебек йөгереп йөрер идем»,- дип җаваплады ул. Өч ул, бер кыз үстергән әбиебез. Дүрт баласы да бүген җир куйнында ята икән. Кызы илле ике яшендә, уллары алтмыш яшькә җитеп, бер-бер артлы дөнья куйган.

– Балаларым кинәт вафат булды, йоклап яткан җирдән, – дип сөйләде ана. – Әле минем бәхеткә Раушания киленем булган. Әнкәле-кызлы кебек 33 ел гомер итәбез. Бик акыллы, сабыр ул. Мин электән шундый үткен булдым. 1943 елдан 1950нче елларга кадәр комбайн йөрттем, эшне ир, хатынныкына бүлмәдем. Улларыма карата исә кырыс идем, эшсез тотмадым. Аллага шөкер, баһадирлар үстердем. Дәрәҗәле җирләрдә эшләделәр. Гомерләре генә кыска булды.

Хәмидуллиннар гаиләсе гармунчылар нәселе. Мәгъфирә апаның дүрт баласы да гармунда уйный белгән. Сабантуй, башка бәйрәмнәрдә аларның нигезендә таң атканчы гармун тавышы тынмаган. Аларны әбинең тормыш иптәше Хәкимулла абый үзе ясаган. Авылның атаклы гармун остасы булган ул. Бүген дә йортта Хәкимулла абый ясаган гармун саклана. Оныклар аны иң кадерле ядкарь итеп саклый. Гармун дигәннән, 1970нче елларга кадәр Коштаулыда 70 процент ир-егет әлеге уен коралында уйный белгән.

Төп йортка килен булып төшкән Раушания апа тормыш иптәше Рамил Хәмидуллин белән ике ул үстергән. Малайларның икесе дә башлы-күзле булып Казанда яши. Гаилә башлыгы Рамил абый гомере буе Апас полиция бүлегендә эшләгән, полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әле күптән түгел ирен җирләгән Раушания апа сабырлыкның серен менә нидә күрә:

– Гомер буе каенана белән яшәдем. Әни үткен, нык холыклы, шуңа карамастан, без сүзгә килеп, ачуланышып яшәмәдек. Хәтерлим, никах көнне үз әнием: «Мулла укыганда: «Җеназам шушы нигездән чыксын иде, дип теләп утыр», – диде. Безне ирне ир, каенана, каенатаны хөрмәт итәргә өйрәттеләр. Шул киңәшләрне тотып гомер уздырдык. Әни белән икәү генә торып калдык. Ул миңа терәк тә, дус та, исән-сау була күрсен...

ТАРИХИ КӨНДӘЛЕК

Шуңа игътибар итәм: хәзер күп авылларның үз китабы бар. Кайдадыр аны шул авылда яшәүче, каләме булган шәхес язган, кайсыдыр җирдә аерым бер кеше акча түләп эшләткән. Коштаулының да затлы, 680 биттән торган, авылның тарихын, бүгенгесен яктырткан үз китабы бар. Аны шушы авылдан чыккан, бүгенгесе көндә Казанда яшәүче эшкуар, «Апас» якташлык җәмгыятенең вице-президенты Наил Галиуллин яздырган.

– Наил абый кебек кешеләр авылда тагын берничә булса, бер кайгы да күрми яшәр идек, – диде Коштаулы җирлеге башлыгы Хәҗәт Сабиров. – Ярдәм кирәк очракта аңа әйтәбез, беркайчан кире какмый. Үзе дә ата-ана нигезенә атна саен кайтып йөри. Колхозлар таралгач, авыл мескен хәлгә төште. Сабантуй үткәрергә, башка эшләргә дә бер тиен акча юк. Шуңа күрә иганәчеләр эзлибез, әле алар бар. Соңгы елларда эшләнгән кое, күл, зират йорты – барысы да белдекле эшкуарлар, мәрхәмәтле авылдашлар ярдәме белән булды.

Авыл тарихы китабын язарга алынгач, могҗизага тиң дәфтәргә тап булалар. Баксаң, 1925 елда Коштаулыда туган, шунда үскән, 1967 елда Казанга күченгән фронтовик-хезмәт ветераны Әнәс Мәхмутов, туган авылы тарихына багышлап, 622 битле көндәлек язып калдырган. Каян башына килгән, ничек шуның кадәр мәгълүмат җыя алган, авылдашлары хәзер дә соклана, гаҗәпләнә. Әнәс абый көндәлегендә шундый юллар бар:

«Коштаулы 1700нче елларда барлыкка килгән дип фаразларга була. Архив документларында шундый саннар бар. Авыл элек Тәтеш өязе Килдураз волостенә кергән. Революциядән соң Апас районына кушылган.

Кызганыч, элеккеге кульязмалар сакланып калмаган. Бабайлар сөйләве буенча, авыл бу урында булмаган. Ә моннан ерак түгел Килдураз авылы белән ике арада Чуертау дигән таулы урын бар. Менә шунда берничә гаилә яшәгән, дип сөйлиләр. Моның булуы бик мөмкин. Бу урында элекке савыт-саба ватыклары, таба кисәкләре табылган.

Авылның төньяк-көнбатышында «Дүрт үле» чокыры бар. Телдән-телгә күчеп килүче риваятьләргә караганда, бу җирдә дүрт гаилә яшәгән. Бервакыт, Чуертауда яшәгән кешеләр килеп, боларны үтергәннәр. Һәм бу җиргә үзләре хуҗа булганнар. Авыл белән чокыр арасында әле дә каберлекләр бар. Аның тирәсе тотынмаган, шулай ук сукаланмаган да».

Әнәс бабай көндәлегендә Аккош күлен дә бик матур тасвирлый. Аккош көтүе, шундагы бакалар «хоры», таллык, камышлыклар – балачагының иң ямьле чоры дип атый. Коштаулыда коелар, күлләр күп булган. Заманында авылны кеше аяк басмаслык сазлыклар чолгап алган. Боларның барысы хакында да Әнәс абый бәйнә-бәйнә язган. Хәзер авылда ул сазлыклар юк инде, ә менә коелар сакланып калган. Тагын бер үзенчәлек: биредә бер-ике метр җирне казысаң су чыга. Чынлап та, авыл сазлыклы урынга урнашкан икәненә инанасың.

Коштаулыда бүген 277 кеше яши, 153 хуҗалык исәпләнә. Барлык татар авылларындагы проблема монда да бар: яшь гаиләләр авылда бик калмый. Сәбәбе – әлеге дә баягы эшсезлек, башка проблемалар. Коштаулыда белем йорты юк, малай-кызлар күрше Килдураз төп белем бирү мәктәбенә йөреп укый. Бәхеткә, балалар бакчасы бар, анда унлап сабый йөри икән. Шулай ук мәдәният йорты, мәчет, кибет, китапханә эшләп килә. Авыл кешесе шуңа сөенә.

PRESSA.RU



ЧАРДУГАН ЯСАУЧЫ ИМАМ

Коштаулыда халык гади, ачык. Кайсы гына йортка керсәң дә, чәйгә кыстыйлар. Күбесенең бакчасы, ишегаллары чәчәккә күмелгән. Һәм иң сөендергәне, бәлки, гаҗәпләндергәне дияргә кирәк: халык дөресен сөйли. Бер проблемаларын да яшереп калмыйлар. Хәтта авылның имамы Ислам хәзрәт тә хәлне ничек бар, шулай бәян итте.

Ислам Гыймадиев дингә яшьли килгән. Коштаулыда мөселман туе уздыручы беренче кеше ул. 2003 елда Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәне тәмамлаган. Авылда аның абруе бик зур. Кем белән генә сөйләшсәң дә, «безнең Ислам» диләр. Гәрчә авылның имамы башкача уйлый икән:

– Бер-ике тапкыр муллалыктан китәргә дип тә караган идем, – ди Ислам Гыймадиев. – Җибәрмәделәр. Юк, миңа мәчеткә бару, мәетләрне күмү авыр түгел. Тик авыл имамы башка эшләрне дә алып барырга тиеш, дип уйлыйм.

– Ә тагын нинди эшләр? – дим.

– Мәчеттә балаларга дин гыйлеме дәресләре укыту, иң беренче чиратта, мулла өстендә булырга тиеш. Шулай ук авылда яшәүче авырулар янына барып хәлен белеп, сәламәтлегә өчен дога укып кайтса да, яхшы бит. Сырхау кешенең дә күңеле, доганың да шифасы булыр иде. Дөрес, мин боларны кайчандыр эшләдем, балаларга дин гыйлеме дә өйрәттем. Ә соңгы елларда бу эшләр белән шөгыльләнергә вакытым юк. Кызганычка каршы, дөнья мәшәкатьләре шактый. Шунсыз булмый, тормышны алып барырга кирәк. Хатыным белән өч ул үстерәбез. Балалар әле мәктәптә укый. Аларны аякка бастырасы бар. Үзегез беләсез, муллаларга хезмәт хакы түләнми.

Ислам Гыймадиев җиде ел элек шәхси эшмәкәр булып теркәлгән. Шул елны үгезләр үстерү өчен дәүләттән кайтарылмый торган 58 мең сум субсидия алган. Бүген дә әлеге шөгылен ташламаган: кечкенә үгезләрне үстереп сата. Авыл мулласының тагын бер шөгыле бар: тимердән чардуганнар, капкалар эшли. Тимер эретеп ябыштыру өчен, бөтен җиһазны үз куллары белән ясаган:

– Безгә бит кредитлар алырга ярамый, риба, – дип сөйләде Ислам

хәзрәт. – Шуңа күрә кайда нәрсә аунап ята, арзангарак бирәләр, алып кайтам. Әтием гомер буе тракторда, комбайнда эшләде. Аннан калган иске тимер-томырлар да бар. Шуларны эшкә җигәм. Менә бу эретеп җыю җайланмасының моторын гына сатып алдым.

– Тимер эше белән ничек мавыгып киттегез? – дим.

– 2000нче елларда Апас мөхтәсибәтендә эшләдем. Ә аннан бер һөнәр булсын дип, Апас аграр көллиятенең эретеп-ябыштыру факультетына укырга кердем. Укып бетергәч, районның металл җыю базасына эшкә урнаштым. Тик 2010 елда ябылды ул. Шуннан озак уйлап тормадым, эретеп ябыштыру эшенә керештем.

Чардуганнарның бәясе 4–8 мең икән, ничек эшләвенә карап. Биек, челтәрләп ясаганы кыйммәтрәк йөри. Ә тимер капкалар, кую белән бергә 50–60 мең сум. Бизәкләрен, төсен Ислам абый заказ бирүченең теләгенә карап эшли.

– Чардуган, капкаларны үзегез генә эшлисезме? – дим.

– Төрлечә була, улларым да булыша. Эш күп булганда хатынның абыйсы, кияүне чакырам. Күршем кереп булыша.

Ислам Гыймадиев белән бик озак сөйләштек. Дин дип кычкырып йөреп, кемнедер сүгүче муллалардан түгел ул. Дөньялыкны да, динне дә алып бара ала торган гаять гыйлемле имам ул. Авылдашларына үз мисалында дөрес яшәүнең юлын күрсәтә. Мондый имамнар күбрәк булса, авыл мәчетләре буш тормас иде.

ИКЕ ЙОРТНЫҢ БЕРСЕНДӘ ТРАКТОР!

Бу авылның хатын-кызлары үткен. 93 яшьлек Мәгъфирә ападан башлап, яшь кызларга кадәр. Клуб мөдире Тәскирә апа Хафизова, хуҗабикә Фадия апа Усманова хуҗалыкларын карап чыктык. Унлап баш мөгезле эре терлек кенә асрыйлар. Йорт-җирләре ялт иткән, бакчада ни генә үсми! Кайчан барысына да өлгерәләр, тамаша!

Коштаулыда тагын бер нәрсә шаккатырды: монда һәр ике йортның берсендә кечкенә ясалма трактор бар. «Ока», «Лифан» моторы булса, калганын җыю бер ни түгел икән. Мини-тракторларны авылда беренче булып Ильяс Галиев ясаган. Җирле Ломоносов яки Исаак Ньютон ул биредә. Уйлап табучының үзе белән танышып булмады, Казанга эшкә киткән чагы туры килде. «Замана техникасы» турында Ислам абый Гыймадиевтан сораштык. Ул да ишек алларындагы мини-тракторын үзе ясаган:

– «Ока» моторыннан ясаган трактор ягулыкны күбрәк ашый, шуңа мин «Лифан»нан эшләдем. Ишек алдында әллә ничә еллар череп яткан берәр техника булса җитә инде. Шуның әйберләрен алып трактор әвәләргә була. Дөрес, кайбер детальләрне сатып алырга да туры килә. Безнең авылда хәзер шундый мини-тракторларны ясап сата башладылар, бәясе 50–60 мең сум. Бик җайлы ул, машина йөртү таныклыгы да кирәкми, җир эшкәртәсең, печән чабасың, кирәк җиреңә барасың. Минем күбрәк аңарда малайлар йөри. Болыннан печән алып кайталар.

Ильяс Галиев кечкенәдән уйлап табучы булган. Үсмер чагында ук, сыйныфташ малайлары белән, яшәгән йортларына радио чыбыгы сузган. Малайлар бер-берләре белән шулай аралашкан. Ул чагында әле йортларга телефон кертү турында сүз дә булмаган. Кызганыч, Ильяс абый шул юнәлеш тә укырга кермәгән. Кем белә, бәлки берәр танылган инженер яки физик туар иде. Хәер, өмет бар әле: Коштаулы үсмерләренә техника «җене» кагылган. Әти, абыйларына ияреп, трактор җыялар, техника төзәтәләр. Хәзер талантны ачарга мөмкинлекләр күбрәк, югалып калмаслар...

PRESSA.RU

Лениногорскида без легендаларны күп ишеттек: борынгыларны гына түгел, ә заманчаларны да. Рәнҗетелгән ротонда турында да бәян итте җирле халык, тынгысыз полтергейст белән сүгенергә ярата торган спортчы кыз турында да... Әмма бертавыштан иң күркәме Бәкер атлары хакындагысы булды, дип килештек.

ТАТАРСТАН ЛЕГЕНДАЛАРЫ: ХАН АТЛАРЫ

Борын-борын заманнарда бер бик тә абруйлы һәм кодрәтле ханның искиткеч матур атлардан тупланган табуны булган. Хәким аларның күпсанлы ярышларда яулаган җиңүләренә чын күңеленнән куанган, дүрт аяклы бу җан ияләрен хәтта хатыннары белән балаларына караганда да якынрак күргән. Җилдәй җитез булган атлар, яллары ефәктәй елкылдап торган, гәүдәләренең сылулыгы күзне иркәләгән. Әмма еллар арты еллар узган, һәм менә чабышкылар картая башлаган: елгырлыклары кимегән, аяклары аксаган, күмердәй янып торган күзләрен дә томанлы элпә каплаган. Хан инде аларга карап, элеккечә горурлык хисе түгел, ә кызгану тойгысы гына кичергән. Йола буенча, картайган атларны сугымга озатырга тиеш булганнар. Ләкин хан кайчандыр шулкадәр газиз булган атларына кул күтәрә алмаган, ерак түгел сазлыкка куып җибәрергә боерган. Нинди язмыш көтә аларны – Аллаһы Тәгалә үзе хәл итсен, дип гөманлаган. Бичара атлар, башларын боек кына түбән иеп, үлемнәренә таба юл тотканнар...

Күп тә үтмәгән, сазлык тирәсеннән узып йөргән хан ялчылары атларны күреп исләре киткән: куе, ефәк яллары яңадан җилдә җилферди, күзләре күмердәй дәртләнеп янып тора, йонналары кояшта ялык-йолык килә, аксаклык турында исә сүз дә булырга мөмкин түгел, аяклары биеп-уйнап тора, имеш. Яшәреп киткән, сау-сәламәт атларның кешнәвеннән ирек исе бөркелә, ди...

Бу хәбәр тиз арада бөтен тирә-юньгә таралган. Һәм бирегә могҗизалы дәвалау көченә ия саз ярдәмендә яшьлеген кайтарыр, чирләреннән арыныр өчен, халык агыла башлаган.

Ыруы белән Бәкер атлы кеше дә килеп урнашкан сазлык янына. Монда ул авыл салган, бу авылга аның хөрмәтенә Бәкер дип исем биргәннәр. Балалары исә күршедә яңа авыллар торгызып җибәргән: өлкән улы Иштирәк – Иске Иштирәк авылын, төпчек улы Каратай – Кече Каратайны.

...Аксакаллар әйтүенчә, теге тылсымлы гүзәл атлар ай тулган төннәрдә Бәкер сазлыгына төнге күктән көтүе белән килеп төшә дә, дәвалый һәм яшәртә торган сазга ятып ауный, терек чишмәсеннән су эчә, имеш. Ә инде көч туплап, сәламәтлекләрен яңарткач, яңадан биеккә – Айга юыртып менеп китәләр, ди.

Реклама 16+
Кис тә бүләк ит
Моңсулансаң, килеп чык, чәй эчәрбез!
97 еллык зирәклек
ТАТАРСТАН
журналы
ТАТАРСТАН
Журнал акыллы, игелекле, мәңгелек кыйммәтләргә ия булган эксклюзив открыткалар сериясе тәкъдим итә

PRESSA.RU